***Рөстәм Мингалим***

# КЕМ КУЛЛАРЫНА КАЛДЫРЫЙМ?

Шигырьләр, поэмалар

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2007

УДК 821.512.145-1
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
М50

**Мингалим Р.Г.**

Кем кулларына калдырыйм?: шигырьләр, поэмалар / Рөстәм Мингалим. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 382 б. – 2000 д. – ISBN 978-5-298-01571-4

Әлеге китапка шагыйрьнең төрле елларда язылган лирик-фәлсәфи шигырьләре һәм поэмалары тупланды.

ISBN 978-5-298-01571-4
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Мингалим Р.Г., 2007

## җиргә бер сүз

### ЯНА-ЯНА КИТКӘН ТОРНАЛАР...

I

Моннан бик еракта, артта, күп кышлар һәм җәйләр артында, бер көн бар. Ул көнне бүгенге ай да күрми, кояш та яктыртмый. Ул көн өстендә инде катлам-катлам яңа кышлар, язлар, җәйләр, көзләр. Яңа юллар, шәһәрләр...

Менә шул ерак көндә Эльза үзенә хас булмаганча җитди иде. Миңа ул моны сиздермәскә тырышты. Хәер, бәлки, Эльза холкы белән гел җитди кеше булгандыр. Гел миңа моны сиздермәскә тырышкандыр, минем әле җитдилектән ерак икәнемне сизеп шулай эшләгәндер... Булыр да!

Сез, кешеләр, гел учаклар кебек,
төрле уйлар сездә дөрлиләр.
Шуңа күрә генә дөнья якты –
якты көннәр, өйләр һәм илләр.
Әле, бәлки, Кояш яктылыгын
сезнең янулардан аладыр.
Яна сездә шатлык, кайгы, сагыш,
ә дөньяга болар бар да бер.
...Мин дә янам,
сезнең кебек янам! –
Йолдызларда шуның яктысы.
Бу язганым гади бер хикәят,
ләкин ул да гомер чаткысы.

II

Нигәдер?
Белмим мин,
белмим мин,
нигәдер
дусларга,
бер яшь кыз
сөям, дип сөйләдем.
Кич белән, киенеп,
киткәндә торактан,
әйттем мин дусларга,
барам, дип, еракка.
Әйттем мин, барам, дип,
сөйгәнем янына.
Гел әйттем, янәсе,
мин аны сагынам.
Ә чыны – ул яши
торакның каршында.
Сагыну уе да
юк кебек башымда.
Барам да кагылам
туп-туры ишеккә.
...Бер ел кагылам,
ике ел кагылам
шул таныш ишеккә.
Шылт итеп keләсе
ачылуын ишетәм.
Көннәрдән бер көнне
уздым да өенә,
нигәдер ашыктым
«Сагындым!» дияргә.

Эльзаның җавабы
кагылды йөземә:
«Сагынып килмәдең,
Алдыйсың?!
Йә, нигә?
Ни өчен алдарга?!
Ярамый алдарга!
Мин сине аңладым,
алдарга кирәкми!
...Кыен тик аңлавы үземнең йөрәкне.
Бик кыен аңлавы
үзеңнең йөрәкне.
Киттең бит,
килмим, дип.
Яңадан ник килдең?»
Кыен шул аңлавы
үзеңнең йөрәкне!
Мин чынлап аңламыйм,
аңларга кирәкме?
Сагынмый килдемме?
Сагынып килдемме?
Төшми һич хәтергә:
килмим, дип әйттемме?
Белмим мин,
белмим мин,
яңадан ник килдем?
Тик шуны беләм мин,
ул үзе сөйләде:
ватылган гаилә,
онтылган сөйгәне.
...Тәрәздә пәрдәләр –
ап-аклар, ап-аклар!
Зәңгәрсу халаты –
сап-сары шакмаклар.
Аягы очына
чүәге эленгән.
Сулышы ешлыгын
түшләре сөйлиләр.
Эльзаны шигырьгә
күчер дә куй аны.
Чәчләре кап-кара,
ямь-яшел диваны.
Диваны артына
чәчләре таралган.
Өстәлдә көзгесе,
кулында тарагы.
Тукта!
Ни сөйли соң
аның зур күзләре?!
Ул миннән башкарак,
ул миннән үзгәрәк:
шактый ук олырак,
шактый ук сипкелле,
еш кына елмая –
ул дөнья шикелле.
Шуңадыр ул миңа
бетмәде ошап та.
Шуңа бит мин аны
киталмыйм ташлап та.
Бүген ни сөйли соң

аның зур күзләре?!
. . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әллә ул үзгәрде?
Әллә мин үзгәрдем?
Әллә без
үзгәрдек?

Әнә шул ерактагы, инде табылмаска югалган кечкенә алтын тәңкә кебек түгәрәк көндә... Эльза озак сүзсез торды. Мин, әкрен генә ниндидер көй сызгырынып, бүлмәдә йөрдем. Бу кечкенә бүлмә Җир хәтле зур тоелды миңа ул чакта. Әйтерсең Җирнең бер як читендә – мин, икенче читендә – Эльза. Мин аны күрәм, таныйм. Башка көннәрдә ул болай җитди түгел иде. Әнә чын Эльза – стенадагы фоторәсемендә... Ул анда шат, бәхетле.

Күптән төшкән фотосурәте ул аның.

Мин һаман әкрен генә сызгырындым. Сызгырынуым бөтенләй үк мәгънәсез түгел иде, анда минем уй – мондыйрак мәгънәдәге җырлар бар иде:

Аклы күлмәк, аклы күлмәк
иңнәремә тар инде.
Сөйгән яры тиң түгел, дип
сөйләүчеләр бар инде.
Таулар биек, таулар биек,
тау өстендә учагым.
Дошман көнләшерлек ярлар
табала торган чагым.
Күлләрендә, күлләрендә
балыклар уйный икән.
Минем уйлар чуалганда,
ул ниләр уйлый икән?

Шунда кинәт Эльза елмайды. Стенадагы фоторәсеменә охшап калды. Ул әле гомерендә бер тапкыр да кайгы кичермәгән кызчык кебек иде. Мин сызгырынган шаян көйгә Эльза җыр башлады:

Ал итә алыр идем лә,
гөл итә алыр идем.
Ятлар сүзен санга суга,
ялгызы калыр инде.
Яулыгыма яңгыр тиде,
кибәр әле киптергәч.
Үптермәсәм, сөйми, диде,
азган, диде, үптергәч.
Өстәлемдә ике сәгать,
икесе дә туктаган...

Эльза җырлаудан туктады. Үзе һаман елмаеп миңа карап тора иде. Ул хәзер тәмамламаган, узган очрашуыбызда мин җырлаган бу җырның ахырын:

Онтылгач та бергә йөргән,
искә төшәр йоклаган, –

дигән юлларын мин сызгырынып тәмамладым. Аннан тәрәзәгә карап алдым. Көн әле якты. Урамда кызыл көз.

– Син җил кебек! – диде миңа Эльза шунда.

Мин эндәшмәдем. Ул тулып торган кызыл иреннәрен түгәрәкләде дә сузып кына сызгырып куйды:

– Җил тавышы киләме? – диде.

Мин эндәшмәдем. Тик, чынлап та, миңа аның сызгыруыннан кышкы җил авазы ишетелде. Тәнемә салкын таралган кебек булды. Тәрәз артындагы көз тәэсире бугай дип уйладым.

– Син ми-нем җы-лы ко-яш-лы кө-нем идең! – диде Эльза.

Мин җылынып җиттем. Ләкин эндәшмәдем.

– Син салкынайдың, – диде Эльза.

Мин эндәшмәдем.

– Син бик салкынайдың! Мин китәм! – диде ул.
– Кая китәсең? – дидем мин.
– Торналар киткән якка, – диде ул, шаярган да һәм шаярмаган да кебек. – Торналар белән китәм, – диде өстәп.
– Димәк, очасың? – дидем.
– Очам! – диде Эльза.
– Торналар кайтачак бит, – дидем мин.
– Мин кайтмаячакмын, – диде Эльза.
Мин көлдем.
– Шатланасыңмы? – диде ул.
– Ә шәһәр?.. Бу шәһәргә синнән башка... Аңа синсез күңелсез булыр, – дидем мин.
Эльза, урыныннан кузгалып, өстәле янына килде. Бераз вакыт көзгесенә карап торды. Аннан, миңа таба борылып:
– Мин шәһәрне сиңа калдырам. Син кара, аңа күңелсез булмасын! – диде.
Әллә миннән көлүеме? Ялваруымы бу? Үкенүеме? Тавышында – мең төсле мәгънә. Ләкин бу сөйләшүнең асылы миңа аңлашылып җитми иде. Шаяра бугай дип уйладым эчемнән. Тагын көлдем.

III

Ул шаярмаган.
Ул китте.
Хәбәрләшмәдек... Соңрак... Соңрак аны мин гел искә алдым. «Торналар киткән якка китәм!» – дигән иде. Шул чакта көлгәнем өчен мин аңардан бик оялдым, гафу үтенәсем килде... Аңа бәхетләр теләдем. Ә ул кайларда икән? Инде мин күпме юллар уздым, күп яшәдем. Аны очратканым юк... Җир бүген минем өчен әйтерсең Эльзаның кайчандыр мин белгән бердәнбер тәрәзәгә ап-ак пәрдә корылган бүлмәсе кебек кечкенә. Ә Эльза күренми.
«Торналар киткән якка китәм!», – диде... Ул көн артта, моннан еракта, яңа кышлар, язлар, җәйләр, көзләр астына күмелгән. Ул көнне бүгенге Ай да, Кояш та яктыртмый.
Хәзерге юллардан заманның авыр машиналары узганда, Җир дерелди, күптән күмелгән көн калтыранып куя: мин шуны һәрвакыт бөтен тәнем белән сизәм. «Торналар киткән якка китәм!» – дигән иде.

Без, кешеләр, бер-беребезгә охшаш,
хисләр төрле, әмма...
дөрлиләр.
Шуңа күрә генә дөнья якты,
якты көннәр, өйләр һәм илләр.

Янып йөри бездә сагынулар,
башта әллә нинди моңнар бар.
...Әллә нигә
бу елларда
гел төшемә керә
кызыл көзләр,
яна-яна киткән торналар.

*1969*

## БАКЧАСАРАЙ

Бакчасарай – Кырымда, анда елый торган һәйкәл бар. Ханнар сараендагы бу фонтан-һәйкәлне 1764 елда Гәрәй хан эшләткән.
Гәрәй ханның Диләрә исемле яшь хатыны була. Диләрәнең Кырым ханы кулына кайсы сугышта, ничек төшүе билгесез. Берәүләр аны – грузин кызы, икенчеләр – поляк кызы, өченчеләр чиркәс кызы, имеш, диләр. Ханның иң көчле мәхәббәте шушы гүзәлдә булган. Тик кыз бу язмышы белән килешә алмаган, бик тиз сулган һәм тиз арада дөнья куйган. Кайгылы Гәрәй хан үзенең чиксез кайгысын сурәтли торган һәйкәл эшләргә әмер биргән... Ул һәйкәлне Иран остасы Гомәр эшләгән.
Бу һәйкәлгә кайчандыр А.С.Пушкин кызыл чәчәк куя. Шул истәлекне яңартып, нәкъ Пушкин куйган урында хәзер дә гел кызыл чәчәк тора.

Саумы, Пушкин язган Бакчасарай!
Шаккатарлык серең юк сыман.
Күккә карап баскан һәр манараң
сызгырмыйча калган ук сыман...
Шушындамы яхшы атлар булган?
Илләр курыкканмы шушыннан?
Әйтерсең лә моңа җавапларның
чынына да ялган кушылган...
Өзек-өзек килгән аваз кебек
ерак ята инде ул заман.
Шул заманда инде Гомәр оста
Гәрәй ханны никтер алдаган.
Һәйкәл итәм дигән хан кайгысын,
яшьле итәм дигән күзләрен:
ә мин беләм, җанын һәйкәл иткән
ул Диләрә дигән гүзәлнең...
Җанга кушылып елый кызыл чәчәк,
Бакчасарай кушыла боларга.
Төне-көне елый яшь Диләрә,
ярыймы соң шулай еларга?!
Ике йөз ел буе яше тама –
күңелләрне уя икән лә!
Җирдән юкса аның көндәшләре
һәм Гәрәй дә күптән киткәннәр.
Болай озак елау авыр ич ул,
заман хәзер үзгә – бүтән бит.
Дәүләт дилбегәсен җуйган татар
инде тавышын артык күтәрми.
Мин ханнарга хәбәр китермәдем,
хан булырга монда килмәдем.
Күреп кенә йөрдем
узганнарның
әкрен генә
Җиргә иңгәнен...
...Сау бул,
Пушкин язган Бакчасарай,
без белмәгән серең юк сыман.
Күккә карап баскан һәр манараң
сызгырырга торган ук сыман.

*1973*

## КАРАДЫК ЛА КИЛЕП ДӨНЬЯГА

*(Бер сөйләшүдән өзек)*

– Сәлам, дустым!
Ярый очрап куйдың,
киләм әле тулып күңелем.
Чайпалмаска, чайпалмаска исәп,
бераз гына... сиңа түгелим.
Артык зарым-кайгым да юк үзе,
хис кыллары миндә нечкәрәк.
Эшем бара, хатын исән-имин,
бер уйласаң, тагы ни кирәк.
...Кызым үсә. Да?! Үсеп тә куя!
Бу охшап та үсә кемгәдер?!
Күптән түгел генә нәкъ мин иде,
бүген кайтып керсәм...
Күрәмен...

Сыздырыплар уйный урыс көен,
моң дәрьясы инде – дүрт ягы.
Нинди уйлар килмәс кыз балага,
скрипка елап туктады.
Күз тимәсен, кызым, кулларыңа,
яман күзләр булу хак, дидем.
Инде уйна берне үзебезчә,
бик тыңлыйсым килгән чак, дидем.
«Былбылым»ны уйна.
...Уйнамады...
Менә шулай, дускай! Ни дисең?
– Ни дим? – диде дустым, –
димәк, шулай,
әнә минем хәлне кара син.
Сагынасы булган бу Казанны
һәм... авылда яшәп каласы.
Әнкәм мәрхүм сүзе хак иде шул,
мине җиңде хатын киңәше...
Урамчарак әйтсәк, зверь инде,
элегрәк... Хәзер шәп яшим...
Өч малаем бар дип йөргән идем,
булмадылар миңа берсе дә.
Минем хисабыма үстеләр дә,
өчесе дә күчте күршегә...
Хет берсе дә минем телне белми,
җанны шулар ничек белсеннәр?
Инде киләчәктә берсен-берсе
танысалар ярый, мескеннәр.
Югалттылар менә этиләрен,
әбиләрен... бабаларын да...
Югалтулар юлы йотар инде,
югалтырлар инде барын да.
Аналарын гына сатыйм дисәм,
ул карчыкны хәзер кем алсын?!
Үзем, әйтик, яшьне табармын да,
баласы да булыр, аннан соң...
Без дәвамсыз буын, ахры, яшьти,
хет утырып ела, хет ятып:
баласызлар ялгыз – баласызга,
балалылар ялгыз – югалтып...
Синең кызны кичереп тә була,
Кыз барыбер инде ир ягы.
Ә малайлар?!
– Әй, малайлар булып
карадык ла килеп дөньяга.
Моң-зарларны
монда калдырыйк та
китик әле, дускай, икәү без.
...Кая барасыз, дип сорасалар,
белмибез, дик... Ә бит беләбез.

*1990*

## КАЙ ТАРАФТАН, КЕМ НӘСЕЛЕ БУ ҖАННАР?

Нәҗес чукыр карга булып сандугач –
ни кылырсың, тәкъдиреңдә шул булгач?
Кушып тәкъдир мин дә аз-маз эчкән чак,
тарих мең дә тугыз йөзне кичкән чак.
...Олы юлда минем арттан җиттеләр,

янәшәмнән шап-шоп атлап киттеләр.
Калмыйлар да, калдырмыйлар мине дә,
туган, диләр, юлдаш, диләр, дус, диләр.
Кай тарафтан, кем нәселе бу җаннар?
Тукайны да белмиләр, чукынганнар!
Минем эчкә сызылып кына шик үтә,
ни әйтсәң дә, башта затлы түбәтәй.
Костюм яңа, акча да бар кесәдә,
таласалар, әгәр «чишен» дисәләр?
Уйга килгән килде бермәл алдыма,
болар минем түбәтәйне алдылар.
Сатып аны, эчтеләр-исерделәр,
үземә дә бер йөз грамм бирделәр.
Туган, диләр, юлдаш, диләр, сал моны!
Аннан, диләр, салырсың костюмыңны!
Олы юлда бик кыен шул ялгызга,
мондый мәлдә иман булмый явызда.
Күзләрендә уйный минем киләчәк,
чишендерә, болар чишендерәчәк.
Мөртәтләргә җиңел генә бирелмәм,
салдырырлар костюм белән тиремне!
Сөяксез дә йөрәксез калдырырлар –
әмма болар кулы җитмәс рухым бар!
Исән-имин рухым әйтер берчакны:
– Йә, егетләр, өзик исәп-хисапны!
Ишеткән бар, ил малы илдә калмас,
Кайтарырлар – ир малы ирдә калмас:
гаҗәпләнеп ул көнне тарих күрер,
минем рухым боларны чишендерер.

*1997*

## РУСИЯ КИҢЛЕГЕНДӘ

Әйе,
җилгә
җайлы аңа
Русия киңлегендә.
Җил мәңгелек уй
йә җандыр,
бардыр мин-минлеге дә.
Килегез, кил әле,
җилләр,
уртаклашыйк уйларны!
...Күп уйларым
җил юлына
байрак итеп куярлык.
Туфрактан
түгел бугай без,
җилләрдән яралганбыз.
Урысча сибелгәнбез дә
татарча таралганбыз.
Безнең бүген, артка карап,
алга барган чагыбыз.
Чын хәлебез
Гимныбызда,
Гербыбызда чагылыр...
Җиттек җиде юл чатына,
юлны япкан... төнмедер?
Тагын нинди сугыш уты

төньяпманы күтәрер?!
Күзләребез, башларыбыз
тагы ниләр күрерләр?
...Төнлә дә...
Килегез, җилләр,
хәлебезне белергә.
Исән булсак
аңлашырбыз
урысча, хет татарча...
Хет җилләрчә,
хет җеннәрчә
сөйләшербез таңгача.
Хәтәр төндә русияле
йокламыйча да чыдар.
...Алда бит –
җил дә сизмичә –
мәңге йоклыйсыбыз бар.

*2000*

## ТАТАР ТҮБӘТӘЕ НИК КАРА ТӨСТӘ,
## ЯКИ ХОДАЙ ЯЗСА...

Ходай яза, әгәр язса,
бирә бит ул байлыкны:
татар иле – татарныкы,
рус иле дә аныкы!
Зур урыска бер генә ил,
һәм шунысы кыенрак:
ил үзәге томанлырак,
чикләре – артык ерак!
...Татарның
иле икәү дә...
җиңел түгел аңар да:
ике илгә ярый торган
көй һәм бию табарга!
Ике илнең шатлыгы да,
кайгысы да икәү ич.
...Бу илләрнең
шатлыгыннан
кайгысы зур икән ич!
Кайгырып ике ил өчен,
башы кайный татарның:
түбәтәен дә каралткан
кайгылы башы аның!
Ходай язса, бәндә күрә
тәкъдирендә ни барын.
Күрик әле, түзик әле,
яшик әле, дусларым!

*2000*

## ИДАРӘ ЧЫЛБЫРЫ

Үзгәрә дип күп яздылар,
үзгәрәдер – чындыр ул...
Шулай да, ничек дип әйтим,
вәйт озын да чылбыр ул!
Вәйт югары китә ул –
башәйләнгеч,

текә ул!
Иң түбәннән өскә хәтле –
арт ялауга корылган...
Йа Ходa! Без түбәннәргә
ничек түзеп торырга?!
Ничә күрәм күтәрелеп,
ялау да ялау һаман,
җитмәсә,
әле ыштансыз
һәм
тәһарәтсез
заман?!
Товарищлар!
Бу ни гадәт?
Килешми бу, кирәкми,
рас уйладык үзгәрергә –
ялашуны сирәклик!

*1989*

## АЛДАГЫ САЙЛАУЛАРДАН СОҢ

Сайлаулар узды,
туннар тузды, дисең инде син.
Шулай ул, энем Габидулла,
сайлау дигән мәсьәләнең
ике ягы була.
Сайлаучылар сайладылармы?
Сайладылар!
Сайланучылар сайрадылармы?
Сайрадылар!
Эшлиләр, нәтиҗәсе дә бар –
татар хәлен
шактый җайладылар.
Кибетләргә тулды
затлы туннар.
Тик затлы тун әлегә кемнәргә?
Сайланучыларга
һәм аларга җайланучыларга.
Урамнарны чыелдатып чапкан
затлы машиналар кемнәрнеке?
Сайланучыларныкы
һәм аларга җайланучыларныкы.
Ишегеннән чыккан исе
сине исертеп егарлык
затлы рестораннар,
чәчәк кебек чәчелгән
яңа өйләр,
якын һәм ерак илләрдәге
виллалар,
дыңгычлап доллар тутырылган
сейфлардан ачкычлар,
күкрәк киереп күккә менгән
очкычлар кемнәрнеке?
Сайланучылар
һәм аларга җайланучыларныкы.
Кыскасы, санаганнарым –
мәсьәләнең беренче ягы.
Аның икенче –
безнең тунга кагылышлы ягы –

сайлаучыларга кәҗә тоягы!
Алдагы сайлаулардан соң,
имеш, кәҗәсе дә була.
...Ни бит,
кәҗәсен нитеп, мин әйтәм,
туннарны ямарбыз,
энем Габидулла.

*1995*

## ГАРИЗА

Күп тыңладым акыллылар сүзен,
авызларын гына үбәсе!
Яшим хәзер хатынымны тыңлап,
Күптән кирәк булган, күрәсең.
Бу нәтиҗәм – алтмышымны узгач,
изге Тукай туган бу айда...
...Язам хәзер,
хатын әйтеп тора,
мин гариза язам Ходайга.
Бер Ходаем!
Тудырдың да Үзең,
Һәммәбезне Үзең карыйсың.
Кара инде ошбу гаризамны,
өч үтенеч анда барысы.
Беренчедән,
сәнгать нисбәтеннән,
тәмам ашты татар биеккә:
һәркем яза,
ясый,
уйный,
җырлый!
Ну күрсәттек инде биеп тә!
Һәрберебез Тукай бүләгенә –
зур исемгә лаек, валлаһи.
Бу исемне тагарга дип уйлыйм
бар татарга – уптым илаһи.
Искәрт, Ходай, түрәләргә моны,
берәм-берәм безне ваклыйлар.
...Икенчедән, сәясәткә күчеп,
Сиңа тагын мотлак серем бар.
Ирек балы кайный бит Казанда,
шактый усал булды куәсе.
Киртлә, Аллам, Мәскәү колагына,
мөстәкыйльлек бирә күрмәсен!
Шуны бирсә, халкым бүләк яулап
һәм кәнәфи бүлеп... үләчәк.
Ярый Мәскәү пока моны белми,
әгәр белсә – тиз үк бирәчәк.
Өлгерәчәк тиз үк арабызда
мәркәзебез башын кыючы...
...Хөр мәмләкәт –
истәлек ул безгә:
узганнардан туфрак
бер учлык.
Бүгенебез – сәнгатебез кебек!
Тик әз генә йөрәк ачына:
Казан бакчалары – эт бәдрәфе,
язын шулар кардан арчыла.

Этлеләргә салым салырлар да
баетырлар әле казнаны...
Һәм өченче – соңгы үтенечем,
сабыр-сабыр, хатын!
Язамын!
Үзем хәзер җәннәтеңне көтәм,
бер аягым гарше катында.
Бир исәнлек, Ходай, кызларыма,
татарларым вә урысларыма,
татарларым вә урысларыма,
вә глауный –
минем хатынга!

*1999*

## УРАЗА ЕЛЫ

*Русиянең пенсиягә чыккан
мөселманнарына*

Мин пәйгамбәр түгел, ә нигәдер
Күкләр миңа алдан сиздерә.
Пакь ураза аен тәмамларга
уйламагыз быел тиз генә.
Мең тугыз йөз туксан тугыз! –
бу ел
килде безгә изге ел булып.
Бу ураза елы! Кардәшләрем!
Уразага узыйк умырылып!
Мин Сусанин түгел,
шикләнмәгез,
иярегез минем артымнан!
Хатын-кызда гөнаһ күбрәк була,
җыелыгыз яныма, хатыннар!
Ир-атларга урын сезнең артта,
сакланыгыз әзрәк алардан.
Чалбар изүләре ачыклар күп,
берәүләрнең күзе аларган! –
Бу күренеш, хәер, картлыкка хас,
склероз-мазар булу бар.
Андыйларның илгә керәге юк,
иярегез миңа, туганнар!
Иярегез, кулсыз-күзсез халык!
Кипкән-сулган, әйдә калмагыз!
Изге елда чумыйк изгелеккә,
разый булыр газиз Аллабыз!
Аяксызлар, басып таякларга,
арбаларга утырып, әйдәгез!
...Юк, мин патша түгел,
шулай да сез
иярегез миңа һәммәгез.
Мең тугыз йөз туксан тугыз!
Әйе,
гөнаһлардан тәмам арыныйк!
Иман нуры эчик, без нур ашыйк,
нәфесе корсын
шакшы карынның!
Гыйнвардан соң февраль
килми хәзер,
калган марты-черты ай түгел.
Алда әйттем:

мин пәйгамбәр түгел.
Өстәп шуны гына әйтүем:
мин гап-гади юлчы,
юлдашлардан
ашыгыбрак кына баручы.
Пенсиям дә әле алынмаган,
алып килер арттан Маруся.
...Көтмик аны, әйдә атлыйк, халык,
оҗмах тарафына үтәбез!
Чиста кесә, җиңел карын белән,
шәт, быел ук барып җитәрбез.

*1999*

## КҮПЛӘР СОРАВЫНА БЕР ҖАВАП

Кайдан чыккан, имеш, кеше? –
күпләр шулай баш вата...
...Аналары су сибә дә,
Кызлары чәчәк ата.
Ни чыкмас та,
кайдан чыкмас,
чиксезлек бу! – шул кызык!
...Әнә дөлдел –
канатлы тай
очкан... йолдыз тамызып.
Түлке артык чуарлаган,
кичерик, яшьлектәндер.
Ни хәлләрдә хәзер үзе,
кай тарафка җиткәндер?!
Сылап киткән ул Галәмгә
Айны да, Кояшны да...
Кайдан чыккан, имеш, кеше? –
сораумы бу, йа Хода?!
Шул тай юеш җир тамызган,
яралгансыз шунда сез:
димәк, Алла бакчасында
кыймылдыйсыз һәммәгез.
Сез биектә һәм бөекләр! –
моны белү бик кирәк.
...Алла кушып бакча кипсә,
чиксезлеккә Җирне сипсә?!
Да-а-а, хәлегез хөртирәк.

*1999*

## ЧИКСЕЗЛЕК ҺӘМ КӨЗГЕ ЧЕБЕН ТУРЫНДА

Көзләр микән,
күзләр микән,
йөзләр микән
саргайды?
...Шагыйрь уе
чиксезлектән
чебенгәчә
тарайды.
Чебен-чебен,
ябышкан да
йоклый гына шушында.
Кышка кием кайгысы да,

ашау-эчү хәсрәте дә,
китап язу нияте дә –
берни дә юк башында.
Нәрсә аңа вокзалың да,
шан-залың ни, тәхетең.
Үзеннән чиксезлеккәчә
хәзер аның бәхете.
Шагыйрь түгел лә,
бу көздә
бул идең чебен генә!
...Шунда сүзне
төгәллим мин,
югыйсә сүгенелә.

*1995*

## ТАБУТ ХӘТЛЕ АЛТЫН!

*(Хатын-кызлар колагына)*

I

Ышанмагыз Русиянең
антына, сөйләвенә,
ах итеп,
чүгеп,
чукынып:
– Яратам! – дигәненә.
Өзелеп сез яратканны
алып китә белер ул.
Аны утка
һәм табутка
оста кертә белер ул.
Ышанмагыз, алданмагыз
Җиргәчә бөгелсә дә:
– Ялгышсам,
түлим –
саф алтын
табут хәтле! – дисә дә.

II

Ышанмагыз
шагыйренә,
чәчрәтеп
сөйләвенә:
су ярында балыкчы ул,
сез – аңа селәү генә.
...Балыкчының
зур ятьмәсе
сарайда чери икән.
Ятьмә сөйрәр
пәһлеваннар
пока
Чечняга
киткән.

III

– Кайтырла-а-ар! – дим,

чү, иярдем
Шәүкәт Гали моңына.
Ышанам бит шул шаянга,
сез ышаныгыз миңа.
Ышанмагыз Русиянең:
– Яратам!– дигәненә.
Ярата белми Русия,
ул
көчли генә белә.

*2000*

## ӘЙ, ШАЯН ТОРМЫШ...

*(Сәяси үзгәрешләр уңаеннан)*

Сәясәтләрен сатыйм,
аны күп ишеттек.
Искесен ишеттек,
тыңладык яңасын.
Авызларын гына
этләр яласын?
...Килеп җиттек.
Шушында,
гомер ахырында,
талдым төнге юлда.
Дөм караңгы монда.
Халык – кайнаша,
әллә кемнәр
кыймылдый
янымда:
һаман өмет өзмәүчеләр,
бәхет эзләүчеләр,
өметсезләр,
алдакчылар,
эчкечеләр,
караклар,
үтерүчеләр,
үлүчеләр...
...Мин урлый алмам,
үтерә алмам.
Качкын бәхетемне
язып табалмам –
дөм караңгы монда!
...Ул кайда,
кайда ул –
чын кыйбла?!
Нишлибез, халык?
Юлдашлар!
Эчкечеләр!
Караклар!
Безгә кай тарафка?!
Кай якка узабыз,
бәгырькәйләрем,
үтерүчеләр, үлүчеләр?!
Әй, шаян тормыш,
якамнан
кулыңны ал әле,
буасың бит,
җибәр! Җибәр!

*1996*

## ГАЯРЬ ТАТАР

...Бик күптән,
һай күптән
безнең татарны
карап торды,
барлап торды Мәскәү.
Сынап торды,
санлап торды Мәскәү:
булдыклы бит,
җай бит ул татар!
Әй аның түрәсе,
татарның түрәсе,
әз генә елмаеп,
бер генә үбәсе, –
май бит ул татар!
Сәйяр татар,
гаярь татар!
Онытма, Мәскәү,
татар барын.
Һәрчак әзер
татарларың.
Син:
– Сыйлыйм! – дисәң,
кунак булып барачак.
– Җигәм! – дисәң,
ул ат булып барачак.
Мылтык бирсәң –
солдат булып барачак.
Син дигәндә, Мәскәү!
Синең өчен, Мәскәү!
Әйтсәң татарга,
кушсаң татарга
энә
белән
кое
чокырга:
– Чукыныплар китим,
булдырам бу эшне! –
дип әйтер дә татар
һәм
чукыныр да.

*1995*

## УЗАР ЮЛЫҢ...

Атлый торгач– барыла да,
бара-бара арыла шул.
...Сәяси таң, сәяси кич,
әлҗе-мәлҗе сәяси юл.
Керсә шагыйрь сәясәткә –
әйбәт түгел, начар инде.
Сәясәттән качып булса,
бөтен шагыйрь
качар иде.
Качар иде –

качып булмый.
Узар юлың шушы булгач,
басасың да, аяк таела,
нидер чәчрәп
йөзеңә – лач!
Сәясәт соң ул ни-нәрсә,
ни булса да –
яхшы булмас!
Яшәешнең башыдыр ул,
тик шигърият башы булмас.
...Асыл йөзе сәясәтнең –
чын исеме – хәйләдер лә.
Ул илләрнең өстен – аска,
астын өскә әйләндерә.
Шигърияткә
тыныч күлләр,
ак үрдәкләр, камыш килешә.
Камышлыкка поскан көймә,
«Сөям!» дигән тавыш килешә.
Шулай кайчак күңелемә
тыныч моңнар йөзеп керә.
Каләм алсам –
аң җуярсың,
сәясәткә баш бәрелә.
Чума каләм сәясәткә,
һәм шакшы ис
җәелеп чыга.
Охшап калам
юылмаган
бәдрәфтәге
бер юлчыга.
Керсә шагыйрь сәясәткә –
язмау яхшы бу җәһәттән.
Араннан
качкан
айгырдай
качар идем сәясәттән.
...Качар идем – качып булмый,
узар юлың шушы булгач,
басасың да, аяк таела,
нидер чәчрәп
йөзеңә – лач!

*1995*

## КЫЛЫЧ ЙӨЗЕ БУЙЛАП

*(Казанның меңьеллыгы уңаеннан)*

Мин Казанның һаман барлыгына
ышанып та җитмәс бер кеше,
тик аның зур юлын – елмаюын,
көрәшләрен таныйм, күз яшен.
Мең ел гомер! –
кылыч йөзе буйлап!
Ничек узылган ул?
дигәндә, –
томырылып Казан үргә менгән,
үрмәләпләр...
төшкән...

түбәнгә;
калыр гына иде үр өстендә –
тәкъдиренә башка язылган...
...Өстә – Мәскәү,
денсез татар калган,
Иблис калган көлеп, кул болгап.
Тормыш, әйе, кызык –
чыны шулмы,
миңа гына шулай күренәме?
Ул үтәли һәм шәп-шәрә күренә,
кендегеннән генә күлмәге.
Мең ел элек монда мин юк идем,
бүген мин бар – бу шәп,
шәт, начар?!
Казаныма тагын мең ел теләп,
дога кылып яшим татарча.
Тик жәл, әнә хәер җыючылар
үзәгемә
утырып,
төртенеп –
гәрчә алар инде мең яшәмәс,
хәтта Бауман исеме сөртелер.
Чал Казанның
яшь байрагын
карыйм,
чынлыгына бераз шигем бар;
һәм җилләр дә алып бугазыннан,
җилтерәтеп – аны сыныйлар.
...Иртән ачсам
Казан радиосын –
ишетәм татар гимны газабын:
авызын Мәскәү учы кыса сыман,
кысылып... тына... көйнең азагы.
Көйне кысу – нәрсә...
Телне синең,
җанны кисеп була! Бик була! –
Тотып язмыш газиз илкәеңне,
бирсә башкисәрләр кулына...
Татар сүзен– үзен һәм Казанын
ташламаган бөек Мәрхәмәт, –
кылыч йөзеннән дә бүгенгәчә
исән китергән бит, и рәхмәт!
Мең ел элек, ярый, мин юк идем,
бүген мин бар – ярый анысы да:
– Үрдән урын сорыйм Казаныма,
ишетә күр мине, бер Хода!
Бир Казанга гомер, бир, Хода!

*2001*

## НИШЛИБЕЗ?

Югалту да бергә, табышлар да,
бер гаилә җирдә – ишле без:
нидер ачабыз да, нидер ябыла,
безгә хәвеф шакый... Нишлибез?
Хиросима хәле – безнең адым,
Грозныйда әнә безнең эз:
анда сандугачлар тилергәндер,
тилергәндер инде... Нишлибез?

Йолдызларга бару серен чиштек,
нәрсәнедер дөрес чишмибез:
рәхәт явар сыман иде күктән,
ишелә бит афәт... Нишлибез?
Галимнәрме булдык, залимнәрме?
Җирдә табигатьтән көчле без:
табигатьнең карынын ярып куйдык,
яралгысы кибә... Нишлибез?

*1996*

## КИЧЕР, АЛЛАМ!

Татарчалап сөйлим,
и бер Ходам,
син бит татарча да беләсең.
Инде сизгәнсеңдер кешелеккә
син җибәргән акыл кермәсен.
Фикер сикереше аз-маз булды,
гаурәтләр дә бераз капланды.
Зур өметең генә акланмады,
ботын чабып шайтан шатланды.
Күкне бүлә кеше, сугыш-суеш,
комың җитми җирдә комсызга.
Ил өстенә илләр ут ыргыта,
җәһәннәмең булып җир кыза.
Хәтер җуеп бара бу кешелек,
Адәм белән Хава онытылган.
Эттән туган кебек бериш нәсел,
бериш нәсел – әйтик, дуңгыздан.
Пәйгамбәрләр
алдан сизгәннәрдер,
качканнардыр шуңа биредән.
Оят бер эш кебек миңа бүген
хәтта шигырь язып йөрү дә.
Ике тиен бирсәң – дин алалар,
өч тиенгә аны саталар.
Бер-ике сүз әйтим урысча да,
Җирдә хаким хәзер сатана.
Кеше чыкмый пока колларыңнан,
тавык сыман алар, баш – этәч!
Авызын төясеңме акыл белән,
күз дә колак аша кермәгәч?!
...Үзең генә аңлап,
кичер, Аллам,
бик пышылдап сорыйм, син ишет:
– Каты башкаена Кешелекнең
куймыйсыңмы соңгы бер тишек?!

*1999*

## БӘЛКИ, АЛГЫ ЯРГА ҖИТӘРБЕЗ...

*(Сугыш фаҗигаләре, шәхес культы корбаннары аша узган гомерләрне уйлап әйтелгән шигырь)*

Без кичкәндә тормыш диңгезен,
Су түгел шул анда, кан иде.
Кан исенә дөнья исерде,
Чигәләрдә пуля биеде,
Гали затлар ауды чүплеккә,
Телдән, аңнан язып адаштык.
Йә милләтне милләт дөмбәсләп,

Аңга китерергә маташты...

Без кичкәндә тормыш диңгезен,
Ямьсезләнеп беттек имгәнеп.
Гарип уйлар-сүзләр кычкырдык,
Озак шулай аңга килмәдек...

...Тормыш диңгезендә әйләнмә,
Хәлебезне шунда шәйләдек:
Кан өстендә тордык әйләнеп,
Ярый әле шуны шәйләдек...

Инде, бәлки, аңга килербез,
Бәлки, алгы ярга җитәрбез.
Ул чор безне ничек каршылар,
Һәм кан исе бездән бетәрме?

*1996*

## АК КАПКАДА КАРА ШӘҮЛӘ

*(Татарстан мөстәкыйльлегенә каршы Россия суды чыгарган карар уңаеннан)*

Бу мин әле, күрше, әй, Русия,
Чамаларсың, шаять, син тавыштан,
Иле булып шагыйрь сөйли моны,
Сөйли, димәк, сиңа Татарстан.
Телебездә безнең уртак сүз күп,
Язмышлар да охшаш язылгандыр.
Алмаш-тилмәш кидек
бер күлмәк тә,
Ыштансыз да чаклар аз булмады.
Кочаклашып йөрдек кичә генә,
Миңа килен бүген шактый кызың.
Мөстәкыйльлек дигән чалбар кисәм,
Танымавың мине иллә кызык!
Яңа гасыр каршысына бастык –
Ак капкасы гына әле ябык...
Яла хөкем әйттең ялган судта,
Шуның белән нәрсә ачыкладык? –
Чын йөзебез безнең йөри икән
Барлык белән юклык арасында.
Җаннарыбыз ерак бер-берсеннән,
Чиксезлекнең ике тарафында...
Килешүләр язып, кул куешсак –
Беркетсәк тә аны йөзәр томда:
Без кичәге түгел,
Күзләр башка,
Үзебез юк хәтта күз артында.
Калдык ике бөек шәүлә булып
Әнә яңа гасыр капкасында:
Сул кулыңда тәре шәүләсе дә,
Пычак шәүләсе бар уң кулыңда!

*1996*

## КЕМ КУЛЛАРЫНА КАЛДЫРЫЙМ?

Син, Русия,
гел карадан
карага таба килдең...

...Кайчандыр
куллар чәбәкләп,
мин сине ак арбам итеп
таныган балаң идем.

Әнә шулай –
мин күргәнчә –
калуың кирәк иде!

Искәртүчең булмагандыр
алай калыр юл барын.
Юктыр ак фәрештәләрең,
ак уйлы диндарларың.

Сәясмәннәрең
уенны
уеннан арттырдылар,
илтеп кайнар нокталарга,
билеңнән батырдылар.

Шул нокталар –
нокта булса
беркөнне
тарихыңа,
күпме «яңа руслар»ы өчен
булачак кызык кына!

Тик миндәй иске татарга
кызык күренми бу, ә?!

...Күренгәне
көрсендерә,
җанга тозлы моң сибә:
үз дә, чит тә,
бик таныш та,
бик сәер син, Русия.
Хакимнәрең,
галимнәрең –
сәер уйда барчасы.
Шуңа күрә ут борынлы
бронядуңгызларың синең
сөрә күрше бакчасын.
...Очар кошлар
аунап яна,
утырып...
яна...
гөлләр...
Өстә бии боргалаклар,
аста бии
исерекләр,
көрәкләр
һәм
каберләр.
Куркыныч монда туу да,
тудыручы булу да.
Канга,
бауга, күз яшенә
балаларың буыла.

Шуларны көйләп тә төяп,
кайдук җитәрбез икән?
Минме соң ул – алдан сөйрим,
кемнәр ул – арттан этә?

Сабан тарткан тайлар хәлен
үзем җигелеп белдем.
Шулай да, шөкер,
исән-сау
шушы яшемә килдем.
Җитмешне узам, Русиям,
китеп барам, каласың!
Кем кулларына калдырыйм
син хәерче арбасын?!

*2007*

## УЛ ЕЛЛАР...

Яратуның күзе булмый, диләр,
була икән һәм бик зур була.
Эчендә нур була, тышында нур,
зур күзләрдә җылы нур гына!
Шул зур күзләр
салкын акыл чорына
җылы бөрки алган өчендер,
мин тормышта хәтта кеше ярын
яратканнарны да кичердем.
Кичерүче булды үземне дә –
шулай кушты безгә ул еллар.
...Чәчкәйләрен
кара байрак итеп
китсенмени Җирдән ялгызлар?
Онытмадык шуңа аларны да,
гөнаһтыр бу– гөнаһ санасак.
Тик гөнаһсыз булыр идекме без,
әгәр берне генә яратсак?
Йөрмәдек ич берәм-берәм генә,
бергә-бергә бәхет эзләдек.
Һәм яктыртып барды еллар төбен
яратуның якты күзләре.

*1984*

## КӨН КИЛДЕ

Күкрәгенә чәчәк кадап көн килде,
Көннең чәче җылы йомшак җил иде.
Самолетлар дөньяга салды хәбәр,
И гүзәл көн, и якты көн, мәрхәбә!
Профессорлар папкасына нур төште,
Студентлар лекциягә җитеште.
Каравылчы кайтып ятты йокларга,
Станоклар шауладылар цехларда.
Ак кирпечләр диварга әверелде –
Төзелешләр болыннарга күренде.
Кемдер көннең чәчәгенә кагылды,
Кемдер көннең чәчләренә кагылды.
Сузып кына: «Әнкәй!» – диде бер тавыш,
Су буенда шәрә тәнле буталыш.
Самосвалдан тузан тавы ишелде.

Берәү япты «Жигули»е ишеген.
Ишетелде исерек ир көлгәне,
«Тукта!» – диде берәү, әйтте көнгәме?!
Көн йөгерде, йөгерде– туктамады,
Урман, кырлар көннең чәчен тарады.

*1973*

## КАРАП ТОРА...

Бер уйласам – күп шикелле сиңа сүзем,
Бер уйласам – юк шикелле сиңа сүзем;
Инандырып дөньяда бар икәнемә,
Карап тора миңа таба ике күзең.
Сизәсең дә, сизмисең дә, сеңлем, шуны:
Мин олгаеп җитдиләнгән кеше инде;
Җитдиләргә гашыйк чагың җиткән синең, –
Үзең шаян, ышанучан һәм сөйкемле.
Мин мөкиббән синең мондый сыйфатыңа,
Тик, валлаһи, була алмыйм синең кебек;
Адаштым мин, төзәлмәскә ялгыштым мин –
Синнән алда җиргә килеп, дөнья күреп.
Инде сиңа нәрсә сөйлим, сөйләр булсам?
Синең белән сөйләшмәсәм, ничек түзим?..
Яшьлегемнән ике якты хәбәр булып
Карап тора миңа таба ике күзең.

*1970*

## КАРА АТ КЕБЕК БУ ТӨННЕ...

Кайчак туям дөньясыннан,
ак көннәр шау-шуыннан,
газеталардан, хәйлә-хәвеф,
илләр ил ашавыннан.
...Ашыгам төнгә керергә,
төн генә көнем була.
Бу төнем– икенче дөньям,
беренче көем була:
бар да үз монда– Парижы,
Йолдызым, Камышлысы.
Калмаган бәхәс-низагның
гаугалы, тавышлысы...
...Аяк очка басып узам
югалган елларыма –
бөекләр, яшәү турында
беркатлы уйларыма...
Юк монда күзе, куллары
канга баткан залимнәр.
Кош оясы кебек Җиргә
шатлык ташый һәр һөнәр.
Мәхәббәт ватылмый монда,
аңа бик җайлы монда.
Хәтта мин җуйган матур да
һәм кызым да янымда.
Аяк очка басып өчәү
чыгабыз күперләрне...
Касады-су чайпалмый да
Сокка илтә серләрен.
Иркәләп күңел киңлеген,

тынычлык, ләззәт исә...
Без – бәхетле! «Әй, Кешеләр!
Сез бәхетлеме?» – дисәм.
Йөрәгемә көн сизелә,
сизелә ак басымы.
Кара ат кебек бу төнне
тышаулап тотасыңмы?!
Йөгәнләп
тотарсыңмы?!

*1977*

## ЕРАКТАГЫ ЗӘҢГӘР ОФЫГЫМ БУЛ

Син каршымда горур кыя булма,
Булма нәни чишмә яктысы...
Еракта гы зәңгәр офыгым бул,
Тормыш таңым синдә яктырсын.
Юлларымда көзге чәчәк булма,
Булма язгы ярсу ташкын син...
Еракта гы зәңгәр офыгым бул,
Йөрәгем гел сиңа ашкынсын.
Кәккүк булып кырда кычкырсам да,
Әйтмә, җуйды бу, дип, оясын...
Еракта гы зәңгәр офыгым бул,
Сиңа төшсен гомер кояшым.

*1971*

## ӨЧ УРЫН

Сәгать туктап калды төнге өчтә,
өч бүлмәле өйдә – өч урын...
Бер бүлмәдә йоклый чибәр хатын,
өстен-башын ачып, туздырып.
Чумып йомшак мамык түшәгенә,
икенче бүлмәдә ир йоклый.
Һәм өченче бүлмә... иркен бүлмә,
бу бүлмәдә – башка, зур йокы.
Ир белән хатынның мәхәббәте
ята монда – сары диванда.
Кемдер сүгенә тышта, кемдер килде.
Кемдер сорау бирде.
Кем анда?!
Шул арада өйгә тәрәзәдән
кереп тулды сәер кешеләр,
мөгезлеләр алар, ут теллеләр,
эт колаклы һәм эт тешлеләр.
Сукырлар да, ахры, капшаналар,
кеше түгел икән үзләре:
болар бу ханымның иргә әйткән
ачылардан-ачы сүзләре.
Болар ирнең хәтәр җавап сүзе,
ишәйгәннәр икән күптәннән.
Авызлардан чәчрәп төшү белән
тәпи китеп ныгып җиткәннәр.
Җыелдылар бар да зур бүлмәгә,
такта, кадак ала килгәннәр.
Ир белән хатынның мәхәббәте
бүген үлгәнлеген белгәннәр.

Җитез генә табут ясадылар,
кәфенләүне тәмам иттеләр...
Мәхәббәтнең мәетен нишләтәсең,
күмәр өчен алып киттеләр!
Сәгать туктап калды төнге өчтә,
өч бүлмәле йортта – өч урын...
Кара күзле төннәр шаһит моңа,
мәхәббәтсез урын – буш урын.

*1973*

## ЯЛГЫШ ЯРАТТЫМ

*(Шаяру түгел)*

«Тиле яшьлек!» – иске әйтем,
тик яшьлеген кичкән һәркем
уза аны яңартып:
мин дә
тиле яшьлегемдә
бер тилене яраттым.
Туң җаннарның боз колагын
эретерлек кызчык ул.
Күкрәгемә кунып сайрый
тулай торак кошчыгы!
Яз түгел бу, көз дә түгел,
чатнап торган кыш ае.
Сайраштык та саташтык бит,
очты... маржа-тургаем.
Барып кагам бүлмәсен дә,
туңам тәрәз катында.
Уты янмый – йоклаганмы,
иртән генә кайтырмы?
Өмет яна– сары башны
табалырмын шикелле:
сөяп түрем почмагына,
табынырмын шикелле!
Шулай ялгыш яраттым шул,
авызкае – бөрмәле...
Күрәм бермәл ачылганын
мин какмаган бүлмәнең.
Күз шар булды,
өнсез торам – әйтерсең лә бер карак...
...Ә ишектән елмаючы –
                    маржалардан маржарак!
Бүлмәсе җәйләрдән җылы,
йа Раббым, ни ояты?!
Картлыгымда керә төшкә
тиле яшьлегем юлына
аркылы яткан хатын.
– Таныйсыңмы,
мин исән! – ди, –
кил яныма,
тилемсәм! – ди,
моңландыра, уйландыра,
чукындырып китәр иде,
комачаулый таң ату.

*1999*

УЙНАБРАК УЙЛАНУ

*(Өчләм)*

I

*(Өйләнеп йөргән чакны искә алу)*

Нинди икән сездә кызлар,
бездә шундый кызлар бар!
Үбешергә иренең бирсәң –
суырып,
башыңны йотар...
Шуңа талдай бер билкәйгә
салдым бары кул гына:
– Йотар, йотар, –
дип шикләндем,
һәм
нәкъ шулай булды да.

II

*(Өйләнгәч тә матур яшәлгән)*

Ике күкрәк –
килә күкрәп, изү ачам яшененә:
шактый кыска
буем белән,
шактый озын
яшем белән
изү ачам яшененә.
Яшеннәрдә,
күкрәүләрдә
шомланып та
калыр кеше.
Шомланмыйк ла,
шайтан йоклый,
безнең тормыш –
шайтан төше.
Шайтан төше –
безнең Дөнья:
әмма яшәү – барыбер рәхәт.
Рәхмәт инде
әткәемә,
мине тапкан
әнкәемә!
Яшен тотып
яшәгәнгә
үземә дә
бик зур рәхмәт!

III

*(Шөкер, бүген дә без бергә)*

Минем дуслар әйбәт кенә түгел,
әйбәтләрдән-әйбәт ир-атлар.
...Ресторанга дисәм?
Ни бит әле,
өйгә чакырырга исәп бар.
Чакырырга кирәк үзләрен бер,
килгәч күңел шундый карарга.
Шәрә туташ кебек шәрә бүлмәм
бик ошарга тиеш аларга...

Чакырырга кирәк үзләрен бер,
зур байлыгым – кызым, алтыным.
...Аннан
һәр дусымның хатыныннан
матуррак бит минем хатыным.
Чакырырга кирәк үзләрен бер,
берәр ярты алып һәр дуска.
Шәп закуска алам,
егәр бер дус
акча биреп торса бурычка!

*1995*

## ТӨШЕП ЮГАЛМА ИКӘН

*(Өч хатын-кыз тавышына бер җыр)*

«Иркәм, иркәм», – дигән булды,
карады күзләремә.
Шикәр иде, ширбәт иде,
бал иде сүзләрендә.
Ай иркәм,
вай иркәм!
Яр сөяргә ашыкма да,
соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәҗәсенә
төшеп югалма икән.

«Иркәм, иркәм», – дигән булды,
баш куйды иңнәремә.
Мәңге янар учак булып
урнашты йөрәгемә.
Ай иркәм,
вай иркәм!
Яр сөяргә ашыкма да,
соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәҗәсенә
төшеп югалма икән.

«Иркәм, иркәм», – дигәненә
нигә ышандың, диләр.
Өйләнде дә хатыныннан
инде бушамый, диләр.
Ай иркәм,
вай иркәм!
Яр сөяргә ашыкма да,
соңга да калма икән.
Мәхәббәт дәрәҗәсенә
төшеп югалма икән.

*2001*

## КИЧКЕ БАКЧАДА

*(Биш тавышка бер җыр)*

– Бакча аша киләсең,
гөлгә охшап калгансың,
Гөлбирә.
Кемең болай сыйлады соң,
бераз гына салгансың,
әйе, бераз салгансың,
Гөлбирә.

– Яшь кенә бу димәссең,
авыл кызы димәссең,

Гөлбирә.
Изүеңнән түшең ташый,
каптыр өске төймәсен,
әйе, каптыр төймәсен,
Гөлбирә.

– Юл уңына сыймыйсың,
сулына да сыймыйсың,
Гөлбирә.
Анаң болай булмагандыр,
сиңа нәрсә булды соң,
әйе, нәрсә булды соң,
Гөлбирә?!

– Чәчкәйләрең чәчелә,
сибелә күз карашың,
Гөлбирә.
Тагын бераз сыйланырга
кемне эзләп барасың,
әйе, эзләп барасың,
Гөлбирә?!

– Бару юлың алдадыр,
кайту юлың кайда бит,
Гөлбирә.
Үзең җирдә шикелле дә,
әйе, җирдә шикелле дә,
аякларың айда бит,
Гөлбирә... Гөлбирә...

*2001*

## ХОДАЙ СИҢА КҮП БИРГӘН

*Казанда яшәүче танышым*
*Мария Васильевнага*

Күлмәгең тар, түшең киң,
иреннәрең ут кына.
Куркыта да, суыра да
күзләреңнең упкыны.
Синең зәңгәр упкының
йөз әбиең мирасы:
сизәсеңдер исемнәре
бер шигырьгә сыймасын.
Упкыныңда – морзалар,
татар арба-атлары...
Милли ярыш мәйданының
сез тиңдәшсез затлары.
...Әнә берәү мәйданда:
– Мин татар! – дип очына.
Мүкәләп ул төнлә килер
синең аяк очыңа...
Рус иленең көче – сез,
кабыгымы, төшме сез?
Күрше илләр өстенә дә
бер менсәгез – төшмисез!

Ах, Мария, Мария!
Мария Васильевна!

Мин сиңа асылынмыйм ла,
Син миңа асылынма...
...Ак кәбестә – артларың,
үкчәләрең – кадактыр:
Бикбулатка, Хәйруллага,
Зәйнуллага кадап тор.
Малаена төртеп ал,
яше чыкса – сөртеп ал.
Аннан төпсез упкыныңа
чумганнарын карап кал.
Чуммаучылар очраса,
чукын да бер, ярлыка –
гыйбрәт өчен кирәк әле
алар минем халыкка.

Ходай сиңа күп биргән,
Өеп биргән – азсынма.
Ах, Мария, вах, Мария!
Мария Васильевна!
Күлмәгең тар, түшең киң,
иреннәрең ут кына.
Куркыта да, суыра да
күзләреңнең упкыны.

*2001*

## ТЕНТҮ, ЯКИ БЕРДӘНБЕР ҖӘЙ

Уз бүлмәгә, бу мин генә,
син дә үзең шикелле.
Ямьсез дә син үзең кебек,
нәкъ үзеңчә – сөйкемле.

Дөнья тар ул, очраштыра,
ник очрадың кыш көне?
Әллә хәзер гел кыш кына,
чын җәйләр дә беттеме?

Бар иде бит минем җәем,
кайнар учак... һәм чәе –
соңгы җәйләр арасында,
әйе, бердәнбер җәем!

Исеңдәдер – юлың ялгыш
минем юлга юлыкты.
Син яшь идең.
Бүгенгедәй,
мин карт җүләр ул чакта.
Учак янды чарт-чорт итеп,
шытыр-шытыр син көлдең.
Юк, көлмәдең, син ул җәйгә
шигырь булып бөркелдең.
Минем дә җан шигъри иде,
шактый күпне сөйләттең.
Тыңладың да... Үзең миңа
хәтәр сүзләр дә әйттең.
– Карт шайтан! – дип,
әчеттереп,
күңелемә чәнчедең.
– Ата белән мин сүз белән!

Үтерәм сине! – диден...

Мин сүз белән тенти беләм,
ярый, артык җәелмим:
– Сал туныңны,
хәзер тентим,
кай җиреңә яшердең син
шул бердәнбер җәемне?!

*2001*

## ЯРАТУГА ХӘТЛЕ

Бик яратып бардым,
бардым бераз соңлап.
Бик сагынып бардым,
бардым бераз соңлап.
«Соңламагыз!» диеп
киңәш бирә алам. –
Тормыш әнә шулай
һәм шул килеш кала.
Барсагыз да йөгереп,
минем кебек итеп.
Барсагыз да очып,
мине күпкә үтеп:
яратуга хәтле
ара шундый ерак,
яратырсыз соңрак,
сагынырсыз соңрак.

*1984*

## ЯРАТАМ ӘЛЛӘ НИЧЕК...

Яратам шул бу дөньяны,
яратам әллә ничек:
утлар эчеп яратам да
яратам бозлар кичеп.
Илүсәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!
Иртәләрем, көннәремә,
төннәремә таң калам:
мин дөньяда ямьсезгә дә
«матурым» дип әйталам.
Илүсәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!
Узмас сыман ачылары –
уза да әллә ничек:
яратам шул бу дөньяны,
каласын белгән өчен.
Илүсәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!

*1986*

## ЕЛМАЙ ӘЛЕ БЕР ГЕНӘ

Ниләр булды үзеңә,
ике кара күзеңә?
Мә кулъяулык, сөрт яшеңне,
сөйлә серең үземә.
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Йөзең түгәрәк кенә,
үзең күбәләк кенә.
Керик әле бакчаларга,
йөрик бергәләп кенә.
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Гөл биреп юатыйммы,
биримме сабырлыгым?
Буйларыңа туры килми
уйларың авырлыгы...
Матурым, гөл генәм,
елмай әле бер генә!
Акыллым, гөл генәм,
елмай инде бер генә!

*1990*

## КҮБӘЛӘК АЛАННАРЫ

Җәйләрем, җәй гөлләрем,
Түгәрәк аланнарым,
Ак каен урманнарында
күбәләк аланнарым.
Уйный әле, белми әле,
күрми күбәләкләрем –
әйлән-бәйлән итеп кенә
югаласы көннәрен:
аланнары аръягында
яшерелгән көзге бар.
Яшерелгән көзге түгел,
алда гомер көзе бар.
Чайпала зәңгәр гөлем,
түгелә алсулары.
Сизәдер сары чәчәкләр
көзләргә баруларын.
Уйный әле, белми әле,
күрми күбәләкләрем –
әйлән-бәйлән итеп кенә
югаласы көннәрен:
аланнары аръягында
яшерелгән көзге бар.
Яшерелгән көзге түгел,
алда гомер көзе бар.
Без дә күбәләк әле,
аланнар күрик әле.
Күбәләкле бу аланнар
төшләргә керер әле.
Уйный әле, белми әле,
күрми күбәләкләрем –
әйлән-бәйлән итеп кенә
югаласы көннәрен:

аланнары аръягында
яшерелгән көзге бар.
Яшерелгән көзге түгел,
алда гомер көзе бар.

*1998*

## ЯЛГЫЗЛАР МОҢЫ

Ак кар асларында ялгыз куян,
җилләр җиргә түшәп кар сырган.
Ялгызларга гына юлдаш моң бу,
ялгыз тавыш кирәк бу җырга:
язган безгә ялгыз булырга.
Без җилләргә ялгыз кермәс идек,
туры килде ялгыз калырга.
Ялгыз тавыш кирәк әй бу җырга,
ялгыз тавыш кирәк бу җырга:
язган безгә ялгыз булырга.
Ялгызларга гына юлдаш моң бу,
ялгыз тавыш җитә бу җырга:
безгә язган җирнең өстендә дә,
астында да ялгыз булырга...

Язган безгә ялгыз булырга...

*1994*

## КЫЗЫЛ ЧӘЧӘК

Сагынуларда янамын, дип,
Кемгә дә сөйләмәдем...
Мин һаман сине көтәмен,
Мин һаман сөям әле...
Аһ, юлларың минем янга
Килмиләр дә килмиләр.
Сорыйлар бит танышларым,
Нигә килми ул, диләр...
Үтте кышым, сине көтеп
Җәйләргә кердем инде...
Сиңа гына бирер өчен
Гөлләр үстердем инде...
Су сипсәм дә, ялкын үсте,
Үсте гел кызыл чәчәк.
Синең юллар минем янга
Киләчәк ул, киләчәк.

*1971*

## ТЫНЫЧ ТӨН

Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда.
Кое тора урам уты алдында.
Җанга ничек тынгы килсен ди хәзер,
җанга ничек тынгы килсен ди хәзер?!
Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала
чылдыр-чылдыр су ала.
Йөрәгемдә тау ватарлык көчем бар,
таңда торып юл чыгасы эшем бар.
Ялгыз китү җиңел түгел бит инде,
ялгыз китү җиңел түгел бит инде.
Үсеп җиткән ак күлмәкле кыз бала

чылдыр-чылдыр су ала.
Тыныч төн бу, җәйге төн бу авылда.
Болай соңлап ник инде су алырга?
Алган суы күңел утын сүндермәс,
дәрьялар да күңел утын сүндермәс!
Ак күлмәкле, кара кашлы кыз бала
чылдыр-чылдыр су ала.

*1972*

## ЧӘЧӘК ТУЛЫ БАЛ ИКӘН

Алып килдем сезгә гөл,
күңелемдә гөл йөртәм.
Касады-су буеннан –
алып килдем яшьлектән.
Гөлләр анда гел чәчәктә,
язлар анда гел чәчәктә,
чәчәк тулы бал икән лә,
анда гына кал икән.
Алып килдем сезгә уй,
күңелемдә уй йөртәм.
Касады-су буеннан –
алып килдем яшьлектән.
Анда көнең чәчәк ата,
төнлә күгең чәчәк ата,
чәчәк тулы бал икән лә,
анда гына кал икән.
Алып килдем сезгә моң,
күңелемдә моң йөртәм,
Касады-су буеннан –
алып килдем яшьлектән.
Анда бар да чәчәк икән,
сөйгән яр да чәчәк икән,
чәчәк тулы бал икән лә,
анда гына кал икән.
Анда гына, анда гына
гомерлеккә кал икән дә,
калып булмау бар икән.

*1981*

## ШӘТ...

Сүндер утны,
Ялыктым мин
Бүген көн яктысыннан:
Әле һаман кешеләрнең
Күзләре бездә сыман.
Сүндер утны, бүлмәбезгә
Бәреп кара төн тулсын.
Кайсыбыз карт, кайсыбыз яшь –
Күренмәсен, онтылсын!
Сүндер утны, сүзләр генә
Иркәләсен күңелне.
...Һәм бу төндә ут сүндергән
Бер без генә түгелдер.
Сүндер утны, сөйләсеннәр,
Сүндерделәр, дисеннәр.
Сөенгәннәр сөенсеннәр,

Көенгәннәр көйсеннәр.
Сүндер утны, яшьлекнең, шәт,
Шигъри аслы шулдыр ул:
«Янганны сүндерә алу
һәм сүнгәнне яндыру».

*1971*

## ОНЫТЫЛЫП БАРА ИДЕҢ

И беренче мәхәббәтнең
якты да хәтәр чагы!
Онытылып бара идең,
искә төштең ник тагы?
Еракларда калып яктың,
ара һаман үсте лә...
Инде картлык болытлары
өелә гомерем өстенә.
...Онытылып бара идең
Һәм шулай кирәк иде.
Син ярып узган җанымның
ярасы тирән иде...
Тагын кагылдың бит әле
җанымның ярасына –
күкләрнең
күкрәген ярып
яктырган яшен сыман.

*1990*

## БОЛАЙ ТҮГЕЛ ИДЕМ ДӘ БИТ...

Болай түгел идем дә бит,
Үзгәрдем шул инде мин;
Һәр тар юлны тар димимен,
Һәр киң юлны киң димим.
Болай түгел идем дә шул,
Үзгәрдем бит инде мин;
Һәр ялгызны ялгыз димим,
Һәр парлыны пар димим.
Мин болай түгел идем лә,
Нишләттең мине, дөнья? –
Дөреслекне аңлаттыңмы,
Керттеңме ялгыш юлга?

*1972*

## ГОМЕР ЯЗЫНДА

Аларның гомер язында,
чәчәктә, нурда чагы...
Аларның әле кечкенә,
шулай ук зур да чагы.
Кисәләр – кием килешә,
йөрсәләр – йөрүләре.
Күңелләре юри безгә
үтәли күренәдер.
Бераз йөгәнсезләр димме?!
Әйдә, шулай булсыннар.
Язгы суның ярдан чыгып

шауларга да хакы бар.

*1971*

## БАНУ ӘБИ, ТУГАНАЙ

Йортларында керләре,
тәрәзәләр аша карап кына,
күрә икән кемнәрне?
Бану әби, туганай,
Бану әби, тулган ай, –
хәтерли ул кемнәрнедер
каршылаган көннәрен.
Ачык булыр ишеге,
иркен булыр түрләре...
Түрләренә тукталып ул
уйлый икән кемнәрне?
Бану әби, туганай,
Бану әби, тулган ай, –
хәтерли ул кемнәрнедер
каршылаган көннәрен.
Турагандыр икмәген,
юкадыр телемнәре...
Телем-телем теленәдер
аның да күңелләре.
Бану әби, туганай,
теленә ул тулган ай, –
хәтерли ул кемнәрнедер
каршылаган көннәрен.

*1982*

## ҮТӘЛИ ҖИЛ

Каршыңда ялгызлык
үтәли җил булды,
җаныңа үтеп җил тузгыды.
Ел сыман тоелган
ул суык төннәрне,
әнкәем, ничекләр уздырдың?
Ничекләр уздырдың,
әнкәем, көннәрне,
җилләрне ничекләр кичтең соң?
Үтәли җилләрдә
көн иткән ялгызны
бик соңлап аңлый шул баласы.
Карыйм да үткәнгә,
үкенеч икән лә:
соңладым, мин дә бик соңладым.
Бүген үз каршыма
үтәли җил килә –
бу җырны мин шунда җырладым.

*1997*

## ӨННӘРЕМ ҺӘМ ТӨШЛӘРЕМ

Юлым артта, гомер артта,
барсы да узды кебек.
Уйлап шуны, дөрләп куям
ак каен тузы кебек.

Мин бу Җирдә пакь эз генә
калдырыйм дигән идем.
Сукмады бит санга язмыш
мине һәм татар илен.
Шуңа, бәлки, сансызланып
йөргәннәрем булгандыр.
Болганганым, болгатканым,
керләнгәнем булгандыр.
Пакь эз генә калдырырга
хыялланган җан идем.
Язмышыма кол булсам да,
хыялыма хан идем!
Шуңа гына, шуннан гына
җирсүләр, җиңүләрем.
Еракларда юлдаш иттем
гел хыялым җилләрен.
Учларыма көлеп яуды
көннәрем-көмешләрем.
Әмма никтер өннәремнән
матур булды төшләрем.

*1992*

## СИН АКЫЛЛЫ

Без сөйләштек:
син акыллы,
күп белгән-йөргән кебек.
Хәтта син минем акылның
офыгын күргән кебек.
...Үзеңчә кара син миңа,
син үзеңчә уйла да...
Офык артында берни дә
булмас диеп уйлама!

*1974*

## САРЫ КӨЗ

И сары көз!
Талларымны,
тауларымны тарадың.
Сары сөрән салып бүген
тәрәзәмнән карадың.
Әй сарысың, бигрәк сары:
хәлем шулдыр, күрәсең.
Дусларымның хәле хәзер
шулай була күрмәсен.
Ышандыр, көз,
син бу елда
мине генә,
бүген генә
бу хәлемдә күрәсең?!

*1997*

## КИТӘСЕЛӘР...

Искә алсаң, шулай инде,
миңа дуслар килә иде.

Язлар килә, яз күгенә
чигелеп кошлар килә иде.
Барысы да килә иде,
хәзер бар да китә генә.
Кошлар китә, яфрак китә,
чәчәкләр дә китә менә –
барысы да китә генә.
Гөрләп китә, гүләп китә
йә сызгырып китә менә.
Хет капланып ела хәзер
гомер тавың итәгенә,
барысы да китә генә.
Китә әнә кышлар булып,
әнә китә җәйләр булып.
Йөгереп китә малай булып,
шаулап китә явым булып.
Китә кинәт йә тәгәрәп,
йә ишелеп, йә убылып.
...Әйләнмәле давыл уза
бөтерелеп-бөтерелеп...
Ни аласыз, әйләнмәләр?
Алыгыз ла, бетерегез!
Тезеп элгән пакь керләрем
давыл белән китә генә!
Канат җәя кызыл чалбар,
ак күлмәкләр күтәрелә!
Сер булып та, кычкырып та
китә белә китәселәр.
Төн булып йә көн булып та
китә белә китәселәр.
Бик ашыккан туташ булып,
туп-туп басып китә менә!
...Китә гомер,
үтә гомер,
үтә генә, китә генә.

*1987*

## НӘРСӘ ГАҖӘП?

Сәер генә еллар була, юллар була,
Үзем дә мин әллә нинди, сәер бәндә.
Язны-көзне карап тормыйм, чыгам юлга,
Нәрсә гаҗәп, нәрсә булмас юл йөргәндә!
Юл юл булыр, тигез булыр, үргә менәр,
Түбән төшәр, бер киңәер, бер тар булыр;
Мәрхәмәтсез чокыр ятса минем алда,
Минем янда мәрхәмәтле дус табылыр.
Төшмә, дияр, бәлки, аны тыңлармын да,
Төшеп чыкмый калганнарны беләмен мин.
Нәрсә гаҗәп, бәлки, әле ул чокырга
Төшәрмен дә сау-сәламәт менәрмен мин!

*1971*

## ЯЗГЫ ТУКАЙ ЯНЫНДА

«Ачылды тау...» – диләр язда,
Тау түгел, йөрәктер ул! –
Язда шулай бер уйлану,

Яңару кирәктер ул...
Яшәешнең баш көненнән
Бүгенгәчә– ни заман!
Язга күзсез кергәннәр дә
Килерен ак уйлаган.
Бик ерактан шәйләнгән ак
Бу язга да ялгана.
...Күрсәгез кара күбәләк,
Юрамагыз яманга.
«Өстегезгә актарылып
Күк төшеп килә!»– дисәм,
Иелмәгез, таралмагыз! –
Шунда гына сез исән...
«Кысыла офык боҗрасы,
Ул элмәк икән!» – дисәм,
Анда гасырлар чайкала, –
Без аякта, без исән.
Йөз кабат яз килеп тагын,
Инде исән булмасак...
Җирдә язлар, язда шигырь
Һәм Тукайлар булачак! –
Язда яңару кирәк ул!
«Ачылды тау...»– диләр язда,
Тау түгел ич, йөрәк ул.

*1977*

## КОЕГЫЗДАН СУ АЛДЫК

Озын юлда сусадым, су бир, сылу, түләрмен:
итәгеңә тотынган
малаеңны үбәрмен.
...Коегыздан
су алдык,
әйттең ябып капкачын:
– Бала-чага төшмәсен!
Бала-чага ачмасын!
Сүзкәйләре бик таныш,
Үзең миңа чит сылу.
Синең болай борчылу –
ул минем дә борчылу.
Җиргә уртак борчу бу,
әйтерсең лә бу бала –
гел очам дип йөгергән
канаты юк дивана:
йә еракта үкси ул,
йә көлә безне кочып.
...Коелар өстен япсак,
елгалар өсте ачык...
Диңгезләр өсте ачык,
океаннар өсте ачык.

*1983*

## СЕҢЕЛЛӘР

Авылыгызга килдем якты кышта.
Ник, дисезме? Кызлар күрергә...
Абый булып, бераз шагыйрь булып,
«сеңелкәйләр!» диеп йөрергә...

Шәһәрдә дә авыл кызлары күп,
егылып уңа шәһәр ул яктан.
Тик авылдан китү белән кызлар
югалта шул нидер, югалта...
Шуңа килдем әле авылыгызга,
авыл матурларын күрергә.
«Матуркайлар, сеңелкәйләр!» диеп,
картлач кына булып йөрергә.
Чана эзләреннән, ат күзеннән
үткәнемне килдем карарга...
Кызлар юган кебек авылыгыз,
ак күбектәй таулар кабарган.
Җилләп кибә керләр кер бауларда,
якты кыштан якты ак керләр.
Безнең гомер соңын яктыртырга
ярый әле сез бар, сеңелләр!

*1984*

## Ә ХӘЗЕР БЕЗ АКЫЛЛЫЛАР

«Җитмеш җирдә җитмеш яры!» –
диделәр... Сөйләделәр...
Шуңа ук җитте микәнни?
Ай-һай, булганбыз җүләр.
Ә хәзер без акыллылар,
әдәпле, йөгәнлеләр.
Йөкләнә безгә зур эшләр,
без юллы, җегәрлеләр.
Сүзебезгә колак салсаң –
яшебез йөзәр сыман.
Җанда моң, иңдә уңыш бар,
инде без көзләр сыман.
Җитдилек чагыла күздән
шаярыйм дигәндә дә...
Мәхәббәт дигән мәңгелек
темага килгәндә дә –
җитмеш кыз сыйган күңелне
бер хатын биләп тора...
Җитмәсә әле, нигәдер
йодрыгын төйнәп тора.
Ярый ла без акыллылар,
юкса әй булмас ниләр?!
...«Көзләрнең дә
язга охшаш
көннәре була!»– диләр.

*1980*

## ГЕЛ

Җитдиләр янына барсам,
шаяннар җитми кебек.
Шаяннар янына барсам,
җитдиләр җитми кебек.
Яшәүнең кайсыдыр ягы
гел мине читли кебек.

*1971*

## БЫЕЛГЫ КЫШ

Үрелеп кенә Үргә ак юл менә,
күптән киткән идем шул юлдан.
Читтә каршыладым картлыгымны,
шуңа күнеп яшим быел да...
Онытыла язган Үр һәм ак юл,
оныттыра икән бу тормыш!
Быелгы кыш– миңа таныш түгел,
мин белмәгән сәер-якты кыш!
Мондый кышны әллә күрдемме бер,
килгәнме ул минем яшьлектән?
Үз хәлемне аңлый алмыйм быел,
аңлый алмыйм әле ничек тә...
Һаман чыгып карыйм, кышны карыйм:
офыккача якты тирә-юнь.
Кар кырлары аша йөзеп бара
яшьлегемә таба йөрәгем...
Ак каз барса шулай, таныр идем,
йөрәк димәс идем ялгыш та.
...Туган якта кабер эчләре дә
яктыргандыр сыман бу кышта.

*1997*

## НАРАСЫЙ

Бер гөнаһсыз нарасый бу –
көне буе сазлы суда!
Балакларын сызганган да
икенче көн бака куды.
...Өченче көн куа бака,
дүртенче көн тагын килде!
Йа Ходаем, ни диярсең?!
Ул бакага гашыйк инде!
Яраткач бер саз бакасын,
су буеннан китә алмас.
Ә гашыйклар бу сүземне
йә аңлар да йә аңламас.

*1972*

## КОЯШЛЫ ЯЗДА

Иреннәрең
ал гына да
бал гынадыр!
Өзелеп тамган сүзләреңә
бал буялган...
«Сөйләшә дә белмим» дисең –
бусы ялган.
«Син карт» дисең, «абзый» дисең –
чеп-чи ялган.
«Мин шул бик яшь кызый» дисең –
чүтеки ялган.
«Үбешә дә белмим» дисең –
бу да ялган.
«Үбешәсем килми» дисең –
тагын ялган.
«Дәртсез бала булдым» дисең –

ялган, ялган.
Әнә
күкне үпкәнсең дә,
эзе Кояш булып калган!
«Ялган, абзый, ялган!» дисең,
ялган булыр менә:
мондый язда
дәрт чүлмәге
тышыннан беленә.

*1979–1999*

## АЛМАЛЫК

Сиңа дигән сүзләрем күп иде,
һаман шуны сөйли алмадым.
Кичләрем дә шуңа, таңнарым да
бигрәк моңсу килә алланып.
Безнең сүзләр,
сөйләшмичә калган
безнең сүзләр –
сыгылыплар төшкән алмалык.
Бар иде шул икәү сөйләшәсе,
син үзең дә моны аңладың.
Чиксез галәм сыйган бу заманга
без янәшә сыя алмадык.
Безнең сүзләр,
сөйләшмичә калган
безнең сүзләр –
сыгылыплар төшкән алмалык.
Сөйләшәсе һаман алда сыман,
алдады ла тормыш, алдады.
Йөз аңлашыр идек бер сөйләшеп,
без сөйләшер вакыт калмады.
Безнең сүзләр,
сөйләшмичә калган
безнең сүзләр –
сыгылыплар төшкән алмалык.

*1992*

## САБЫРЛЫК АЛАМ ХӘЗЕР

Тормыш һаман сабыр гына,
Тын гына торды карап.
Мин бәрелеп ватылырдай
Ярсыдым ничә кабат!
Җан бүген дә шул халәттә,
Ярсыдым, туздым менә.
Ни өчен дип сорыйсызмы? –
Анысын тормыш белә.
Тормыш әнә сабыр гына,
Тын гына карап тора.
Җитмәсә, каршыда гына
Сандугач сайрап тора.
Сандугачкай, кичер, ялгыш
Бу хәлгә кергән булсам;
Тормышны кичер, бу хәлгә
Чынлап җиткергән булса...
Ярсуымны илтеп менә

Суларга салам хәзер.
Мәңге сабыр суларымнан
Сабырлык алам хәзер.
Акчарлак елар өстемдә, –
Шул гына авыр булыр...
Тормыш һаман сабыр гына,
Тын гына карап торыр.

*1973*

## ӘГӘР БЕРӘҮ ӘЙТСӘ

Әгәр берәү әйтсә:
– Җир яначак,– дисә,
– Ул кызыл шар булып
бер калачак,– дисә.
Ышанмагыз аңа,
ярату бар әле.
Ә безнең ярату –
янгыннардан көчле.
Ә безнең ярату,
ә безнең ярату,
ә безнең ярату –
янгыннардан көчле.
Әгәр берәү әйтсә:
– Җир яначак, – дисә,
– Ул кара шар булып
бер калачак, – дисә.
Ышанмагыз аңа,
ярату бар әле.
Ә безнең ярату –
янгыннардан көчле.
Ә безнең ярату
Җирне яулап ала,
яшел шар өстендә
яшьлек булып кала.
Әгәр берәү әйтсә:
– Бар да бетте, – дисә,
– Инде хәвеф Җирне
әсир итте, – дисә.
Ә безнең ярату
Җирне яулап ала,
яшел шар өстендә
яшьлек булып кала:
яшәү булып юлда
бар илләрдә кала,
татлы үбү булып
иреннәрдә кала.

*1975*

## ҮПКӘЛӘРМЕН КЕБЕК

Хатамдырмы, юкмы,
һич сөйләмим көлеп:
миңа Татарстан
Җир үзәге кебек...
Йөрим кайчак чыгып,
күп шәһәрләр күреп,
Казан шәһәрләрнең
иң гүзәле кебек.

Сорасалар әгәр,
бирә алмам бүлеп:
Мәскәү Татарстан
шәһәредер кебек.
Мин дөньяны сөйдем,
дөнья торсын белеп:
ул да Татарстанның
бер өлеше кебек!
Хаталанма, диеп
әйтсә кемдер көлеп, –
шул кешегә мәңге
үпкәләрмен кебек.

*1973*

## СӨЙЛӘРГӘ ДӘ ХУРЛАНАМ

«Дөнья ямьсез!» – дип әйтмә син,
Әйтмә минем ишегә.
Дөнья матур
Матурлыкны таный белгән кешегә.
Үз бала охшар атага
Йә охшар анасына.
Кайчак уйлыйм да,
Бу дөнья
Миңа үз түгел сыман.
Мондый зур охшашсызлыкны
Сөйләргә дә хурланам.
Яшәгән, олгайган саен
Ямьсезләнә барам ич мин,
Ә дөнья – матурлана.
Шундый матурлыкны бозып
Күпме яшәргә мөмкин?
Вакыты җиткәч, китәрмен!
Китә тора бит кешеләр,
Китәрмен,
        мин кемнән ким?

*2004*

## ГЕЛ КАБАТЛЫЙМ ШУЛАЙ

Ялантәпи узган көннәргә
Әйләнәм дә кайтам сагынып.
Талларымнан телгә бал тама,
Елгаларга йөрим табынып.
Йолдызым, Камышлым,
Гел кабатлыйм шулай, гел генә.
Йолдызым, Камышлым,
Әй туган як кынам, бергенәм.
Тәкъдиремә язган икәнсез
Адашмаска миңа читләрдә.
Җиргә сыймас олы шатлыгым,
Кычкырасы килә күкләргә.
Йолдызым, Камышлым,
Гел кабатлыйм шулай, гел генә.
Йолдызым, Камышлым,
Әй туган як кынам, бергенәм.
Әнкәм исе килә гөлләрдән,
Исләренә җаным исерә.

Кәгъбәләрдән изге җир булса,
Сез генә ул аннан изгерәк.
Йолдызым, Камышлым,
Гел кабатлыйм шулай, гел генә.
Йолдызым, Камышлым,
Әй туган як кынам, бергенәм.

*1995*

## ӘЛЛӘ ШУЛАЙ БУЛА МИКӘН?

Сок суы белән Касады
Камышлы сулар икән.
Яшьлегемнең канатлары
Әллә соң шулар микән?
Әллә шулай була микән?
Буладыр ла инде ул.
Уйларымда ике елга,
Шуңадыр ла инде ул.
Сок суы белән Касады
Сагышлы сулар икән.
Алар әллә миңа таба
Сузылган куллар микән?
Әллә шулай була микән?
Буладыр ла инде ул.
Уйларымда ике елга,
Шуңадыр ла инде ул.
Сок суы белән Касады
Кушылып ага, диләр.
Көнбагышлар ала сары,
Сары юл саба, диләр.
Әллә шулай була микән?
Буладыр ла инде ул.
Уйларымда ике елга,
Шуңадыр ла инде ул.
Җырларымда ике елга,
Шуңадыр ла инде ул.
Гомеркәем буйларына
Шулай була инде ул.

*1991*

## ӘЙЛӘНЕП КАЙТУЫҢ БАР

Монда башың әйләнерлек
Бәхетле булуың бар.
Пар канат итеп бәхетеңне,
Күккә омтылуың бар.
Берзаман киткән урынга
Әйләнеп кайтуың бар.
Ләкин кунар урын күрмәү,
Аны югалтуың бар.
Күчәреннән Җир күчкән, дип,
Кычкырып шашуың бар.
Бар нәрсә урынында килеш,
Синең адашуың бар.

*1971*

## ЧАКЫР АНЫ...

Кичер аны, чакыр аны,
Килсен сиңа, ул килсен.
Илдә берәү булсаң әгәр,
Дөньяда бер түгелсең...
Дөньяда бер булсаң әгәр,
Чакыр аны, ул килсен!

## ГАДӘТЕМДӘ – КЫШКЫ ДАВЫЛЫҢ

Шулайдыр шул, ту да, үс тә синдә –
Инде сине онытып буламы?
Авылым, авылым!
Бүген эшем ташлап,
Торам әле шуны уйланып:
Синнән киткән малай гына идем,
Шәһәрдәге яңа иптәшем
Ни өчендер, миңа эндәшкәндә:
«Син, деревня», – диеп эндәште.
Ә мин русча белмим, мин татарча:
«Шулаймы?!» – дип аңа бәйләндем,
Һәм шәһәре аның күз алдында
Шактый вакыт зырлап әйләнде.
Дорфалыктыр, тәртипсезлектер бу,
Малайлыктан бу, дип акланмыйм.
Ләкин булды инде, сине шулай
Мин беренче тапкыр якладым...
Хәзер сине башкачарак яклыйм,
Башкачарак яшим, авылым.
Әмма йөрәгемдә – җәйге эссең,
Гадәтемдә – кышкы давылың.

*** * ***

Күр яшисе елларымны,
Алар бит ап-ак шәмнәр.
Шәмнәре ничәү булса да,
Гомерем минем шәмдәл.

Син кыю гына кил әле,
Кил якын шәмдәлемә.
Әйдә, ут кабызыйк әле,
Кабызыйк шәмнәремә.

Янсын әле якты булып
Бөтен-бөтен шәмнәре.
Шәме беткәч, икәү бергә
Бәреп ватыйк шәмдәлен.

## БЕЗ ИГЕЗЛӘР ТҮГЕЛ

Шатлыкларга исермәскә,
Табынмаска булдым мин.
Кайгыларга юлыксам да,
Абынмаска булдым мин.

Бар чагында узасы юл –
Аякта булу кирәк.
Юлда кемне нәрсә көтмәс? –
Аякта булу кирәк...

Мөмкин дошман үчегүе,
Дусларымның сынавы.
Җавап сүзләр күп булса да,
Санаулы бит, санаулы.

Санаулы бит эшлисе эш, –
Гомер чиксез түгел бит.
Кая тартмас, кая кермәс –
Күңел бит ул, күңел бит!

Шатлыкларга исермәскә –
Табынмаска булдым мин.
Кайгыларга юлыксам да,
Абынмаска булдым мин.

Нинди булмас янда юлдаш,
Нинди тел йә фигыльле?
Без игезләр түгел Җирдә,
Узар юл – төрле-төрле.

Кайгы белән шатлык кына
Икесе игез бугай.
Юллары һәм гомерләре
Аларның тигез бугай.

*1972*

## БЕР ТАНЫШЛЫК ТУРЫНДА

Бу очрашу моңлы булды,
Беренче һәм соңгы булды:
Утырдык Тукай янында,
Йөредек Кабан ярында...
Минем сүзгә тик син шаһит,
Синең сүзгә тик мин шаһит,
Сизми калды төн үзе дә
Уйны да безнең, сүзне дә.
Танышлыкны без таш иттек,
Кабан күлгә ташлап киттек.
Уйнады суда боҗралар...
Ничә ел уйныйлар алар,
Уйларыма кагылалар,
Болай диеп кагылалар:
– Кил син, егет, кил Кабанга –
Су өстен сыйпап карарга.
Өметләнмә шуннан күпкә,
Син үрелмә, егет, төпкә.
Үрелеп нигә тармассың,
Аралап ала алмассың!
Бик күп анда серле ташлар,
Кемгәдер кадерле ташлар!

*1970*

## КЫШ ТҮРЕНӘ УТ ЯГЫП...

Көн кояшлы тора да,
Сүрелә бит учагың.
Нинди уйга талдың син,
Кыш түренә ут ягып?
Шулай инде Иделдә,

Кырлар тоташ кар инде.
Кар диңгезен кичәргә
Чаңгыларың бар инде;
Инде утың бар икән,
Ягар утын бар икән –
Нәрсә булыр уеңда?
Шатлык микән, зар микән?
Уйлыйсыңмы еракны,
Җәйдер анда дисеңме?
Әллә хәзер шул якта
Булырга телисеңме?
Бездә тоташ кар инде,
Шулай инде биредә.
Сүзләремә колак сал,
Туган булсаң Иделдә.
Ерактагы җәй белән
Син үзеңне җылытма,
Күктә кояш бар диеп,
Учагыңны онытма!

*1973*

## УРМАНЫМДА ЙӨРИМ

Урманымда йөрим,
Урманымда,
Баллы юкәләрем һавасын сулап.
Күптән киселгән,
Караеп калган төпләрдән
Үрентеләр чыга дулап.
Урманымда йөрим,
Урманымда,
Әткәмнең чалгы янавын
Хәтерләткән җирдә;
Чабып куйсаң, җыеп куйсаң,
Өеп куйсаң –
Эскерт-эскерт
Чәчәк булыр биредә.
Урманымда йөрим,
Урманымда...
Кайчак, авыраеп уйларымнан,
Имәннәр күләгәсенә утырам.
Имәннәр,
Үрентеләр,
Үләннәр
Юлымны
Киң һәм зәңгәр
Биеклеккә таба
Дәвам итеп тора.

*1967*

## БАРГАН ЧАКТА

Күпме көрәш бу тормышта,
Күпме көрәш алымы?
Биеклекләр, биеклекләр –
Җиңел генә алынмый.
Мәхәббәттә, эштәме ул,
Зур яудамы – гел көрәш.

Кем яшәсә, бу көрәшкә
Суырылып шул керә.
Кыю керә бирәүләре –
Осталар! Алдыралар!
Чигенгәндә – күперләрне
Яндырып калдыралар.

Мин дә чыктым зур көрәшкә
Кечкенә хәйлә корып:
Барган чакта күперләрне
Калдырамын яндырып.

## ҖИТӘРЛӘР...

Ашыгып үтте җәяүле,
Үтте атлы дөбердәп...
Машиналы үтеп китте,
Самолет үтте гөрләп.
Максатлары булгач алда,
Бар да барып җитәрләр.
Максатын югалтканнар бар,
Шулар ни хәл итәрләр?!

*1972*

## БУ КИЧ СӘЕР КҮРЕНӘ

Кояш җиргә төшәр-төшмәс,
Бу кич сәер күренә.
...Яр буенда бер ал чәчәк –
Күккә хәтле үреләә...
Кулымдагы кармак сабы
Җирне дә үтә сыман.
Кармагымда кыртыш чыга,
Җәен чыккандай судан.
Чәчрәп киткән һәрбер тамчы
Бер зур океан бугай.
Елга шавы – минем тавыш,
Дулкын минем җан бугай.
Әллә ниләр уйга килә,
Ярый бирәү дә белми!
И рәхәт – озын уйларым,
Ярый бирәү дә бүлми!
Ут турында җырлый кояш,
Сүзләрен ишетәмен...
...Җемелди су өсте тулып
Акчарлак бишекләре.

*1975*

## АВЫЛ МАЛАЕНЫҢ МОНОЛОГЫ

Бәхәсләшмик әле.
Инде таныштык, аңлаштык,
Мин бит шат
    биредә
        сезнең кебек
            яңа дусларым булганга.
Бергәләп яшәрбез, эшләрбез.

        Бергәләп чыгарбыз
                  яңа юлларга.
Бәхәсләшмик әле.
Беленде бит инде –
Мин авыл малае,
Ә сез –
        шәһәр егетләре.
Бәхеттә алышмыйк әле без.
Һаман:
«Без синнән бәхетлерәк», –
        диясегез киләме?!
Алайса сөйләгез!
Рәхәтләнеп тыңлыйм алайса
       шәп машиналарда
              озын юллар үткәнегезне.
Сөйгән ярларыгызны
      фонтанлы бакчаларда
           үпкәнегезне.
Күз алдына ачык китерәм
Яшьтән үк
        баш әйләнгәнче
              биегәнегезне
                    зиннәтле залларда.
Ә мин әле менә хәзер генә
        керә башладым аларга.
Ә мин әле менә хәзер генә
Таксиларга күнегәм;
Нәкъ сезнеңчә рәхмәт әйтеп,
Артыграк түли беләм...
Сөйләгез,
     шәһәрчә кыю,
          ышанычлы рәвеш белән.
...Тик бәхет мәсьәләсенә
     мин
        барыбер
             болайрак киләм:
Исергәнегез булмаса
     басуда
         мәхәббәт һәм бодай исеннән,
айныганыгыз булмаса
тау җиле исүдән;
иярсез атларда чабып
      үткәнегез булмаса
            җиләкле кырлар өстеннән –
сезнең бәхет, дусларым,
            кимрәк булыр минекеннән.

*1978*

## ӨМЕТ

Ал гөлем ак кар астында
Калды шул инде көлеп.
Юк, сулмас ул, коелмас ул,
Ул минем өмет гөлем.

Йөрәгемнән ал гөлемә
Карлар аша көч бирәм, –
Бик сизәм лә, кыш озын ла,
Кар салкын ла, кар тирән.

Яз җитүгә кар югалыр,
Ал гөлем чыгар көлеп.
Юк, сулмас ул, коелмас ул,
Ул минем өмет гөлем.

*1973*

## КАЙТЫРМЫН

«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!» –
Бу тавышны әнкәсе,
Әткәсе дә бик белә.
Бу колакка ишетелә,
Бу йөрәккә ишетелә.
Бик ерактан ишетелә:
«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!»
Яңа гына югыйсә,
Агач өй – диңгезендә
Йөзә иде бит әле
Ул агач бишек белән!
Кай арада тавышы
Һай ерактан ишетелә.
Океаннардан ишетелә
Йә күкләрдән ишетелә:
«Йөзеп кенә кайтырмын!
Очып кына кайтырмын!»
...Ә кем белә
Киткәннең
Исән-имин кайтасын?!

*1973*

## ЯЗДЫМ

«Вакытның бер күзе – Кояш.
Ә бер күзе аның – Ай:
Чынлап та ул шактый сәер
Һәм куркыныч та бугай.

Карый ул безнең тарафка,
Әйтерсең вакыт аучы:
Бер күзен тәмләп кыса ул,
Бер күзе әнә ачык.

Ә кулында мылтыгыдыр,
Чакмага...
Баса бугай!
Сызгырып килер пулясы
Кемнедер хәзер егар,
Егар!» –
Шулай
Яздым үзем,
Үзем курку тоймадым.
Мин куркаклар нервысында
Юри бераз уйнадым.

*1972*

## ХАТ ЯЗ, ДУСКАЙ, ТЕЛӘЧЕГӘ

Хат яз, дускай, Теләчегә, –
Кайсы айда киләсең?
Алкын Мишә-су ярында
Акчарлактай Теләче!
Түш салыйк суларына,
Очыйк болыннарына.
Мин канатлы бу дөньяда
Туган ягым, акчарлагым
Теләче булганына.
Хат яз, дускай, Теләчегә, –
Безгә юлны беләсең.
Мәҗлесләрнең сиңа түре,
Хуҗаларның – көләче!
Түш салыйк суларына,
Очыйк болыннарына.
Мин канатлы бу дөньяда
Туган ягым, акчарлагым
Теләче булганына.
Хат яз, дускай, Теләчегә, –
Ничә көнгә киләсең?
Үкенмәссең бөтенләйгә
Алып калса Теләче!
Түш салыйк суларына,
Очыйк болыннарына.
Мин канатлы бу дөньяда
Туган ягым, акчарлагым
Теләче булганына.

*1974*

## УРМАННАРГА ЙОМШАК СУКМАК КЕРӘ

Кайчак кеше шулай онытылып,
Мәшәкате белән йөгерә-йөгерә,
Көне-төне тимер юлдан чапкан
Тимер тәгәрмәчкә әверелә.
Йомшак түшле яшел язны тоймый,
Усакларны күрми, юкәләрне.
Кичермәгән сымак мәхәббәт тә,
Белми иркәләнү-иркәләүне.
Заман тизлегендә әйләнеп ул
Соңгы чиккә җитеп кызган була.
Һәм кай җире сызлаганны белми,
Чөнки үзе тоташ сызлау була.
Минем хәл дә шулай иде, ахры,
Йөрәгемнән килде ачы аваз.
Идел җиле тиде маңгаема,
Ул да ят шикелле иде бераз.
Әмма якын итеп, әйдәп мине
Урманнарга йомшак сукмак керә.
Бал кортлары миңа бал җыйганны
Әйтерсең лә беренче кат күрәм.
Парлы-парлы кешеләрне күрәм,
Карап күзең туймас яшь кызлар бар.
Иркәләргә теләп кулым сузсам,
Баш иярләр кебек зур агачлар.

*1974*

* * *

*Н-гә*

Ишеттем,
Мин киткән юлдан
Сиңа кайгы килгән,
Ишеттем.

«Кайгылы күзләрем турында
Өч юл шигырь
Язмады шунда!
Кайгылы күзләрем турында!» –
Дигәнсең, ишеттем.
Ишеткәнне генә язу
Кыен икән... кыен икән...

Кайгың кечкенәме, зурмы?
Миңа каршы булганмы?
Мин аны күрмәдем шул, иркәм.

*1974*

## ҖИДЕ БАБАЙ

Күптән түгел сыман да,
бер уйласаң, күптәндер.
Төгәлрәк әйткәндә,
иллеләп ел үткәндер.
Ярмәк, Бакай, Камышлы –
зур авыллар ул чакта.
Без бер авыл, бер колхоз,
кеп-кечкенә булсак та.
Исеме бар хәзер дә –
«Черемушка!» дисезме?
«Йолдыз!» иде шул аның
картлар кушкан исеме!
Кешеләре күп димим,
өйләр артмас илледән:
җиде бабай бар иде,
җидесе дә бер дигән!
...Умартачы бабай да,
берсе гармунчы бабай.
Тегермәнче, кыярчы,
аннан кавынчы бабай.
Мин санаган тәртиптә
берәм-берәм үлделәр.
...Аннан китте көтүче,
итекчене күмделәр...
Аннан бетте бездә бал,
карт тегермән туктады.
...Кыярлыкка, – киртәләп, –
мал көтүен туплалык.
Төгәлрәк әйткәндә,
шулай көннәр үтүгә,
үлде бездә гармун да,
бетте безнең көтү дә.
Әнә беткән кавынлык,
тегендәрәк, үрдәрәк.
Анда хәзер таш үрчи,

сибелеп тә тәгәрәп.
Әстерханнан машина
килеп чыкса бу якка,
кавын сатып алырга
бар да баса чиратка:
камышлылар – чиратта,
дәүләтколлар – чиратта.
Бозбаш, Ярмәк, Усманнар!
Бакайлар әнә шаулый!
Балыклылар килмәгән,
алар кавын ашамый.
Күрмәгәнгә мондый хәл
күптән инде, күптәндер.
Төгәлрәк әйткәндә,
иллеләп ел үткәндер.
Җиде бабай терелеп,
күрсәләр безне килеп?!
...Озак яши алмаслар,
үләр иделәр көлеп.

*1986*

## ҮЛӘН БҮТӘН, ЯФРАК БҮТӘН

Күптән киттең, озак тордың,
Анда нәрсә аңладың?
Бүген кайтып туган якка,
Үләнендә аунадың.
Елмайдың син шатлыгыңнан:
– Менә ул, менә! – дидең. –
Монда үстем, монда мине
Һәр үлән белә! – дидең.
Каеннарның яфрагына
Куйдың кайнар битеңне:
– Таныйм, – дидең, – бу шул, – дидең, –
Шул каеннар бит инде!
...Озак тордың, ни укыдың,
Кем булдың син, ни белдең?
...Тар басмадан эчкә кереп,
Дулкыннарга үрелдең.
Алып-алып елгадан су,
Койдың аны җилкәңә:
– Яшь чагымда мине, – дидең, –
Кочты бу су иркәләп.
Тик су сине белми иде,
Яры шул да, су бүтән...
...Үлән бүтән, яфрак бүтән,
Кайтмадың шул бик күптән.

*1972*

## МИН ИДЕЛ КЕШЕСЕ

Ярты ай тирбәлә күктә,
тирбәлә күктә ярты ай,
мин Иделгә киләм.
Мин – Идел кешесе,
бар узганым, киләчәгем белән.
Мин Иделгә
бик еш киләм.

...Яратам Иделне.
...Һәрвакыт
туасы язлар турында,
үсәсе кызлар турында
уйлана идем,
шушында килсәм...
Ә бүген исә
Идел ярына
хәтерем ята,
киң яшел кыр булып.
Керәләр аңа
Җирдән киткән туганнарым,
керәләр
таза атларда
ыргылып...
Керәләр...
Алар кыю булганнар...
Даладан бәргән давылда
аяк өсте торганнар...
Кыю, илсаклар булганнар,
алар талантлы булганнар,
сайрар поэмалар калдырганнар...
Талантлы, моңлы булганнар.
Алар койганнар,
алтынга зөбәрҗәт каш куйганнар.
Нечкә зәвыклы булганнар,
Алар төзүче булганнар.
Ракетадай манаралар бастырганнар.
Яратканнар Иделне.
Чү, тыңлыйм әле,
алар хакында
ниндидер җыр көйли бугай
Идел өстендә, биек-биектә,
күктә тирбәлеп, ярты ай.

*1967*

## МӘКТӘПКӘ КАЙТКАЧ

Сары өстәлдә глобус –
Мин күргән беренче дөнья!
Бармак белән әйләндерәм, –
Кара, зырлап тора;
Меридианнар уйларымны
Үзенә чорнап тора:
Әйләнәләр урманнар,
Әйләнәләр диңгезләр,
Әйләнәләр таулар,
Әйләнәләр материклар,
Әйләнәләр шаулап.
...Күчәреннән күтәреп,
Барысын алам кулга...
Мин күргән беренче дөнья
Нинди җиңел булган!

*1965*

## ДӨНЬЯ КАРШЫСЫНДА

Кеше күңеле кешеләрне кыса кайчак,

И киң Идел, күңелемә киңлек бир син!
Якын итеп янәшәмә килгән һәркем,
Иркен сулап, борчуларын онытып йөрсен!
Йөзә алмас сай елгада хәтта каек,
Тирән Идел, тирәнлек бир уйларыма!
Аптырашка калып торган акыллылар
Шатлансыннар, киңәш белән мин баруга.
Озын юлда мин күтәргән йөк тә авыр,
Көчле Идел, үзең миңа көч бир инде!
Дуамал һәм бөек дөнья каршысында
Синдәй көләч, синдәй горур булыйм мин дә.

*1972*

## КАВКАЗДА

Килгәч-килгәч, син, күреп кит, дидең,
Алып чыктың мине тауларга;
Күтәрелдек шулай без биеккә –
Синең тормыш, синең таңнарга.
Күтәрелдек һаман, каршыбызга
Кар сулары төшә үкереп...
Ә син миңа карап-карап алдың,
Курыкмасын бу дип, үз күреп.
...Таш кыялар – минеке дә алар,
Куркытмый һич сулар шаулавы...
Тагы бераз менсәк, күренер сыман
Сабыр Иделем, бәрхет тауларым.

*1970*

## ИДЕЛДӘ

Әллә көнләштерергәме, иркәм, уең!
Күлмәгеңне яр өстенә куеп,
Кояш нурларына төренгәнсең:
Якты бер дулкыннан
Хасил булган төсле күренәсең,
Идел үбә тезләреңне.
Идел
Керфекләрең белән шаяра,
Кара кашларыңа кагыла,
Кайнар күкрәгеңдә тирбәлә,
Чәчләреңнең сары бөжралары белән
Каплый күзләреңне.
Көнләшмим, көнләшмим.
Беләм бит:
Дөньяны,
Йолдызларга атылган яшьлекне
Ничек сөйсәң,
Мине дә шулай сөясең.
Диңгез һавасы кебек саф
Сүзләр пышылдаган иренең –
Миңа гомерем бәясе.
Кына тигән ун тырнагың –
Ун Кояшым минем –
Мин соң
Җирдәге һәр кызга, һәр егеткә
Шундый бәхет теләмәс идемме?!
Көнләшмим,

Җимерелмәс дуслык,
Таш калалар тудыра белгән
Йомшак кулларың белән
Кочакла, кечкенәм, зур Иделне.

*1965*

## КЫШКЫ РЕЙС

Көннең якасыннан февраль тоткан.
Ак, коры кар
Чагылдырып ала күзеңне.
«Улым – шофер!» – дисең,
Утыр, әнкәй,
Алып барыйм әле үзеңне.
...Кар тузаны бии юлларда,
Баганалар кала тезелеп.
Машиналар чаба.
Култык асларына
Том-том китап төсле этажларны кысып,
Зур краннар ашыга каршыга.
Кешеләр,
Кешеләр,
Кешеләр –
Сәламлиләр
Берсен-берсе
Бары үтешли,
Мәңге бетмәс эше бар сыман...
Җиңел безгә яшәү барыбер.

## БУЛЬДОЗЕР

Көртне ярып килә, юл салып;
Төртелсә,
Тавың китәр кебек кузгалып.
...Монда яңа ферма салалар,
Кайнар куллар тиеп эри кар.
Тракторчы,
Мич башындамыни,
Чалкан ята мотор астында...
Җиңел безгә яшәү барыбер.

Ил тынлыгы – һәрбер адымда,
Нефть вышкалары басуларда,
Хезмәт шавында...

...Алда – шәһәр.
Завод капкаларын
Яшьтәшләрем киереп ачканнар.
41 дә
Безнең аналарга сыенып
Җимерелмичә калган торбалар
Авыр еллар истәлегенә
Таш һәйкәлләр булып басканнар.

Җиңел безгә яшәү барыбер.
Көннең якасыннан февраль тоткан,
Аклыгына тисә, тап эрер.

* * *

Ак кар ява,
Ак кар ява.

Эре, йомшак
Ак кар ява –
Казан кары...

Урам тулы
Казанлылар –
Китүләре,
Кайтулары.
Өсләренә
Ак кар ява –
Казан кары...

Бер шат бала
Кар төягән
Чана тарта.
Берсе куйган
Кар кисәген
Түбәсенә...
Син кар чөймә
Турыбызга,
Иркәм, юрап:
Кемгә төшсә,
Шуның рәхәт
Күрәсенә.
Мондый юрау
Мине борчый,
Сине – белмим.
Күрәсене
Аерым-аерым
Күрмик бары.
Нинди яхшы!
Икебезнең өскә ява
Эре, йомшак
Ак кар ява –
Казан кары.

## КИМСЕНМӘМ, ҺИЧ БОЕКМАМ

Ризван йә Батуныкыдай
Чәчем дә юк, мыек та.
Бу хатыным барында мин
Кимсенмәм, һич боекмам.
Мактыйм әле хатынымны –
Актанышның алтынын.
Башкалар миңа ияреп
Мактасын үз хатынын.
Мактыйм әле хатынымны,
Пускай: «Җүләр!» – дисеннәр.
Тик җүләргә мондый хатын
Эләкмәвен белсеннәр.
Минем хатындай әзерли,
Пешерә белүче сирәк.
Ә теле, теле хатынның,
Табынынннан тәмлерәк.

Яшьтәшемне озаттым кичә,
Хатыны аны каршылады:
– Кайттыңмы, картлачым? – дип,
Ә минеке каршы алды:
«Сагындым, карт лачын!» – дип
Очындыра мине хатын.
Әллә чын, әллә юри
«Пеләш башым» диярендә
«Кояш башым» дип йөри.
Бер салмыш төште юлыма,
Биш, ун тәңкә генә сорый,
Борынын югары тота,
Хәтәр хәрәкәтләр ясый,
Нык куркыта, янәсе.
– Сабыр, сабыр! – дим хатынга.
Сизәм бит хәзер салмышны
Сугып җиргә бәрәсен.
Таш җир монда, ул-бу булса,
Кайда җавап бирерсең дә,
Ничек җавап бирерсең?
Вәт эләкте миңа хатын,
Йөз яшәсәм дә туймамдыр
Мактап та, кочаклап та.
Тик бер ягын мактый алмыйм, –
Сыеп бетми кочакка.

*2004*

## БУЛМЫЙ ТОРГАН ХӘЛ

Булмый торган хәл булган
Кичә безнең авылда:
Җырлап катык шешәсе
Килә икән таш юлдан.
...Сызгырып та җибәрә,
Такмаклап бии икән:
– Их-ма!
Чыкма каршыма!
Чыкса берәү каршыма,
Тибеп егам! – ди икән.
– Тотып ишәм! – ди икән.
– Мин пыяла шешә түгел,
Тимер шешә! – ди икән.
– Теләсәм,
сугып
һәр өйнең
Башын тишәм! – ди икән.

Шаккатканнар әтәчләр
Әтәчләнгән шешәгә.
– Булмый торган хәл бу! – дип
Шаккатканнар кешеләр.

Шунда шешә бер ташка
Абынган да ватылган!
...Авылыбыз кибетендә
Аракы шешәсе белән
Бер тартмада төн уздырган
Пыяла шешә булган ул!
...Исерек шешә булган!

## ЮАТМА ИНДЕ МИНЕ

«Элеккечә яратам!» дип
Юатма инде мине,
Бүгенемне уйландырып
Елатма инде мине.
Бүгенем белән түгел мин,
Узганым белән яшим,
Ярый әле узганымда
Матур көннәрем булган.
Елмаюлар белән тулган
Һәм бәхет белән тулган.
Шундый узганым барына
Куанып яшим хәзер.
Киләчәгем ни күрсәтер,
Мин барсына да әзер.

*2004*

## БЕЗНЕ ВАТЫП АГА ВАКЫТ

Ага сулар, суга ярга,
Ватылып кала ярлар.
Ватылып калган яр сыман
Яшәгән чакларым бар.
Сулар ага, чигенә яр
Чигенә алган кадәр.
Безне ватып ага вакыт,
Чигенсәк –
Артта кабер.

*2004*

## ҖӘЙНЕ КӨТТЕМ

Кыш буена җәйне көттем,
Җәй буе кышны көтәм.
Миңа ошарлык кыш та,
Җәй дә
Булмас микәнни бүтән?
Сентябрь бик ошап уза,
Тиздән кыш килеп җитәр.
Һәм каралган уйларымны,
Һәм узасы юлларымны
Кыш актан да ак итәр.

*2004*

## ЙӨГЕРЕП КИТСӘМ...

Тау өстендә тагын кар сулары
башлады ла көмеш җырларын.
Искә төшә үткән бер очрашу,
ак кояшы белән нурланып,
ак кояшы белән нурланып...
Һәрчак миңа елмаерсың кебек
басып торган идең каршымда.
Тау өстендә булган ул очрашу

тау астына киткән ташкындай,
тау астына киткән ташкындай.
Яшьлегеңә хәзер җәй кергәндер,
миңа инде көзләр кул салган.
Килмәссең шул, көтеп торсам да мин,
йөгереп китсәм – сиңа җиталмам,
йөгереп китсәм – сиңа җиталмам.

*1972*

## ЕЛАУЧЫЛАР

*(Буйсындырылган илләр-халыклар хәленә бер караш)*

...Күз яшьләрен яшерергә киңәш итәм,
океан туган Елаучылар күз яшеннән.
Шул океаннан Елаучылар тарафына,
каза төяп, рәт-рәт булып кораб килгән.
Кораб килгән кәрван-кәрван кайгы төяп,
чын кайгыны Елаучылар шунда күргән:
тавышлары, тормышлары, тарихлары
су өстендә чүп шикелле йөзеп йөргән.
Киңәш итәм яшерергә күз яшьләрен,
бәлки, кырың бер үләнсез, сусыз калыр.
Яңа чишмә килеп, сезне таш дип белсә,
еламаган Ил икәнне Кояш таныр.

*1982*

## БЕЗ ҖЫРЛАГАН КӨЙЛӘР

Идел-илдән еракларда йөрдек,
дөньяларны гизеп тойды йөрәк:
безнең якты күңел киңлекләре
зур дөньядан киңрәк.
Ул киңлектә бер кала бар –
узганнар уты Казан.
Ул – гөрләгән бәйрәмнәрнең
кичәге йорты Казан.
Мәйданнарга чыгып сынатмадык,
һаваларга ашып шуны белдек:
безнең күңелләрнең биеклеге
йолдызлардан биек.
Ул киңлектә бер кала бар –
узганнар уты Казан.
Ул – гөрләгән бәйрәмнәрнең
бүгенге йорты Казан.
Яман исем калдырмадык артта,
киткән чакта кайтып Идел-илгә.
Гел чайкалыр еллар хәтерендә
без җырлаган көйләр.
Ул киңлектә бер кала бар –
узганнар уты Казан.
Ул – гөрләгән бәйрәмнәрнең
мәңгелек йорты Казан.

*1976*

## ХӘЗЕР

Беләгемдә һаман салкын сәгать, –
Текелдәве каныма ишетелә.
Көнлек гомерем белән ашыга-ашыга,
Эш көнемә хәзер сыя беләм.
Инде эш бетүгә, уйга талып,
Мин башыма җыймыйм кайгыларны, –
Чыбык-чабык бәйләмедәй итеп,
Кичләремдә бәйлим мин аларны:
Яман сүзне, уңышсызлыкларны,
Кысып-кысып, авыр бәйләм итәм;
Төнге караңгыда берәм-берәм
Аларны мин тау өстенә илтәм.
Хәтта җиргә салып бәйли алдым
Шат йөземә суккан сөюемне, –
Тау өстенә илттем мин аны да;
Шулай узам хәзер һәр төнемне.
Иртән кояш тауга ал ут сала –
Бар илткәнем янып бетә дөрләп;
Яшәү миңа җиңел булып кала,
Мин елмаеп яңа көнгә керәм.

*1973*

## АТЛАНАБЫЗ АТЛАРГА

Без бәләкәй чакларда –
атланабыз атларга.
Төшәбез әй мәтәлеп
урамнарга, чатларга:
– Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
бездән көлә эч кашып.
Без бәләкәй чакларда –
каласы юк атлардан.
Атланабыз яңадан,
мин дә менәм чаптарга:
– Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
юл өстенә басмасын.
Без бәләкәй чакларда –
очабыз әй атларда.
Үзебезнең кырларда,
мин үземнең чаптарда:
– Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!
Йолдыз белән Дәүләткол,
Усман, Бакай, Балыклы,
Камышлы һәм башкасы
карый безгә баш кашып.
– Ап-па, һоп-па,
без Самара яклары!..

*1995*

## ТУГАН-ҮСКӘН ЯКЛАРДА

Туган-үскән якларда,
иркәләнеп җилләргә,
уздым бер бала сыман
каенлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
каенлык арасыннан.
Туган-үскән якларда,
изү ачып җилләргә,
уздым сулар буеннан,
суда камыш куерган.
Күзләрең карар сыман
камышлык арасыннан.
Туган-үскән якларда,
күптән узган чаклардай,
уздым бер бала сыман
арышлык арасыннан.
Күзләрең карар сыман
арышлык арасыннан.
Карамады күзләрең,
тик һаман да без әле
икәү барабыз сыман
каенлык арасыннан...
Арышлык арасыннан…
Камышлык арасыннан...

*1983*

## УЗДЫЛАР

Ташулар еракта тындылар,
ужымнар көнгә кул суздылар.
Безнең турыда
яшь кызлар сөйләде:
– Җырлап авылдан
уздылар, – диделәр.
Җырлап уздылар.
Уздылар...
Ак йортлар тезелеп калдылар,
Күктә чал болытлар туздылар.
Безнең турыда
якташлар сөйләде:
– Җырлап шәһәрдән
уздылар, – диделәр.
Җырлап уздылар.
Уздылар...
Юлларда гомерләр тузалар,
Җырларда фикерләр тузмыйлар.
Безнең турыда
кешеләр сөйләрләр:
– Сүзләрен әйтеп
уздылар, – диярләр.
Җырлап дөньядан
уздылар...
Уздылар...

*1972*

## БӘХЕТ КИРӘК БЕЗДӘН СОҢ ДА

Алда, ерак-ерак төндә,
безне белми торган төндә,
безне белгән ай бар анда –
ай шәүләсе су өстендә.
Басмалары сыгыла да сыгыла,
бу басмада ул кем белән кем икән?
Кем булса да, бу – бәхетле,
Кем булса да, бу – бәхетле,
бу бәхетле төн икән!
Алда, ерак-ерак төндә,
гашыйкларга дөнья җитә.
...Безне белгән кырлар аша
сулар китә, сулар китә.
Басмалары суга тия сыгылып,
бу басмада ул кем белән кем икән?
Кем булса да, бу – бәхетле,
Кем булса да, бу – бәхетле,
бу бәхетле төн икән!
Алда, ерак-ерак төндә,
бәхет кирәк бездән соң да.
...Безнең гомер эзе сыман
ай шәүләсе уйный суда.
Басмалары айга тия сыгылып,
бу басмада ул кем белән кем икән?
Кем булса да, бу – бәхетле,
Кем булса да, бу – бәхетле,
бу бәхетле төн икән!

*1976*

## ШИГЫРЬ ГЕНӘ...

Үзем теләп алдым шундый һөнәр,
хәзер дәрвиш кебек көн-төн барам.
– Шигырь генә миндә, кемгә кирәк?
Шигырь бирәм? – дип, мин хәбәр салам.
...Барган саен, сизеп, сөенәм әле:
барына да шигырь кирәк бугай.
Төннәрендә җиде ят җирләрнең
Качак якташ кешем килеп чыга.
– Тавышыңны танып килдем, – ди ул.
– Шигырь генә миндә, шигырь бирәм!
Ул шигырьгә карап өен таба,
өй каршыннан аккан Иделен күрә...
...Ерактан ук таныйм күңелләрне,
Һәр күңелгә бирер шигырем бар.
Шигырь генә сузам юл сөйгәнгә –
каршысына тезелә тимер юллар.
Мин кыюлык итеп шигырь бирәм
Үзем шикеллерәк кыюсызга.
Кыш уртасы була – гашыйкларга
умырзая итеп шигырь сузам.
Көмеш язга чыгам, җәйгә җитәм,
кунак булып керәм ятлар өенә.
Яхшы кеше миңа урын бирер.
– Шигырь генә миндә, шигырь генә!
– Шигырь генә икән, и мескен, – дип,
яман кеше көлеп каршы ала.
...Мин аның да яман куенына
салкын елан итеп шигырь салам.

*1973*

## ҖИЗЛЕ ЙӨГӘН, ҖИРӘН АТЫҢ...

Җизле йөгән, җирән атың,
үз татарың – авылда.
Инде алар синнән ерак,
син калада, син монда.
...Әллә татар каласы бу,
әллә урыс каласы? –
Казан тирән, Казан зур ул,
барасы да барасы...
Очрый калсаң бер татарга,
алдан укы иманың,
Йә Иванга тарса юлың –
иманы юк Иванның.
...Бу хәлеңнән сине Алла
коткарыр да шикелле.
Ул коткарыр шикелле дә,
Котылуың – икеле.
Уйлыйсың гел яз качарга,
җәең тота, кышта – соң.
Әле кая хәтлерәк тә
ни рәвешле качасың? –
Юк машинаң,
булмас атың,
аның арба-чанасы.
Калдың менә Казаннарда,
ах, анаңның баласы!..
Җизле йөгән, җирән атың
булса бүген кулыңда –
минем сыман
шигырь язып
йөрмәс идең син монда.

*1995*

## ЧАРАСЫЗ

Ак чәчәккә бәла булды – теле югы,
бәла булды ак чәчәккә – тавышы югы,
йә «сөя» дип, йә «сөйми» дип алдан әйтсә,
йолкымаслар иде аның нәфис чугын.
Көче булмау – ак чәчәккә бәла булды,
ак чәчәккә бәла булды – булмау кулы.
Чәчәк булу бәла булды ак чәчәккә,
һәм юк аның бу бәладән чыгар юлы.

*1973*

## ГОРУР БӘХЕТЕМ

– Акчам бетә, бәхетсезлек! – дисәм мин,
– Ярым китә, бәхетсезлек! – дисәм мин,
– Яшьлек үтә, бәхетсезлек! – дисәм мин,
оятыннан бәхетем йөзе кызарыр.
Җиңел генә: «Мин бәхетсез!» – димәм мин,
күк барында башым түбән имәм мин.
Торалмасам гына шушы сүземдә –

горур бәхетем янымнан китеп барыр.

*1972*

## СОРЫЙЛАР

– Сакларлык, горурланырлык,
кызыгырлык иде, – дидем.
– Кирәк иде, безнең өчен
ул матурлык иде, – дидем...
– Югалды, югалды! – дидем.
– Нәрсә, нәрсә?– дип сорыйлар.
Ни өчен соң бу кешеләр:
– Кем? – дияргә ашыкмыйлар?

*1974*

## ҮЗЕБЕЗНЕ ЧЫГАРГАНБЫЗ ИСТӘН ДӘ

Йортлар салдык – нык булсын дип уйладык,
Юллар салдык– нык булсын дип уйладык,
Иген иктек – күп булсын дип уйладык, –
Үзебезне чыгарганбыз истән дә.
Шигырь яздык – шәп булсын дип уйладык,
Аш пешердек – сез туйсын дип уйладык,
Гөлләр чәчтек – кыр тулсын дип уйладык, –
Үзебезне чыгарганбыз истән дә.
Атлый тордык – сезгә урын карадык,
Үргә мендек – киңлекләрне барладык;
Гомер тавы түбәсендә аңладык:
Үзебезне чыгарганбыз истән дә.
Мәҗлес җыйдык, чакырып дус-кемнәрне,
Билгелик дип бергә булган көннәрне;
Киләчәк өчен, дип, бокал күтәрдек, –
Үзебезне чыгарганбыз истән дә.

*1971*

## ТҮГӘРӘК КҮЛ ГЕНӘ...

Үзәннәрдә якты көннәр күрдек,
көннәреннән, көннәреннән якты ла күл күрдек.
Көннәреннән, көннәреннән якты ла күл күрдек.
Түгәрәк күл генә –
үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,
кулларыңа кул гынам.
Күлләр күзе иде ике үрдәк,
күлләр күзе, күлләр күзе икән лә пар үрдәк.
Күлләр күзе, күлләр күзе икән лә пар үрдәк.
Түгәрәк күл генә –
үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,
кулларыңа кул гынам.
Хәл алырга ярга ятар чал көз,
күл өстенә, күл өстенә генә лә боз ятар.
Күл өстенә, күл өстенә генә лә боз ятар.
Түгәрәк күл генә –
үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,

кулларыңа кул гынам.
Китәме үрдәге,
саргая су камышы?!
Камышларга җил киселә,
җанга үтә тавышы...

*1982*

## ШИГЪРИ САГЫШ

Әйтимме?
Мин юк ич үзем,
Юк тавышым, юк көем.
Ә бер гүзәл яр сөйгән дә
Уйлый яры мин диеп...
Ышанмагыз ул гүзәлгә,
Минем хакта сөйләсә,
Саргылт чәчле, соры күзле,
Мин аны күрдем, дисә.
Каян күрсен ди ул мине? –
Сез аңа ышанмагыз!
Мин тик еллар күкрәгендә
Яралган шигъри сагыш.
Шигырьләрдән сезгә таба
Көлү тавышы килер, –
Минем гомер көлгәнем юк
Һәм көләсем юк гомер;
Шигырьләрдән сезгә таба
«Сөям» дигән сүз килер, –
Минем гомер сөйгәнем юк
Һәм сөясем юк гомер;
Шигырьләрдән елау тавышы
Килсә әгәр, белегез!
Бу мин түгел, елый кемдер –
Арагыздан берегез.
Мин елый, елата белмим,
Юк миндә андый сәләт,
Сездә генә ул бар нәрсә:
Талант, сәләт һәм сәбәп.
Тукта, нидер алдадым, дип
Әйтсәм хәзер, аңлагыз,
Бу мин түгел, бу сезнең сүз!
Кайсыгыз, ник алдады?
Мин алдый, алдана белмим,
Күрмим һәм сөйләшмим мин;
Үзем өчен мин яшәмим –
Сезнең өчен яшим мин.
Әгәр кемдер минем хакта:
«Үлгән!» – дисә, белегез:
Ул мин түгел, үлгән булыр
Арагыздан берегез.
Гомумән, мин юк ич үзем,
Юк тавышым, юк көем.
Ә бер гүзәл яр сөйгән дә
Уйлый яры мин диеп,
Ярым читтә, дип ялгыша...
Сагына ялгыш кына...
Читтә – еллар күкрәгеннән
чыккан бер тавыш кына.

*1967*

## ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ...

Күптән болай булганым юк иде, –
Бер сәбәпсез хәтта елмаям.
Туктап-туктап сулыйм төн һавасын,
Яшел урам шәп муенса итеп
Ефәк бауга тезгән утларын,
Тәрәзләрен, пәрдәләрен ачып,
Миңа карый Казан йортлары.
Туктап-туктап сулыйм төн һавасын,
Бер сәбәпсез хәтта елмаям.
Әйтерсең лә шулай һәрвакытта
Алма исе килер дөньядан.

*1970*

## ИРТӘ

Төн эчендә бу җирләрдә,
Бу тормышта ни булмас?!
Офыктан баш сузып карый
Дөньяга кызыл Кояш.
...Идел буе талларыннан
Суга яфрак коела...
Ярга килеп сары көймә
Яфрак кебек сыена...
Комлы җирләр – кичәгедәй,
Кисешә шул ук юллар;
Таулар исән, шәһәрләр сау,
Төркем-төркем авыллар.
Гүя төнлә бу дөньяда
Кыен хәлләр булмаган;
Ялгыш кына кулдан төшеп,
Көзге дә ватылмаган...
Юрга килә куе кызыл –
Кояштан туган микән?!
Гашыйкларның төнге сере –
Үзәндә томан микән?!
Бу бакчага, иртүк торып,
Теге кызчык ник чыккан?
Күрше йорты – койма аша,
Койма буе – кычыткан.
Койма аша карагандай,
Күрше малай – гашыйк баш,
Офыктан баш сузып карый
Дөньяга кызыл Кояш.

*1973*

## МИН КҮРМӘГӘН ИКЕ ЯКТАШ

Төн эчендә поезд йөгерә,
Мин вагонда уйлап ятам.
Хәтеремдә бер хикәят:
Ике егет безнең яктан;
Йөри алар, учак ягып,
Безнең урман уртасында.
Киемнәрен киптерәләр,

Сөйләшәләр нидер шунда.
Юеш күктә бер йолдыз юк,
Алып качкан ай – көмеш баш.
Бик охшашлар ике егет,
Мин аларга бераз охшаш:
Төнлә учак якканым бар,
Киемнәрне киптергән бар.
Аннан тагы, ни әйтсәң дә,
Якташлар бит әле алар!
Бер чишмәдән су эчкәнбез,
Тик үзләрен күргәнем юк.
Алар яшәп караганнар
Патша-канун заманда ук.
Ә канунга сыймаганнар,
Сыймаганнар Камышлыга.
Ике егет ияргәннәр
Язмышлары тавышына.
Усал язмыш урманнарда
Бүре булып улап йөргән.
Кайчак язмыш кәлтә булып
Мәгарәгә шуып кергән.
Эзләгәннәр егетләрне,
Ләкин тота алмаганнар;
Ничә тапкыр куа чыгып,
Ничә тапкыр алданганнар.
Ни өчендер бу егетләр
Җырлаганнар кайчак төнлә –
Камышлыга якын булган
Иң биек тау түбәсендә.
Тыңлаганнар туганнары,
Дус-ишләре тыңлаганнар.
Дошманда да колак бар ич, –
Тыңламыйча булмагандыр.
Заманнарны кисәр көйгә
Ни җырламас ул моңлы баш?!
Ике егет бик охшашлар...
Мин аларга бераз охшаш:
Тауларда да йөргәнем бар,
Шулай төнлә җырлаган бар.
Аннан тагы, ни әйтсәң дә,
Якташлар бит әле алар!
Йокы алмый шуңа бүген,
Мин вагонда уйлап ятам:
Хәтеремдә– учак уты,
Ике егет безнең яктан.
Киемнәре кипте кебек,
Якташларым ит кыздырды.
Язмышлары кара төндә
Кара юлга ятып торды,
Аннан китте ике егет;
Язмышлары алдан бара –
Үзе бара һәлакәткә,
Яшәүгә, дип алдап бара.
Бик охшашлар ике егет,
Мин аларга бераз охшаш;
Ни әйтсәң дә, якташлар бит,
Ниндидер кыл безнең тоташ.
Бер чишмәдән су эчкәнбез,
Тик заманнар хәзер башка.
Хәле башка Камышлының,

Һәм минем дә хәлем башка.
Мин җырлаган җырлар башка,
Ияр үзгә, атлар бүтән...
Мин күрмәгән ике якташ,
Һаман сезне истә йөртәм.

*1975*

## ЭШ БАШЫ

Эш башы шәп инде, –
миче бар, ташы бар...
...Егетләр
мәш килеп
бүрәнә ташыйлар.
Без менә дүрт егет:
Уфадан – Мәүләтҗан,
Ижаудан – Алексей
һәм Равил – Ульяннан.
Ә мине – Казаннан,
шагыйрь дип йөриләр.
Чынында дусларым –
үзләре шагыйрьләр.
Бергәләп бер эшне
язып та ташладык:
Су-Уса ярына
без мунча ясадык.
Татарның эш башы
мунчадан диимме?
Башланды, башланды –
эш башы шәп инде!
Миче бар, ташы бар,
гайрәтле пар бөрки.
Яшел ут ялыдай
гайрәтле себерке.
Кем генә булса да
килерлек, күрерлек,
Мәскәүдән нефтьче,
министр керерлек.
Чыгабыз юынып –
кайнарлар, кызыллар.
Күшеккән Су-Уса
мунчага кызыга.
Әй, синең уй юкмы
карарга юып баш,
ак төннәр уздырып
арыган ак Кояш?!

## ЯКТАШЛАР ЯНЫННАН...

«100 нче буровой» –
Гомердән бер өзек,
Якташлар яныннан –
Себердән бер өзек:
Кояшлы ачыклык,
Караңгы ешлыклар...
...Кар беткәч,
Җир тулып,
Өр-яңа эш чыккан.

Сазлыклар, урманнар
Көтмәгән яңа эш –
Башланган бораулау,
Кузгалган төзелеш.
...Трактор артына
Тагылган тростан
Балыктай наратлар
Качарга тырыша;
Үләннәр йолкына,
Һәм баса тырпаеп
Кулларын күтәргән
Кыз кебек яшь каен.
Борчылып аюлар
Йөриләр куеда...
Тирәндә – нефтьтә
Борчылган аюдай...
...«100 нче буровой».
Чәй – учак көлендә.
Тәмәке төтене
Ылыска эленә.
Көннәргә ак төннәр
Төенсез бәйләнә,
Кояш – ал тәлинкә –
Туктаусыз әйләнә.
Үкереп үр ала
Кып-кызыл «Татр»лар.
Йөк баскан елганы,
Соры су тартылган.
Шыгырдап баржалар
Ярларга туктала.
Йөк зурга краннар
Ухылдап тын ала.
...Җиңү бар урында
Ник әле хәвеф бар?! –
Кешеләр өстендә
Чайкалды торбалар
Һәм тимер мәйданга
Төштеләр гөрселдәп...
Ярдәмгә ташландык –
Якташның берсенә...
Тиз аны илтергә –
Үзәккә очарга...
Бик иртә шул аңа
Гомерен очларга.
Калабыз ышанып,
Терелер, йөрер дип.
...Киң Себер күгендә
Вертолет дерелди.

*1973*

## ЕРАКЛАРДА...

Урман монда – авыр яшел,
учак артык якты.
Чатный кисәү хуш ис сибеп,
чәйгә төшә чаткы.
Ылыс яна,
безнең канда
чиксез җегәр сыман.

Һәрберебез
йодрык белән
аю җиңәр сыман.
...Гөрли пычкы,
кара яшел наратларны ялап.
Монда узган минутларның
ак төпләре кала.
Көннәр төпкә баш куялар.
Айлар балта тоткан –
алар шулай, безгә карап,
үз хәлен оныткан.
Кандай кызыл уйдык-уйдык
җиләк ята мүктә.
Җирдә шәһәрләр
юк кебек,
һәм без монда күптән
әйтерсең
җиләк нәселе,
учак нәселе без.
Дымлы бу кич һавасында
мең тәм төшенәбез.
Әйтерсең шунда туганбыз,
гел калырбыз торып.
Тик безне юлга чакыра
автобус кычкырып!

*1973*

## МИНЕМ ЯШЬЛЕК

Ә кайдадыр,
шул төзелешкә төзеп,
һәлакәтле ракет коралар.

*Ә.Давыдов*

Яшьлек елларымны
Сарут белән бутап аттым
Яшел эскерт өстенә,
Буразнага салдым –
Кыр тутырып
Эре башак булып үстеләр.
Кайсыларын,
Асфальт белән кушып,
Олы юлга җәеп калдырдым;
Кайсыларын
Корыч эреткәндә яндырдым –
Төтен булып
Биек торбалардан чыктылар...
Һаман елларымны чакырам:
– Саклармын, – дим, –
Җил дә тигезмәм, –
Үзләрен
Тимербетон белән аралаш
Урнаштырам яңа нигезгә.
Мәһабәт йорт
Калкыр бик тиздән.
Безгә борын төбәп
Торган ракеталар
Җиргә иңеп керер
Куркудан,
Ак этажлар түбәсендә
Ал байракка сеңгән

Минем яшьлек
Калыр дулкынлап.

*1965*

## НӘКЪ УНБИШ ЕЛ ҮТКӘЧ...

Көзге төнгә йөзен куйган иде
Күкчәтауның иркен даласы.
Тракторлар уты уйный кырда,
Утка керер төлке баласы.
Тракторлар уты калды кырда,
Анда минем сөргән җирем бар.
Анда серем белгән дуслар эшли,
Барысы да анда калдылар.
Мине алып китте машиналар,
Хәтерләүләр арттан калмады:
Кайчан гына әле буразнада
Тирли-тирли чылбыр ялгадым.
Уйга килде кинәт бер чибәркәй,
Хаталанып куйдык бугай шул:
Җанын бүлеп миңа бирер иде...
Якташына иргә чыкты ул.
Сөю хакындагы безнең сүзләр
Балаларча җиңел алданды, –
Ятимнәрне җыйган ана кебек,
Дала җыеп калды аларны.
Минем белән китте хәтерләүләр,
Ни дип калды икән дусларым?
Авырлыктан качты бу егет, дип
Әйтүче дә бардыр ул барын...
Китүченең юлы гел уңаймы?
Эшләгәннең эше – җиңелме?
Нәкъ унбиш ел үтте,
Бер уйласам,
Эшлим кебек эшем җимереп.
Бер уйласам, көзгә йөзен куйган
Күкчәтауның төнге даласы...
Һәм кайчаннан бирле тракторым
Кабыза алмый йөдим ләбаса.
Дуслар сөрә әнә.
Төн караңгы,
Шырпы сызып карыйм моторга.
Ни булды соң әле?
Мотор салкын...
Тәмәкем дә беткән тартырга.

*1972*

## КУЛЫМ НЫГЫСЫН ӘЛЕ, НЫГЫСЫН

Минем куллар сабый чагымда ук
Шактый гына каты булганнар,
Тотсам,
Каты гына
Тотканмын.
Авылдашлар:
«Аннан алып булмас!» – дигәннәр.
...Күлмәгенә ничек ябышсам да,
Әткәмне
Тартып алды сугыш –

Җибәрдем...
Бәрәңгеләр тоттым...
...Гөлләр тоттым.
Атлар тоттым,
Тоттым
Йөгәннәрнең бавын, каешын...
Мин һаваны тоттым,
Бармакларым белән
Сөзеп таптым аның ямен,
Колач белән тоттым кайгысын, –
Кулым ыгысын әле, ыгысын!
...Каләм тоттым,
Руль, рычаглар, ломнар тоттым, –
Кулым ыгысын әле, ыгысын!
Ыгысын да...
Аннан...
Нәрсә, минем уем, –
Ябышып тормышка,
Җир өстендә
Мәңге яшәп калу түгел лә...
...Киткән чакта,
Кайгыларны, сугышларны эләктереп,
Бөтенләйгә
Алып китмәкче мин
Тегендә.

*1966*

## КҮТӘРЕЛДЕ ЧҮРӘКӘЙ

Күтәрелде Чүрәкәй,
чүгеп алды су яры...
Кемдер чалгы чүкеде,
кемдер чалгы кайрады.
...Ут биеде учакта,
утта казан сайрады.
Без өмәдә кайналып,
ел үсәсен көн үстек.
Кашык хәтле малайлар
чүмеч-чүмеч су эчтек.
Ничә чүмеч тир койдык,
саны истә калмады.
Калды истә чәчәкләр,
мәңгелеккә алланып.
Ак яулыклы апалар –
гел хәтердә күзләре!
Битен юган абыйлар,
яшел ярга тезләнеп...
Уйлап бүген аларны,
ялгыз торам бу ярда.
Әллә нинди моңым бар,
шуны кая куярга?!
Кем дә килми яныма,
кем дә чалгы кайрамый,
ут биеми учакта,
утта казан сайрамый.

...Күтәрелде Чүрәкәй,
чүгеп алды су яры.

*1984*

## НУРСИБӘ ӘБИ ӨЙДӘДЕР

Ул авыл матуры булган,
өе бар, җирле икән.
Язмышы
ялгыз картайткан,
ялгызы чирли икән.
Кичке җил аны беләдер,
төртелә капкасына.
...Өйдәдер әби, өйдәдер,
бик иртә яткан сыман.
Кемдер энә, гармун уйнап,
әллә кемне җылата...
Бакчаларда әллә боз ул,
әллә юеш кар ята...
Сукмаклар язга үреләэ,
язгы юллар аларган.
Яшь яңа матурлар чыга
чыркылдап мунчалардан.
...Машина керә авылга,
Кунак килә берсенә...
Җылы мичләр җылы сибә,
мең тәрәзә нур сибә.
Нурсибә әби өйдәдер,
өендә суык сыман:
утыны да, уты да юк,
ул үзе дә юк сыман.

*1987*

## ЯҢА ЕЛ ТӨНЕ КАЗАНДА

Яңа ел төне Казанда,
мондый мәлдә кем йоклар?
Авылдан килгән карчыклар
бәйрәм күрергә чыккан.
Ут тавышлы белдерүләр,
өндәмәләр кычкыра...
Ракеталар, күч-күч итеп,
күккә бәйрәм очыра...
Нурда һәм карда чайкала
балалар, чаналары...
Мәрхәбә, ак ел шәһәргә!
Кара ел түгел, ярый...
Бөтен Казанны кочаклап,
яктылык бии икән...
Тәрәзәләрдә, мәйданнарда
гел шатлык көе икән...
Карчыклар шуның өчен дә
бәйрәм күрергә чыккан.
Сөенә дә, моңлана да,
уйлана да карчыклар...
Дөньясы кинәт аларга
бер бию көе сыман...
Бәләкәй өйләр өстендә
зур йортлар бии сыман.
Таныш та, ят та кебек төн,
мондый мәлдә кем йоклар?

Авылдан килгән карчыклар
бәйрәм күрергә чыккан.

*1982*

## ӘНКӘЙ, ӘНКӘЙ...

Акыллы бул, дидең, әнкәй, әнкәй,
кер кундырма, дидең, күңелеңә.
Мал даулама, дидең, дан даулама,
бар да фани, дидең, бар да үлә.
...Каты булма, дидең, кешеләргә,
каты күңел – газап чыганагы.
Син әйткәнчә генә яшәр идем,
чыдамамдыр, ахры, чыдамамын.
Бу дөньяның һәр әнкәсе шулай
әйтмиме соң әллә баласына?
Бар кешеләр, шундый кешеләр бар:
карашыннан корыч өметең сына.
Алар ышыгында акылсызлык
бәйрәм итә исереп, биеп, көлеп.
Әллә нәрсә булды, әнкәй, җирдә:
акыл бүген артык акча кебек.

*1985*

## КАЕННАРНЫ ҮТЕП ӨСКӘ МЕНДЕК

Ул каеннар, күккә ишарәләп,
Җир туганнан бирле тора сыман:
шуның өчен генә бөтен дөнья
йортын өскә таба кора сыман.
Шук малайлар шуның өчен генә
үрмәлидер, ахры, агачларга;
һәм кешеләр шуңа өскә карый,
мәртәбәгә ирешә, менә данга.
...Ерак калган саен каеннарым,
мин яхшырак күрәм ул урманны.
Юкәләрен күрәм, усакларны,
имән чикләвеге коелганны.
Анда яфрак күмә Мөбин чокырын,
көн дә үтми яшел яфрак аша.
Кара чокыр төбе күп яткан ул –
шыгырдатып арба гомерен ашап.
Минем бабам гомере шуннан узган,
әткәм ничә чыккан аны кичеп:
ат куганы– сызгырганы булган,
күпме печән чапкан әйрән эчеп.
Ә печәнлек анда – җиләк кенә,
җиләк төсе тырма тешенә йога.
Кызыл тешле тырмасын гел әнкәм
элеп куя иде ак каенга...
...Ул каеннар, күккә ишарәләп,
Җир туганнан бирле тора сыман.
Һәм шуларга карап бөтен дөнья
йортын өскә таба кора сыман.
Без дә өскә мендек – каеннарга,
каеннарны үтеп өскә мендек:
дөнья каршысында,
үлем каршысында,

яшәү каршысында –
    күтәрелдек.

*1974*

## КЫШКЫ СУЫКЛАРГА КЕРДЕК ИСӘ...

Кышкы суыкларга кердек исә,
Хәтеремә төшә үткәннәр.
Аякта нык хәзер, өстә калын,
Онытылсын иде ул төннәр:
Тәрәзәләргә салкын урман чикте, –
Ә ягарга утын юк иде...
Шәһәрләр ач иде, авыллар ач, –
Сугыш кына ул чак тук иде.
Су буенда безнең ач әнкәйләр
Су җылыта иде малларга.
Башлары боз иде, өсләре боз –
Боз хатыннар кебек аналар.
Кулларында һаман бозлы чиләк,
Юлларына калын боз сарган.
Елгасы боз аның, дөньясы боз...
Таймас өчен ныграк басарга!
Итәкләрен тарта боз чуклары,
Бөкләгәндә җиңнәр сыналар.
Өйгә кайтып безне җылытырга
Каян җылы тапкан соң алар?
...Бик өшетеп хәтеремә төшә,
Йөрәгемә төшә ул көннәр.
Күшегеп тора иде, бөгәрләнеп,
Morҗалардан чыккан төтеннәр...

*1973*

## СӘБӘП

Чын яшемнән мин яшь күренәмдер –
Җитди генә сәбәп бар моңа:
Миңа афәт җиле өргән чакта,
Әнкәм басты җилнең каршына.
Салкын җилләр аны кыйнадылар,
Кайнар җилләр аны пешерде.
Фашист бомбасыннан ауган йортлар
Аның иңнәренә ишелде...
Бу дөньяда ул эшләгән эшне
Мин санап та чыга алмамын.
Ул төясә, арба сыгыла иде,
Каян шундый куәт алгандыр?
Аткайлары ак күбеккә батып,
Олы юлда егылып үлделәр.
Үзе тартып китте атлар йөген
Бишек тирбәтәсе кул белән!
Шундый әнкәм булган өчен дә мин
Үз яшемнән бераз яшь калдым.
Әнкәм генә менә...
Картайды шул,
Үз яшеннән күпкә картайды.

*1970*

ТАБЫШ

Тау өстендә
Кояш көйрәде.
Тигез ритм белән
Тибә
Тракторлар йөрәге.
Чык бии кузгалаклар учында;
Тургай бөтерелә,
Очына!
Мотор шавы
Тыпырдап
Бара
Буровой вышкасы очында.
Мотор шавы
Каеннарга сарыла.
Чәчәкләр,
Чәчәкләр,
Чәчәкләр каршымда:
Кызыллар, зәңгәрләр, сарылар...
...Ландышлары,
Әремнәре исе белән бергә
Сеңгән хәтергә
Шушы урманның
Һәр калкулык,
Һәрбер чокыры;
Шулардан уздым ич,
Тай кебек ияреп әнкәйгә,
Көненә ничәшәр чакрым.
Ачыктырды,
Арытты үземне
Бормалы,
Чытырманлы сукмагы,
Җиргә ятып ял иттем.
Әнкәй һаман
Зелпе тамыры тукмады,
Кабыгын салдырды.
– Әнкәем, ардыңмы?
Нигә җыясың
Шул тамыр кабыгын?
Аз гына уйланып торды да
Әйтте ул,
Йөзендә елмаю кабынды:
– Алтыным, кирәк бит...
Аңардан
Резина ясыйлар
Заводлар...
Резина итекләр, туплар,
Бик күп нәрсәләр.
– Кирәкми, кирәкми миңа
Берсе дә,
Кайтырбыз, дигән идең бая!
Ул җәя кулларын:
– Кил, кая,
Кысып
Яратыйм үзеңне,
Син зур ич,
Аңларсың сүземне,
Йә, уйлап карале?!
Туп сорап елаучы малайлар,

Итексез әниләр бар әле.
Еракта-еракта
Машина туктаган:
Баллоны шартлаган, –
Тузгандыр...
Яңа баллонга резина бирмәсәк,
Ничек кузгалыр?
Әткәңнәр сугышта югалды,
Безгә шул күбрәк эш калды;
Азаер,
Азаер әле бер,
Менә сез, малайлар,
Аякка ныграк баскачтын.
...Муенны пешерә сулышы,
Йөрәге,
Тойгысын тәнемә,
Миемә сеңдереп,
Нык кага.
Кулларым изрәгән,
Сыланып
Кадерле, манма су аркага.
Бераздан
Шул арка
Машина баллоны шикелле
Бөгелгән
Зур зелпе куагын
Суырып чыгарды төбеннән...
Менә шушыннан...
Нәкъ шушы ноктада
Бүген
Буровой вышкасы туктады;
Кояшка тоташты
Ярсыган моторлар тавышы.
Нефть –
Табышым.
Нефть –
Резина... ефәк... капрон...
Эшелон-эшелон агыла
Илем юлларыннан.
Хәтерлим:
Алар барысы да башланды
Әнкәемнең кечкенә,
Чарпаланган кулларыннан.

*1965*

## ҖАНЫМ ЧАҢЫ

*(Әнкәйне җирләгәч)*

Әлмисактан гөрләгән су
гөрләп кала әле.
Һәм исәннәр яшәп кала,
гөлләр кала әле.
Яшәрбез дип бергә-бергә,
юанасы килә. –
Чынлыктан качып шигырьгә,
югаласы килә...
Бик әрнетә икән чынлык,
әрни Җирем-Кырым!

Өер-өер саллар сыман
йөзә матәм җыры.
Бер якында, бер еракта
сәер кара көлеш...
Бии кемдер ыштансыз да
тәһарәтсез килеш...
Кемдер, илләр данын егып,
канын ерып кичә...
Үз юлдашын буа кемдер,
кемдер агу эчә...
...Әлмисактан гөрләгән су
эчәр өчен иде...
Исәннәргә җаным чаңы
ишетелмидер инде, –
җибәрмәсләр иде җирнең
болай ук кадерен.
Бу Җир – минем әткәй белән
әнкәем кабере.

*1992*

## ӘНКӘЙНЕ ХӘТЕРЛӘҮ

– Зур улым! –
дигән идең дә
йөземне юган идең;
и рәхәт елаган идем,
каты егылган идем...
Юындырып-коендырып,
мәңгегә киттең, әнкәй.
...Яңгырап
узган
яңгырдай
уздың да киттең, әнкәй.
Кояшың калса да күктә,
кипте бары өс-башым.
Күз яшен киптерми икән
хатирәләр кояшы.
Зур улың була алмадым,
Кеше мәңге бәләкәй;
елыйм да
йөземне хәзер
үзем юалам, әнкәй.

*1997*

## САГЫНУ

Еллар елга охшамый шул,
язлары үзгә тора.
...Үзәкләр өзелә тора, –
кемнәрдер сагындыра.
Сагындыра Тукайларың,
Җәлилләр истә тора...
Гел тулы сагыну дәрьясы
һәрвакыт чиста тора.
Истә Шәрәф, истә Әнвәр –
сагындыра югалган...
Якты безнең күзләребез
сагынуларда юганга.
Такташны бик сагынганда,

Туфанга карар идек...
Инде Туфан сагындыра,
Фаилләр... Ярар инде,
кемнәрдер безгә карыйсы –
кемнедер сагынганда.
Пакь яшәдек, ак китәбез,
Коенып сагынуларда.

*1983*

## КҮКТӘ САРЫ АЙ ЙӨЗӘ

*(Авыл егетләренә)*

Бүрәнәдә – егетләр.
Күктә сары ай йөзә:
безнең яшьлек, валлаһи,
нәкъ шушылай, нәкъ үзе!
Исәнмесез, егетләр!
Хәлләрегез яхшымы?
Җырлыйсызмы?
Әйтегез, әйттерегез,
их, шуны! –
«Китәмен еракларга,
җитәрмен Уралларга.
Баскан эзләрем калсын дип,
нык басам урамнарга.
Әй тал нечкә, тал нечкә,
талдан билкәең нечкә.
Бу кадәрле сөюләрең
булыр бит үкенечкә.
Керәсең төшләремә,
сары күлмәк өстеңдә.
Сары күлмәгең өстеңдә –
ни булды син мескенгә?»
Туктатыгыз, егетләр!
Мондыйны җырламагыз.
Сөйгәннәргә авыр хәл
юри дә юрамагыз!
Без дә шулай җырладык,
нигә кирәк ул сезгә?

...Бүрәнәдә – егетләр.
Күктә сары ай йөзә...

*1978*

## ШУНДА СИНЕ КҮРМИМ БИТ ҺАМАН...

*Каләмдәшем Хәйдәр истәлегенә*

Бик елак көн –
яхшы хуҗа этен
өйдән чыгармаслык дигәндәй.
...Резин итек, ак плащың киеп,
иртүк килдең миңа ярдәмгә:
– Бергә-бергә,
абый,
без яшәрбез! – дидең.

Юньсез малай, вәгъдәң кайда соң?
Бермәл – миңа,
башкаларга ләм-мим –
дөньядан ук китеп баргансың.
Озата алмадым ич соңгы юлга,
күрми калдым – җанны шул кисә.
Бер ел йөрим синә ачуланып,
гаепсез лә үзең югыйсә...
Ничек алдандың да иярдең син
үлем кыяфәтле язмышка?!
Уең – сәнгать, буең сәнгать иде,
тере сәнгать идең, мальчишка!
Каты әйткәч, әйтим йомшагын да,
ишетмәсәң һәм ишетсәң дә...
Машинкаңда һаман шигырь чүким,
акча гына артмый кесәмдә.
...Туздырдылар Казансуның ярын –
без тергезгән учак урынын.
Шагыйрь Мирза килгәч, күрмәс бүтән
безнең анда басып торуны!
Ленин күперен яңарттылар, тик ул
Хәйдәр узарга да ярамый.
Тукталышлар – «Кутуй» һәм «Чишмәле» –
тора әле синсез каралып.
Галәм үзе болай якты гына,
шунда сине күрмим бит һаман.
...Чиксезлекнең чиксез бер җирендә
очрашырбыз кебек яңадан.

*2001*

## СЕРЛЕ ДУСТЫМА

*Фарсель Зыятдиновка*

Мин шикләнеп карыйм сиңа кайчак,
Күптәнге дус үзем синең белән.
Аз беләсең мине, серле дустым,
Ахры, мин дә сине бик аз беләм.
Бер син җилдә очкан мамык кебек,
Бер кузгатып булмас таш шикелле.
Бер син хәтәр-көчле янгын кебек,
Бер янгыннан калган чәчәк көле.
Бер кагасың ярга диңгез булып,
Бер диңгезгә киткән каек кебек.
Үз шатлыгың белән исерек син,
Чит кайгылар белән аек кебек.
Син бу җирдә юкка яшәмисең,
Юкка дуслашмадым синең белән.
Ләкин аз беләсең мине, серле дустым,
Ахры, мин дә сине бик аз беләм.
Безне дөнья белсә, нишләтерләр? –
Уем ялгыш булса, кичер берүк.
Йә атарлар безне, йә асарлар,
Йә салырлар һәйкәл бүгеннән үк.

*1973*

## АСИЯ АПАГА

*«Яшь ленинчы» машинисткасына*

Бер карасаң гади генә,
Җиңел генә кебек эшең.
Әмма син безнең газетка,
Әмма син әдәбиятка,
Әмма син бөтен кешегә
Шундый, шундый кирәк кеше!
Шигырьләр дә синнән уза,
Синнән уза прозалар,
Мәкаләләр синнән уза.
Барысын да беләсең син –
Кем ни яза, ничек яза.
Иң беренче фикереңне
Әйтәсең син язучыга.
Шунысы кызык: синең фикер
Гаҗәп дөрес булып чыга.
Сәгать кебек эшли торгач,
Сәнгать серен син тапкансың.
Акылыңның сизгерлеге,
Күзләреңнең үткерлеге,
Бармакларың җитезлеге –
Гел саклансын,
Гел саклансын.

## СОРАМА, КАМЫШЛЫ

Сорама, Камышлы,
бер сөйләрмен әле.
Гаҗәбрәк бит әле
Әнвәребез хәле.
Кыска итеп әйтсәм:
таза гына иде,
яза гына иде,
яза гына иде...
Матбугат йортына
сыялмыйча тавышы
җиргә җәелә иде,
тәрәзләрдән ташып.
Бу дөньяны уйлап
кем генә авырмый?
Әнвәрдәй шагыйрьгә
авыру – авырмы?!
Адымнары җиңел,
уе бик зур иде.
Кешеләргә таба
һаман килде,
килде...
Кинәт гаип булды,
тордым карап, күреп:
ул югалды безнең
күңелләргә кереп.
...Шулайрак бит менә
Әнвәребез хәле.
Сорама, Камышлы,
бер сөйләрмен әле.

*1968*

## ХӘСӘН САРЬЯНГА

*(Вафатыннан соң)*

Өзелеп яратсак та дусларны,
берәм-берәм җирдән китәрбез...
Яратсак та җәйләр, кышларны,
бала-чага, хатын-кызларны,
берәм-берәм шулай китәрбез.
...Бизмәсәк тә кырдан, үләннән,
көйрәп яткан бөрлегәннәрдән...
Тәм тапсак та төрле телләрдән,
туймасак та торган өйләрдән,
барысын да ташлап китәрбез.
Калдыралмас безне биредә
калдырырга теләгәннәр дә.
Төгәллисе мөһим эшләр дә
калдыралмас безне биредә.
Калдыралмас безне Кояш та,
йолдызлар да, Идел буе да...
Калуыбыз кирәк булса да –
калдыралмас безне бу дөнья.
Шулай булгач,
моннан китәрбез –
курыкмыйча гына, тын гына,
күптән киткән дуслар янына,
берәм-берәм шулай...
Китәрбез.

*1979*

## ЙӨРЕП ЧЫГЫЙК ӘЛЕ КАЗАННЫ

*Шагыйрь Роберт Әхмәтҗановка*

Сине күрми торсам, әллә ничек,
танып булмый көнне, Кабанны.
Йөреп чыгыйк әле, бер күрешкәч,
чигеп чыгыйк әле Казанны.
...Үзебездән әйбәт дуслар монда
очрап, хәлне сорап үтәрлек...
Күрмәмешкә салышып үтсәләр дә,
үпкәләмик артык, күтәрик...
Исемебез чиста, кием пөхтә,
акча да бар кесә төбендә. –
Без бит риза шуңа, данга менеп,
күккә ашкан даһи түгелләр.
Дәрәҗә бар– әйбәт уңыш бирер
сары бодай кыры биеклек.
...Ял итәргә дисәк, диван нигә?
Безгә таш та, җир дә бик ипле.
Берәүләрне ун кыз сөйсә– нәрсә?
Безне сөйгән, әйдә, бер булсын.
Киеме ни безгә, кием аша
җиткерсеннәр йөрәк җылысын.
Чәчәк сузмый гына тыңласыннар,
әй укырбыз шигырь туктап бер.
Һәм, кем белә,
Казандагы гөлләр,
бәлки, бар да безнең өчендер.

*1985*

## КАЛӘМДӘШЕМ РӘДИФ ГАТАШНЫ ОЗАГРАК КҮРМИ ТОРГАНДА ТУГАН УЙ

Ул шулай көлә belә,
яктырып килә белә.
Көмеш тәңкә сипкәндәй,
тавышын сибеп көлә.
Җыя алсаң көлүен –
учка җыеп торырлык,
кесәңә тутырырлык,
куенга тутырырлык.
Тәнең шуны сизәрлек
рәхәтләнеп беравык.
Аның гына көлүе –
шундый тере матурлык.
Аның гына көлүе –
шундый рәхәт түгелү.
Тик отарлык түгел ул,
онтырлык та түгел ул.

*1983*

## ИЛДАР ЮЗЕЕВКА

*(Бераз шаярып)*

...Безнең урын,
бу нәкъ безнең җир, дип
җиң сызганган идек.
Хуҗаларча йөреп,
ут өереп,
эшләп алган идек.
Яшәр өчен урын
сайлаганда,
ялгыштыкмы әллә?!
Турайт әле билең,
әйт кызык сүз,
хәлләрне күр әнә!
Без тормаслык гүзәл
бу урынга
яшьлек кора оя.
Кая китик?
Монда, әй, валлаһи,
Картаерга оят.

## РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИНГА

Миңа кердең Мәскәүдә,
сөйләшәсең, ипле син.
Нидер язып кайт, дисең,
нидер табып кайт, дисең.
Бәлки, нидер табылыр, –
утлар якты үзәктә...
Беләсеңме, син миңа,
тапмасам да, сүз әйтмә.
Күпләр килгән табарга,
әле һаман киләләр.

Этә-төртә Мәскәүгә –
югалырга керәләр.
Югалалар яшьлектә,
югалалар картлыкта.
Елмаешып, исереп
югалалар шатлыктан.
Төсләре дә үзгәрә –
соры юлда сорылар.
Тавышлары – хәрабә,
башы бар да, соңы бар.
Һич күренми эзләре –
шундый якты үзәктә?!
Беләсеңме, син миңа,
тапмасам да, сүз әйтмә.
Мин үземне югалтмам,
хәтта нидер язармын.
Күрешербез исән-сау
уртасында Казанның.
Алда безнең җәйләр бар,
күп кышларда әле без,
ике кара ир булып,
ак юлларда йөрербез.
...Һәм иҗаты тукталган
егетләрнең өенә
йә кызлар бүлмәсенә
илһам булып керербез.

*1977*

## ИЛҺАМ ШАКИРОВКА

Бергәлеккә-бердәмлеккә
чакыру чаңы булдың –
син күзе булдың татарның,
сызлаган җаны булдың.
60 ка җитеп сызлавың
авыр бит, авыр ла ул:
йөздә үтмәс, меңдә бетмәс,
мәңгегә калырмы ул?
«Туган тел»ле халкың калса,
чынга ашар өметең.
Котлыйбыз сине, туганкай,
чын күңелдән үз итеп!

*1995*

## ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ

Тормыш тоташ бәйрәм түгел,
булгалый бәйрәмнәре.
Ник булмасын бәйрәмнәре,
булганда Гәрәйләре?
Ул Гөргөри, Григориймы –
анысы Алла эше.
Әдәбият дөньясына –
безгә кирәк бу кеше.
Мәхәббәттә, дуслыкта да,
иҗатта да алдыра...
Моннан да зур бәйрәмнәрең
булсын, Гәрәй, алдарак!

*1996*

## КЛАРА БУЛАТОВАГА

Юлга чыктың «Гел кояшка карап»,
гел кояшка карап яшәдең.
Күзләреңдә шуңа гел нур булды,
нур киптерде – килсә яшьләрең.
Елмаюың нурдан гына торды,
беләсеңдер үзең калганын...
...Бәйрәм котлы булсын!
Гомере озын булсын
синең кебек якты баланың!

*1996*

## ДИЛӘРӘ ТУМАШЕВАГА

Себерне сөрген диләрме?
Сөрген түгел ул Себер!
Татарлар җире ул, дисәк,
сүзнең иң дөресе дер!
Кара урман – тайгаларда
мөмкиндер адашырга...
Адашмаган, юлын тапкан
Диләрә Тумашева!
Туган телен, туган җирен
яктырткан шәхес бит ул:
гыйлеме белән генә түгел,
хатын-кыз буларак та гөл,
гөлләрдән нәфис бит ул!

## ВАФИРӘ ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНАГА

Безгә әле тауга менәсе дә
чишмә суларына төшәсе.
Синең сүзләр, бәгырь, безнең өчен
үзе, үзе – моңнар чишмәсе.
Син җырласаң, яшәр милләтебез,
чакыр, чакыр безне көрәшкә!
Былбылларның шундый гадәте бар, –
тик үзара алар серләшә...
Сине тыңлап йолдыз таптык әле,
якты җиле җанга ук керә.
Бәйрәм шатлыгыңны уртаклашып,
без котлыйбыз сине, Вафирә!

## ЛЕНА ШАГЫЙРЬҖАНГА

Түшәгең дә шигырь синең,
шигырьдер юрганың да;
«Мөлдерәмә күңел»ең дә
шигырең юлларыдай.
Яшьләрне, яшьтәшләреңне
Көнләштереп яз гына.
Гомерлеккә кердең, Лена,
син шигърият язына!
Кычкырып сине сөйлибез,

кайчакта– яшерен генә.
Котлыйбыз иҗатың белән
һәм булган яшең белән!

## СИН САГЫШЛЫ ШУҢА, КАЛӘМДӘШ

*Айдар Хәлимгә*

Әй, шатланып очырган идең
син «Беренче карлыгачлар»ны.
...Шатлыгыңа сукты язмышың,
җыертты ла синең кашларны.
Маңгаеңа сырлар киртләде,
елатырга иде исәбе...
Иңнәреңдә инде илле яшь –
еламыйбыз, исән ич әле!
Бәйрәм көнең белән котлыйбыз,
табында зур иҗат байлыгың!
Елмаеп куй шулай – үзеңчә,
бугазына басып кайгының!
Синең язмыш– шагыйрь язмышы,
син табышлы шуңа, каләмдәш.
Һәм язмышың – татар язмышы,
син сагышлы шуңа, каләмдәш.
Бәйрәм көнең белән котлыйбыз,
табында зур иҗат байлыгың!
Елмаеп куй шулай – үзеңчә,
бугазына басып кайгының!

*1992*

## БЕЗНЕҢ КҮРЕШҮЛӘР КҮП БУЛМАДЫ

*Рәшит Имашка*

Сәлам сиңа, Имаш, Мингалимнән,
үзең кебек гади бер заттан.
Шигырь аша кысыйм зур кулыңны,
файдаланыйм әле форсаттан.
Безнең күрешүләр күп булмады,
эш бетмәде һаман... Эшлибез.
Яшәмәдек дисәм, гөнаһ булыр,
алтмышка ук җиткән яшебез...
...Халык йөрәгенә тормый, туган,
бүләк, исем кебек нәрсәләр.
Бәйрәм көнең белән,
рәссам Рәшит,
йөрәк ачык сиңа – мәрхәбә!
Безнең күрешүләр күп булмады,
бер булганы йөзгә тиң иде.
Уфа урамнары хәзер тардыр,
без узганда гаҗәп киң иде.
Тик тараймас, Имаш, синең бүлмә,
күргән идем барып, син дәштең.
Иҗат иткән каенлыгың аша
мәңгелеккә чыгып сөйләштек.
Безнең күрешүләр күп булмады,
алда, бәлки, ешрак күрешербез.
Яшәмәдек дисәм, яхшы түгел,
алтмышка ук җиткән яшебез!

## МӘГЪСҮМ ХУҖИН – МӘГЪЛҮМ ХУҖИН

– Хуҗин килгән!
– Узсын түргә!
– Әйдә, каләм остасы!
– Йөз грамм ул салыр бүген,
 әгәр ипләп кыстасак...
– Җитмешенә җиткән чагы,
уен түгел, кыскасы, –
сиксәнендә, туксанында
үзе безне кыстасын!
Ул Казанда, безнең янда
мәгълүм Хуҗин булды ла.
Сабаларда Хуҗин күптер
әдәбият тарихында
укучылар күзе өчен,
безнең өчен – ул гына!
Яшьләр аны, яшьтәш итеп,
Кочаклап ала әле.
Атлавынча – урта буын,
картларчарак та хәле.
Ишетми ул, тыңламый да
«Афәрин!» дигәннәрен.
Гаҗәп оста очлап йөри
хикәя «кибәннәрен»...

*2000*

## РИЗВАН ХӘМИДКӘ

Ничектер сизми дә калдык
сиңа илле җитүен:
әллә бу синең, күз буып,
бер мәзәк күрсәтүең?
Ихтимал алай булу да,
бар синдә андый сәләт.
Әмма гомерләр узуын
текелдәп сөйли сәгать.
Шуны сөйләп килә көзләр,
яфрак куна иңнәргә,
һаман кызлар матурлана.
Сиңа илле дигәннән,
котлыйбыз,
иҗат үрендә
егетлегең беленде!
Мөштәри карт сыман да син
«Актамырлар иле»ндә.

*1991*

## БАТУЛЛАГА

Һәр жанрга гашыйк булды,
ну азып та күрсәтте.
Афәрин, Батулла!
Яшәп, ул язып та күрсәтте.
Әкият арты әкият
ыргытып узып бара.

Проза сибеп бара ул,
пьесалар сузып бара...
Ул публицист, ул режиссер,
дулаган чагы аның.
Сәнгать кырын иңләгән дә
буйлаган чагы аның.
Үзенә илле тулган, ди,
котлыйбыз Батулланы!
Дуласын, әйдә дуласын,
тотмыйбыз Батулланы.

*1988*

## ӘХМӘТ РӘШИТКӘ

*60 яшенә җитүе уңаеннан*

Яшьлек кала кайларда?
Кала яшел елларда.
...Кара-кара юлларда
кала аунап еларга...
Калма, яшьлек, түкмә яшь,
Әхмәт кебек батыр бул.
Узып кит тә Әхмәтне,
йөгереп кире кайтыр бул.
Килешикме? Килешик!
Ул килеште! Без яздык:
Яшьлек белән очрашу
булсын, Әхмәт, бу язың!

*1996*

## ФАРСЕЛЬ ЗЫЯТДИНОВКА

*60 яшь тулу уңае белән*

Алтмыштан соң да еллар күп,
юллар күп әле, Фарсель.
Язучылар белән атла,
галимнәр белән бар Син.
Җитә бит Синдә егетлек,
чыныккан татар ла Син!
Абыйларга, сабыйларга
үрнәк булып
йөр, Фарсель.
Әйләнеп уздырмасалар
тормыш әйләнмәләре –
Син аларның күзләреннән
йөзеп узарлык әле...
Милләтнең Син бик кирәкле,
бик тә газиз баласы.
Бир, каләмдәш, безгә кулың:
– Бәйрәмең котлы булсын!

*1997*

## АЛЬБЕРТ ХӘСӘНОВКА

Тукай сорый:
– Кем бәйрәме?

Нишләде соң ул Хәсән?
– Альберт Хәсән –
ул бит безнең
прозада зур чәчән!
«Озын аяк» Хәсән ич ул,
шуңа җитте алтмышка.
И тагын, бер алтмыш елны
бирче, Ходай, бу дуска.
Киләчәктә безнең теләк,
бәлки, чынга әйләнер?
Ә бүген:
– Альберт, каләмдәш,
котлы булсын бәйрәмең!

*1997*

ШӘРӘ ЧӘРКӘ

*(Яшьтәшләрем мәҗлесенә язылган шигырь)*

Егет итте безне тормыш,
гел бирде йөк һәм йөгәр.
Без күтәрдек, без яшәдек,
без аякта, егетләр!
Көн килер дә, баш әйләнер,
искә төшеп бу чаклар,
егылырбыз мәңгелекнең
шәрә ботын кочаклап.
Ни ул безгә шәрә чәркә,
хет күтәрмә, хет күтәр?!
Төпләрендә сәер моң бар,
Күтәриктер, егетләр?!

*1994*

ЯЗУЧЫ ГӘРӘЙ РӘХИМГӘ

*(Ул 1941 елның 15 июлендә Шөгер (хәзерге Лениногорск) районының Аланлык авылында туган)*

Котлыйбыз сине, каләмдәш,
бер кочаклап җай гына.
...Булмады тормыш җилләре
сиңа да уңай гына.
Шулай да ерак киттең бит,
калдырып Шөгерләрне.
Истәлеккә алып киттең
моңнарын, шөгыльләрен.
Аланлыкта алан калды,
алан сиңа якындыр.
Анда атаң, анаң калды,
алар сиңа якындыр.
Туган якның бер чишмәсе
салкыннардан-салкындыр.
Бәлки, бүген, бәлки, күптән
эчең тулы ялкындыр...
Шагыйрьләрнең чын халәтен
каян төгәл беләсең?!
Илле яшьләр килсә килсен,
Күзгә яшьләр килмәсен!

*1991*

## ПАЛАТАДАШЛАРГА

Ә мин бүген төнлә йокламадым,
Тоймадыгыз гына сез аны...
Мин дәвалар өчен палатага
Алып кердем төнлә дөньяны.
Инде сулып килгән үләннәргә
Һәм гөлләргә сулар койдым мин.
Янып, әрнеп яткан мәйданнарның
Яраларын бәйләп куйдым мин.
Мин кан бирдем кайбер шәһәрләргә,
Мин җан өрдем кайбер юлларга.
...Зур дөньяның чирен бетерергә
Көч җитмәде минем кулларда.
Сезне уятырга кыймадым мин,
Уятасы калган шул аны...
Мин дәвалар өчен палатага
Алып кердем төнлә дөньяны.

*1970*

## ТАНЫШЫМА

Таш дивардай кайгы ауды өстемә –
Әмма күрдең минем йөздә тынычлык.
Күкрәгемә кунып шатлык талпынды –
Әмма күрдең, үзгәрмәдем, мин шул ук;
Һәм киттең син минем яннан: «Җансыз бу,
Кайгы-шатлык белми торган кеше!» – дип...
Моннан зуррак кайгы барын беләм мин,
Моннан зуррак шатлык көтеп яшимен.

*1967*

## ЭНЕМ ИСЛАМНУРГА

Яшь кенә идең син,
юк, сөйли алмыймын,
һәм сине дөньяга кем сөйләр?
Яшь кенә егетләр,
акылсыз егетләр,
акыллы гомереңне өзеләр.
Өзеләр, ишеттем
«А-а-а!» дигән тавышың
соңгы кат яңгырап калганын.
Тик, сиңа багышлап,
бер шигырь язарга
мин һаман булдыра алмадым.
Язарга тотынсам,
һәр сүздә «а» хәрефе, –
барысы да кычкыра башлады.
«А-а-а» дигән тавышка
күмелде дүрт тараф, –
ашыгып каләмем ташладым.

*1973*

## ЗӘҢГӘР ИШЕК

*Балачак дусларыма*

Бер-беренә охшаш чуерташлар сыман,
Уйга килә ярда безнең шәрә яткан...
Җәй артыннан кышка керде Җир әйләнеп,
Җир әйләнә сибеп безне төрле якка.
Һәрберебез каршысында зәңгәр ишек,
Без җитүгә, ул арткарак оча сыман:
Сакчысы бар, үзе калын, үзе бикле –
Җитәсе бар, бәрәсе бар, ачасы бар.
Үзен зәңгәр ишек итсә серле максат,
Дөнья безне кеше иткән, куәт биргән.
...Максатына тими узган ташлар кебек,
Соңгы көндә егылмасак иде Җиргә.

*1973*

## СОҢГЫ МӘСЬӘЛӘ

*(Кызым Алсу туган елда миңа 50 яшь иде...*
*Шул чактагы кичерешләрдән)*

Мәсьәләне бер-бер артлы
каршыма тезде тормыш.
Шуны чиш тә яшәрсең, ди,
чишәсең, ди, йә, тырыш.
Теш белән дә, баш белән дә
җитәрлек чиштем лә мин.
Уйлар йөртеп, иң сыгылып,
иллегә төштем лә мин.
Шунда да яңа мәсьәлә –
хет сөен, хет аптыра:
учымда тотам кызымны,
никтер ул елап тора.
Бу елак кеше булганчы,
мин туфрак буласы бар.
Ләкин мин туфрак булганчы,
ул кеше буласы бар:
алынмам моны чишәргә,
куркыта нәрсәгәдер.
Син, тормыш,
үзең чиш инде
бу –
соңгы мәсьәләне.

*1988*

## АЯК КИЕМНӘРЕ ТӨЗӘТҮЧЕ ДУСТЫМА

Ташла бүген чүкеч-кадагыңны,
Мин дә ташлап чыктым каләмемне, –
Безгә инде очрашырга иде,
Очрашырга иде күптәннән;
Атнасына җиде очрашып,
Җиде киңәшкәндә бүтәннәр,
Бер шәһәрдә торып киңәшергә
Безгә генә вакыт җитмәде, –
Ял вакытында яңаларны җыйдык,
Эштә искеләрне сипләдек.
Киттек әйдә бүген.

«Эш бит...» димә, «кешеләр...» димә,
Кичерерләр әле, кичерерләр.
Кеше эшен ташлап бөтенләйгә китә,
Кичерәләр әле кешеләр.
Ә без нәрсә... Иртәгәдән тагын
Җыр язарга утырам мин менә.
Син кадаклар белән, җепләр белән
Җыр чигәрсең аяк киеменә.
Тагы безне белмәүчеләр булыр,
Табылыр шунда аның белгәне,
Безнең җырга басып биегәйгәнен,
Безнең җырга басып йөргәнен.
Бүген исә
Икебез өчен генә
Сыра кайтарганнар паркка.
Салкын чишмә суын аз эчмәдек,
Сыра эчеп тамак карлыкмас.
Сөйләшербез,
Бәхәсләшер нәрсә
Болыт булып калмас фикердә,
Сөйләшербез...
Көне-төне
Икебез ике җирдә
Шушы бер тормышны уйлыйк та,
Шушы тормыш өчен, ким дигәндә,
Солдат итегенә җиз кадаклар аша
Олтан береккәндәй булыйк та,
Сөйләшергә вакыт тапмыйк икән –
Киттек әйдә!
«Эш бит...» димә, «кешеләр...» димә!
Кичерерләр әле, кичерерләр.
Кеше эшен ташлап мәңгелеккә китә,
Кичерәләр әле кешеләр.

*1966*

## ТУГАН ЯК КЫРЛАРЫНА

Әйтәдер кем, бу ялгыз, дип,
Китте дә югалды, –
Ә мин киткән чакта сезне
Үзем белән алдым.
Кайсы якка юл тотсам да,
Минем белән алар:
Чыелдап сары чебешләр
Уйнаган бакчалар,
Салкын чишмәле басулар,
Куянлы урманнар;
Таулар, бозаулар һәм тайлар
Җаныма сыйганнар.
Сезнең бүреләр белән мин
Мәҗлесләргә кердем.
Таксиларда, самолетта
Сезнең белән йөрдем.
Трибуналар, зур залларга
Чыкмадым мин сезсез;
Юл башым сез, юлдашым сез –
Хыянәтсез, тиңсез...
Шигырь тулы күкрәгемдәй
Якын күрәм сезне,

Утларга керсәм генә мин,
Алып кермәм сезне.

*1971*

## ЧИТТӘ ЯШӘП КАЛГАН ЯКТАШЛАРЫМА

Киттек тә без читкә, яшәп калдык,
Кунакка да кайтмый кайсыбыз.
Нефть чыгарабыз, йорт салабыз,
Җыр язабыз – бәхет ясыйбыз...
Бөтен кеше өчен тырышабыз –
Үпкәләмәс безгә туган як...
Ләкин туган якка бу кайтуда
Ни өчендер миңа кыенрак,
Качак кебек сизәм мин үземне,
Әйтерсең лә сез дә качаклар...
Башкаемны иеп уйга калам:
Безнең яктан артык кай яклар?
Йорт салырга монда урын юкмы?
Җыр язарга мөмкин түгелме?
Шул ук кояш чыга һәм яктырта
Юлларыңны синең, күңелне...
Башак тирбәтәләр шул ук кырлар,
Тирә-юньдә мотор гөжләве...
Тик ни гөжли алар, кем кулында?
Нигә безнең кулда гөжләми?
Егәрле бит безнең беләкләр дә,
Безнең башларда да акыл бар.
Мине шигъри хисләр ялгыштырса,
Кичерегез, зинһар, якташлар!
Ләкин бу кайтуым сәер булды,
Сәер тойгы белән моңланам:
Безне сагынудан кибеп ята
Туган якта безнең елгалар.

*1970*

## АВЫЛДАШКА ХАТ

Аэродром иде безнең урам:
Казлар күтәрелде каңгылдап.
Бүрәнәгә утырып сөйләштек бер:
Мин китәргә булдым авылдан.
Кайбер агайларга үпкәләдем, –
Булмагангадырмы әтиләр,
Безнең колакларны еш бордылар,
Авыр-авыр сүзләр әйттеләр.
Күнегергә теләү туды миндә,
Тик өстенлек алды чиркану.
Малай булсаң да бит, горурлык бар,
Тамырларда барыбер ир каны.
Шуңа түгелмени авыл эшен
Бик тиз генә алдык өйрәнеп?!
Йөгәненнән тотып зур атларны
Кырмыскалар кебек сөйрәдек.
Бүген сезнең кулда машинадыр,
Исәннәрме теге агайлар?
Безне шактый кимсеттегез, диеп,
Син бәрелмә инде аларга.

Калса калган икән безнең хәтер,
Аларның да хәтере калмасын...
Әй, ташлыйк ла моны, ничек хәзер
Кәрим бабайларның алмасы?
Клуб ничек? Яшь-җилкенчәк кызлар
Сибәләрме «Ярмәк» көенә?
Безнең буын ничек? «Абый» булгач,
Онытып бетермиме биюне?
Самолетлар төсле күтәрелеп,
Очалармы казлар каңгылдап?
Кашка бия күптән үлдеме соң?
Ә малайлар ничек авылда?
Әтиләре бармы барсының да?
Әтисез булса, син тагы
Берүк авыр сүзләр әйтә күрмә,
Бора күрмә аның колагын!

*1963*

## ГӨЛ КҮЗЛӘРЕ МӨЛДЕРӘМӘ

*Фасил Әхмәткә*

Уйнадың да, тулды моңнар,
тулды күңелләремә.
Күңелемне күмде гөлләр,
нур иңде гөлләремә.
Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?
Көйләреңне каян алдың,
нинди тылсым беләсең?
Сандугачлар мәктәбендә
укыдыңмы әллә син?
Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?
Моңнарыңда җиргә кайта
җирдән киткән әнкәем.
Ак чыбылдык эчләрендә
алмалы бишеккәем...
Гөл күзләре мөлдерәмә,
ник чылана таң нуры?
Әллә кояшлы кайгым бу,
әллә шатлык яңгыры?

*1994*

## ТУМЫЙ КАЛГАН БАЛАГА

*(Багышлау)*

Бәхетлеләр – синең хәлдә,
синең хәлдә мин түгел.
...Гасырларның карынында
син барлыкны сизәм гел.
Без бу якта – дөньялыкта,
күргәнең юк син аны.
Килмә, бала!

Кагыла күрмә
капкасына дөньяның!
Аны кагып мин ялгыштым,
хаталандым да кереп...
Үкендем әй, көлә-көлә,
әй үкендем – үкереп...
Минем кебек монда һәркем
ялгыша да юана...
Монда без дә,
дөньябыз да –
бөтенебез дивана.
Кемдер яга, кемдер яна,
яна дөньям, гөлләрем.
Өзелеп берәү бала көтә,
берәү буа килгәнен...
Безнең уен – ут эчендә,
тәкъдир шулай, күрәсең.
Түрәләрнең түре яна,
түбәннәрнең – түбәсе...
...Диваналар уенында –
диваналар үлеме:
элмәк-элмәк көннәр монда
муеннарга эленә.
Ачма дөнья капкасын!
Күзләреңә ут кабыныр,
куркыныч якты монда.
Качып кал син
гел караңгы
гасырлар карынында.

*1992*

## ГЕЛ ШУЛАЙ ГЫНА ТОЕЛДЫ

Чатнагач,
Тормыш
Ярылыр,
Ярылыр төсле тоелды,
Гел шулай гына тоелды, –
Ярылыр кебек бер!
Ак белән бәйләп карадык,
Ал белән бәйләп карадык,
Тасмалар сайлап карадык, –
Таралыр кебек бер!
Балдаклап
Саклап
Карадык.
Кечкенә генә кыз бала
Аны кочаклап карады, –
Булмады, –
Ярылды тормыш,
Ярылды барыбер.
...Һәр яртысы ике якка
Юл алды аларның –
Яңгыр юар,
Карлар күмәр,
Күмәр
Яраларын...

*1974*

## БАЛА ЭЗЕ

Үзен күптән күргәнем юк,
Күзләремдә – бала эзе,
Йөрәгемдә – яңа эзе,
Өйдә үзем генә.
Өйдән чыксам,
Урамда да
Эзләр генә,
Барысы да
Бала эзе генә.
...Ничек матур батып барган
Кыр өстеннән бала эзе, –
Аның эзе кебек.
...Җәйгә керсәм, ком өстендә
Тезелеп калган бала эзе –
Аның эзе кебек.
Юл буеның туфрагыннан
Озак барган,
Бала барган,
Биш бармагы кала барган...
Яланаяк кая барган?
Аның эзе микән?..
Аны куып җитәрменме,
Шушы эздән китсәм?
Һәм нишләрмен, ни әйтермен,
Әгәр куып җитсәм?!

*1974*

## ТУГАН ЯК ЕЛГАСЫН ХӘТЕРЛӘҮ

Исә дә җил,
камышларың сөрлегә.
Туган якта
җем-җем аккан
бергенәм!
Тамчы күрсәм дә,
төшәсең исемә.
Диңгез күрсәм дә,
киләсең уема.
Иң яшел дә
иң йомшак яр –
синең яр.
Җирнең иң ак казы
синдә коена.

*1994*

## ТАУ АСТЫНДА ГАДИ СУ

Күк ул тиңсез,
Касады-су –
тау астында гади су.
Исән бул, йөзем юган су,
мин дә юлга чыгасы.
...Туган су,
сау бул, йөзем юган су.
Алым кала,

гөлем кала,
алып булмый шул инде.
Җитсә китәр вакытларың,
калып булмый шул инде.
...Туган су,
сау бул, йөзем юган су.
Күк ул тиңсез,
галәм чиксез,
анда йолдыз адашкан.
Адашкан йолдызлар хәле
тигән безнең язмышка.
...Туган су,
сау бул, йөзем юган су.
Касады-су, әй, туган су,
сау бул, йөзем юган су.

*1984*

## СИНЕҢ БАЗАР

*(Милләтен сатучыга)*

Авыр туфрак телим сиңа, атың корсын,
ата-анаң рухы шуны сизеп торсын:
син яхшырак киенер өчен – халкың саттың,
кәеф-сафа сөрер өчен – халкың саттың.
Халкың саттың – әйбәт эшкә керер өчен,
халкың саттың – түш киереп йөрер өчен.
Дәү дәрәҗә алу өчен – халкың саттың,
гел базарда калу өчен– халкың саттың.
Үтеп бара гомерең шулай сата-ала,
милләт кала – хәтереңдә исемең кала:
исемең кара, йөзең кара, кара бәгырь!
Исле җисемең каршысында –
кара кабер.
Авыр туфрак телим сиңа, атың корсын –
әби-бабаң рухы шуны сизеп торсын!

*1992*

## ШАТ БАЛА...

Син дә бик шат,
мин дә бик шат,
ул шатлана, бу шатлана.
Бар микән соң дөньясында
безнең дә кебек шат бала?
Дөньяны йөреп чыкмаган –
илендә йөреп шатлана.
Илен дә йөреп чыкмаган –
өендә йөреп шатлана...
...Ботка юкта – ботын чабып,
өйрә чөмереп шатлана...
Юктыр ла ул бу дөньяда
безнең дә кебек шат бала.

*1972*

## ИКЕ ТАКТА – БЕР БАСМА

*Язучы Ркаил Зәйдуллага*

Син, энем, затлы фикерләр
уйлап йөрисең, беләм.
Аларны язып халыкка
бирмә келисең, беләм.
Мин дә күп уйлап уелдым,
язып та карый идем.
–Алыгыз, ал! – дип, татарга
үрелеп арый идем.
Алар мине ишетми дә,
күрми дә сыман юри.
...Яннарында сәер янгын
үзләрен ялмап йөри.
Беттеләр болар дигәндә –
калганнары табыла:
сөннәтлесе, сөннәтсезе –
үз сөягең танылa!
Ул ат булган җирдә булыр,
себерке торган җирдә.
...Товар сата-ала белер,
эчә белер хәмер дә.
Сүгенүе нәзек чыгар,
кысылыбрак, тоныграк.
Йә гөрләгән тавышы да
нечкәреп алыр кайчак.
Ул әйбәт «господин» булыр,
иң әйбәт «холоп» булыр.
Ана телен яхшы белмәс,
шул безнең халык булыр.
Ясканма әллә ни затлы
шигырь бирәм дип аңа.
Андыйны кабул итми ул,
аңа кирәкми яңа.
Аңлашырлык иске булсын,
хатыннар төсле булсын.
Ал ягы текә булсын да,
арт шәриф көчле булсын.
Яз, энем, минемчәрәк син,
йә Ризван Хәмид кебек.
Гәрәй Рәхим киңәшләрен
тыңлап кара бер кереп.
Әйткән сүзен Батулланың
ишеткәнең бардыр, шәт:
ике такта– бер басма, ди,
уртасында мәхәббәт!
Шуны язып, әллә кемнәр
язучы булып җитте.
– Милләткә аннан ни файда? –
дисеңме?
Сорау җитди!
Без барыбер языйк, энем,
каләм бит ул бездә бар.
Ашап дуңгыз да булалар,
укып дуңгыз булмаслар.

*1989*

## БЕЗНЕҢ ГЕРОЙ

Безнең Герой өченче көн

аракыга карамый:
– Бер күренсен
ирлек, мәгънә.
Хатынга йөзенче вәгъдә,
юк, бозарга ярамый.
Керсә керер ресторанга,
чыдар,
барыбер чыдар.
Үрелеп кайнар үрдәккә,
көйрәп яшәгән йөрәккә
лимонад сибеп чыгар.
...Таныш өстәл,
ак халатлар,
ыгы-зыгы, тәмле ис.
Түзә Герой, түзә ич!
Күрше өстәлдә –
шампанский, шайтанский,
ах, бөкесе –
шалт итте дә
сикерде:
өч көн җыйган түземлекне
чәлпәрәмә китерде.

*1967*

## ИЛЛӘ МӘГӘР...

Башың җитмәсә – уйлама,
башың җитсә – уйла.
Көчең җитмәсә – уйнама,
көчең җитсә – уйна.
Оялыр булсаң – күренмә,
оялмасаң – күрен.
Буең җитмәсә – үрелмә,
буең җитсә – үрел.
...Уйламасаң,
уйнамасаң,
үрелмәсәң әгәр –
гел дөньяга күренмәвең
шәптер иллә мәгәр.

*1971*

## БУЛМА

Малай булсаң,
Бул син әйдә,
Малай бул син, –
Куркак булма.
Шагыйрь булсаң,
Ике төрле
Фәлсәфәгә
Уртак булма.
Тормышыңда
Малай булып
Кал син калсаң, –
Бабай булма.
Шигырьләрдә
Бабай булсаң,
Бул син әйдә, –

Малай булма.

*1970*

## БУ ЕЛЛАРДА...

*Үземә*

Без актарган таулар артта калды,
таш күтәрер көчем калмады.
Хәзер көчем– сирәк бәйрәмнәрдә
йөз грамм да ярты алмалык.
Узды китте яшьлек сәер чорда,
сәерләтеп узды җанымны.
– Яшь кызлар! – дип
өзелеп ялганмадым,
гел ханымнар күзгә чалынды.
Уйлап шуны хәзер елмаям да,
сызланам да кайчак утырып.
Мин гомерне тормыш учагына
яктым бугай артык тутырып.
Күралмадым татлы малай-йокы,
саташулы булды төннәрем.
Төшкә керде күрше матур апа,
мин иреннән аны көнләдем.
Егет булган мәлдән көннәрем дә
саташулы төшкә әверелде.
Муеннан ук иде яшьтәшләрем,
яшем җитмәсләргә үрелдем.
Әти булгач – кемгә бәхет бирдем,
үзем йөрдем дөрләп-куанып!
Бүгенгәчә янып бетмәгәнгә –
мин тилегә һәйкәл куярлык.
Көләр идем карап– һәйкәле юк,
һәм күңелдә нәни бер шом бар.
Бу елларда нык картайдым, ахры,
гел чалына күзгә яшь кызлар.

*1999*

## СҮЗЛӘРЕҢ ГЕЛ ИСТӘ ТОРДЫ

*Актаныштан Яңа Кормаш кызы*
*Илүсәр Вәлиевага*

Ну начар да язгансың, дип
әйтүчем дә син булдың.
Моны язма– янарсың, дип
әйтүчем дә син булдың.
Бер җилкәмдә ике баш та
түгел иде югыйсә.
Бар язганым – җан һәм кеше,
күңел иде югыйсә...
...Язылды шул –
бер башлагач,
хут белән дә уйналды.
Хут белән уйнаган шәйгә
ут белән дә уйналды.
Сүзләрең гел истә торды,
шулай да азгаладым:

шигырьдән җәяү качканнар
өчен дә язгаладым.

*2001*

## ТОРМЫШ ЧАБА

Уята,
йоклатмый вакыт –
җилтерәтеп йөртә.
Аңа нәрсә
синең төнең,
көнең, кичең-иртәң?!
Аңа нәрсә кем булуың,
син хатынмы, ирме?!
Якасыннан ала вакыт
Ил кадәрле Илнең!
Кайчакта буып тота да,
күзеңә кан тула.
Тота вакыт –
һәйкәл үлә...
...Сандугачлар буыла,
тота вакыт,
төртә вакыт –
бар да алга йөгерә.
Егылып йөзең ватарсың,
мин көчкә өлгерәм.
Һәм менә елмаям әле –
җәяү йөри алам!
Машина да очрап тора,
очып-очынып утырам –
алтмыш яшьлек бала.
...Тигезлекләр,
аннан таулар –
тау өстендә йортлар.
Юлларны таулар күтәрә,
һәм чокырлар йота.
Борылышлар,
кырын юллар –
машинаң әйләнер.
Кемдер:
– Әйләнсә әйләнер,
яшәп калыйк, – ди, – бер!
Әйләнмәсен иде, шофер,
каула
сизеп чамаң!
...Шулай синең,
минем тормыш,
бөтен тормыш чаба.

*1991–1997*

## УТ КЕБЕК ДУСЛАР

«Рәхәт яшә, тыныч яшә,
моңа шартың бар», – дисең.
«Сиңа нәрсә, янәшәңдә
ут кебек дуслар!» – дисең.
Син белеп сөйлисең дә бит
һәм бераз белмисең дә.

Ут дигәннән, минем менә
шундый бер хәл исемдә.
Чаңгылы бала чагымда
урманда йөргән идем.
Ул көнне урман карауччы
агайга кергән идем.
Зур өендә олы миче –
әй яна иде тулып...
Дөрли уты әллә ничек,
куркыныч матур булып.
Икенче көн кергән идем,
мич һаман яна тулып.
...Ә бер килсәм– яна өе,
нәкъ миче кебек булып...
Син әйтәсең: «Янәшәңдә
ут кебек дуслар! – дисең, –
рәхәт яшә, тыныч яшә,
моңа шартың бар!» – дисең.

*1985*

## ТОМАННАРГА ТАБА ИЛТТЕЛӘР

Сары бодай кыры җилдә кайный,
әйләнәсе тимер сак иде...
Үҗәтләнеп безнең үсеп йөргән,
гел ашыйсы килгән чак иде.
Бирмәделәр ипи туган якта,
читтә бәхет вәгъдә иттеләр.
Төяп-төяп безне поездларга,
томаннарга таба илттеләр.
Безне суга сипте пароходлар,
машиналар җиргә таратты.
Кемдер сугып тешне
койды безнең,
кемдер каршылады яратып...
Әверелдек моңлы килмешәккә,
чын йөрәктән җырлар чыгардык.
Җырыбызга тыгылып үләр чакта,
туган якны уйлап чыдадык.
Табалмадык читтә бәхет димим,
бөтенләй үк буш кул кайтмадык.
Туган якка кайткач, күпләребез
әнкәйләрне генә тапмадык.
Инде безнең күңел
шул вакыттан
мәңгелеккә хәтле өшегән...
Киләчәкнең тимер түрәләре
ни күрсәтер тагын кешегә?!

*1991*

## АК БОЛЫТЛАР ҮТТЕ

Еш сөйләшәм быел күккә карап,
үзем генә калгач, бергә-бер.
Әткәм, бабам, аның бабасы да
бу күк йөзен шулай күргәндер.
Күпме үтте, ак болытлар үтте –
еллар битен сыйпап, иркәләп.

...Гомер иттем,
җиңдем,
канатландым,
бәйрәм, җырлар –
истә... истәләр...
Әрнеп-әрнеп елаганым да бар,
чынлап елау булмый онытырлык.
Җан телендә, ачык яраларда
тоз таулары эреп утырды.
Көлгән чагым булды үз хәлемнән,
яралану, әрнү, елаудан,
мәхәббәттән,
табу, югалтудан,
гомер, тарих,
уйдан,
юллардан.
Мин көлмим дә быел, еламыйм да,
кайдан килде бу ел, ник килде?
Еласам –
мине һичкем
юаталмас,
Көлсәм – туктап булмас шикелле.

*1980–1997*

## ВОЕНКОМАТТА

Нигә
бу егетләрне
үлчәп маташасыз
салкын, җансыз үлчәгечләр белән?
Алар,
этиләре сугышка киткәндә,
кайнар беләктә калдылар.
Төгәл авырлыкларын
бары әниләре белә.
Алар
иң биек агач очыннан
чикләвек өзделәр,
иң биек тау түбәсеннән
чия таптылар,
иң биек атны
йөгәнләделәр,
кул арасына керү белән.
Аларның төгәл буйларын
бары әниләре белә.
Булышмагыз,
хезмәткә яраклы дип язгыгыз,
үлчәмичә генә.

*1960*

## БАРДЫР

Бардыр чын йөзе тормышның,
Тик мин аны күрмәдем.
Аның йөзе минем алда
Һаман торды үзгәреп.
Һаман миңа күрсәтте ул
Битлекле йөзен генә.

Шулай да яхшы бүгенге
Тормышым йөзе менә.
Бәлки, калган гомеремне
Шушында үтәрмендер.
Барыбер, артыма карап,
Сагынмам үткәнемне.
Сагынмам бала чагымны,
Югалтып әтиләрне,
Сугыштан үлем хәбәре
Кайтаручы җилләрне.
Җилне бүлеп, әкият сөйләп
Юатты әнкәй безне –
Әкиятне үзенә йотып
Күренде тормыш йөзе.
Күренде: вакыт– Газраил,
Һәм кояш тәмуг иде;
Ә җир ясалып бетәргә
Торучы табут иде...
Бардыр чын йөзе тормышның –
Мин күргәннән үзгәсе.
Бүгенге йөзе – ярыйсы, –
Шул яхшыга үзгәрсен.

*1967*

## САБЫЙЛАР КӨЛӘ

Сабыйлар көлә.
Сабыйлар – кечкенәләр.
Сабыйлар белмиләр,
Ә без –
Ата кешеләр –
Олылар, фикерлеләр, көчлеләр –
Шактый гына яшәдек.
Өлгерә алмасак та
Туй ясарга
Бер өстәлдә
Бөтен милләт бергә –
Өлгердек танышырга,
Өйрәндек сөйләшергә.
Сабыйлар көләләр.
Сабыйлар – кечкенәләр
Белмиләр.
Безнең сүз
Мөһим мәсьәлә турында:
«Җир шары
Ничегрәк калыр
Алар кулында,
Чишелеп барлык серләре,
Артып акыл гөлләре,
Галәм йөрәге була алырмы?
Әллә
Тарткаланып,
Теткәләнеп,
Янып,
Җәһәннәм булып калырмы?»
Сабыйлар белми –
Алар – кечкенәләр.
Минем өметләр шикелле ап-ак
Тешләрен күрсәтеп

Көләләр.

*1967*

## КҮПМЕ ИЛЛӘР...

Җирне күккә менгерербез –
Шундый эшкә җай табарбыз.
Күрелмәгән көчлеләр без,
Күрелмәгән осталар без,
Ләкин һаман кешеләр без, –
Беребез дә диңгез булмас.
Яшьләр безне алыштырыр –
Беребез дә тиңсез булмас;
Пулялар кебек вакланып,
Усалланмыйк пуля кебек.
Яшик әле шат йөз белән
Һәм сөйләшик уйнап-көлеп...
Яшик әле сокланышып,
Сокланырга күпме төс бар:
Күпме илләр, төрле милләт –
Нинди келәм, матур, чуар!
Түм-түгәрәк Җир шарыбыз
Чәчәк тулы болын кебек, –
Бер чәчәген югалтсак та,
Зур хатабыз булыр кебек.
Күрелмәгән көчлеләр без,
Күрелмәгән акыллылар.
Әгәр инде ният итсәк,
Бездән әллә ниләр чыгар:
Күкне аска төшерербез,
Җирне өскә менгерербез, –
Барыбер кемдер ай булмас,
Кояш булмас һичберебез.

*1973*

## КҮҢЕЛЕМДӘ МЕНӘ ШУНДЫЙ ШАТЛЫК БАР

Яхшы гына беләм мин үз телемне,
Дуслар белән сөйләшәм дус телендә;
Хөрмәт итә белгәч инде үз телем,
Хөрмәт итә белермен мин дус телен –
Күңелемдә менә шундый шатлык бар.
Юк, элемтә җебе генә түгел тел,
Тел йөзең ул, тел бабаң ул, тел – нәсел;
Хөрмәт итә белгәч мин үз нәселем,
Хөрмәт итә белермен дус нәселен –
Күңелемдә менә шундый шатлык бар.
Ирләр алар дуслаша да ил була,
Ир ни телдә сөйләсә дә ир була;
«Ир эчендә иярле ат бар», – диләр, –
Ул ат минем сезгә бирер хәзинәм –
Күңелемдә менә шундый шатлык бар.

*1967*

## КАЙВАКЫТТА

Кайвакытта үз-үземне мактыйм мин:

Ап-аз яшәп, күпме нәрсә таптым, дим.
Тапканым да хәрам йә ялган түгел –
Мин югалту хисабына таптым гел.
Мактанырлык тапканың ни дисезме?
И дусларым, шуны да күрмисезме:
Күпме җиргә күз нурларым чәчелде,
Дөнья уе сирәгәйтте чәчемне...
Кимеп калды йөземдәге алсулык, –
Элек булган көлү инде миндә юк.
Җитдилегем арта бара бермә-бер,
Көтмәгәндә әллә нишли йөрәгем.
Ташкын кебек гөрләп килгән елларым
Артта кала моңсу гүләү чыгарып.
Минем күңел бераз нечкә күңел бу,
Тик белегез, зарлануым түгел бу.
Бу югалту минем өчен чүп әле,
Югалтканнан югалтасым күп әле...
Бер үземне югалтырмын, шунда сез
Минем нәрсә тапканымны күрерсез.

*1970*

## ШИГЫРЬ ДӘФТӘРЕМНЕ АКТАРСАГЫЗ

Әгәр
Сандугач
Кеше хәреф белмәгән чорда
Халык җырларыннан яралган булса,
Ярый әле
Мин аның
Матур тавышыннан гына ләззәт алам. –
Телен төшенсәм,
Ачы хәсрәт турында җырлаган чагын күрсәм,
Борчуларым артыр иде –
Җирнең күпме матурлыгын югалтыр идем.
Әгәр моннан күп еллар элек
Кызыл чәчәкләр –
Кызларның
Оялып елмаюларыннан,
Ак чәчәкләр –
Аналарның сөенеп елмаюларыннан,
Зәңгәр чәчәкләр
Ерактагы юлчыларның
Туган якларын күзаллап елмаюларыннан
Яралган булсалар,
Ярый әле
Ясалма, ялган елмаюдан
Яки
Кешене мыскыллап елмаюдан,
Яки кайгырып,
Акылдан шашкан кешеләр елмаюыннан
Яралган чәчәкләрне танымыйм –
Җирнең күпме матурлыгын югалтыр идем.
Очрак чыгып,
Шигырь дәфтәремне актарсагыз,
Аннан...
Бервакытта да...
«Минем хыялларның хәрабәләре»
Дигән шигырь эзләмәгез.

*1967*

## ҖИНАЯТЬ

Мин гаҗәп төн булыр идем
бер генә тапкыр.
Кешелекне
үзем аша
уздырыр идем
бер генә тапкыр.
...Бер генә тапкыр.
Ләкин шушы гаҗәп төннән
чыгармас идем
бозык уйлы кешеләрнең
берсен дә, –
таңның ал капкасы аша
яңа якты көнгә
керерләр иде
чиста уйлы кешеләр генә...
Керерләр...
Ни булганны әле аңламый торырлар,
сөйләрләр:
– Җинаять! – диярләр.
Яннарында туганнарын
тапмаслар берәүләр:
– Җинаять! – диярләр.
Берәүләрнең күренмәс якыннары,
танышлары.
Күренмәс иде бу көнне
минем дә кайбер дусларым.
...Һәм бу көнне
күренмәс идем мин үзем дә, –
шушы «җинаятем» өчен
калыр идем
узган гаҗәп төндә.

*1970*

## ОЧРАШУ

*(Ленинград дәфтәреннән)*

Ленинград,
Мине гафу ит,
Болай түгел идем,
Әллә нишләдем –
Кинәт тынычлыгымны,
Бүгенге көнемне
    үзем югалттым әле.
Канымда – тревога,
Йөрәгем – блокадада,
Күзләрем
42 нче елгы күгеңә әйләнде.
...Хәзер, хәзер
Соңгы дошман самолеты
Качып китәр күзләремнән...
Соңгы бомба
    юкка чыгар
        фикеремдә ярылып.
Һәм мин, Ленинград,
Синең бүгенеңә охшап,
    сау-сәламәт,

көләч калырмын.

*1965*

## ЛЕНИНГРАДКА

Зурлыгың
бөтен дөньяга күренә,
Бар дөньяга таныш көчең;
Соборларың түбәсенә менәм әле
Кечкенәлегемне күрер өчен.
Йөрим әле,
Бөек кешеләрнең эшләрен,
бөекләрнең һәйкәлләрен
карыйм әле ныклап;
Кечерәйим тагын мең тапкыр –
Бөтенләй юкка чыкмам.
Күпме калсам –
Шул булырмын мин,
Шунда булыр
Әнкәм сөтеннән алган ак җырым,
Әткәмчә елмаю, сөйләшү, ярсу да;
Шунда булыр
Халкыма кирәкнең
Барсы да,
Барсы да.

## ТӨН ДИСЕЗДЕР

*(Ленинградтагы таныш кызларга)*

Аңламассыз мине йөздән: кайгылымы, гашыйкмы мин?
Ашыкмыйм мин еларга да, көләргә дә ашыкмыйм мин.
Мине дөнья салкын-салмак уйларына әсир иткән.
Шуңа миңа бер кара кыз – Казан кызы әйтте күптән:
«Егет түгел, син – төн! – диде. – Янәшәңдә бару читен!»
Утыз яшькә ялгыз җитәм, мин һаман шул, мин һаман төн.
Сез дә һаман шул икән бит – безнең Казан кызларыдай
Әзер тыйнак елмаерга һәм аз гына кызарырга.
Кулларыгыз гөлләр тота, каләм тота кирәк булса.
Кулыгызда таш ватыла, нишләр анда йөрәк булса?
Дөнья сезгә көчне биргән, сезнең нечкә керфекләр дә
Өзелмәслек җепләр булып үреләләр егетләргә.
Очрашканда исәнләшеп янгыгызда туктавыма
Елмаясыз – кабынасыз төнге Казан утларыдай.
Ә мин менә, кызлар күңеле ни көткәнне белмәгәндәй,
Онытам бит иңегезгә бер шаян сүз әләргә дә;
Сизмәгәндәй ике күзнең калганлыгын миңа карап,
Ничек сезгә очрап калсам, шулай капыл китеп барам.
«Егет түгел, төн!» – дисездер, төшенәм, кызлар, үзем дә.
Тик белегез: бер чаткы да читтә калмый төн күзеннән.

## КҮПЕРЛӘР

*(Бүген соңгы тапкыр Ленинград күперләрен карап йөрдем. Иртәгә китәм.)*

Күперләр, күперләр!
Шагыйрьләр эшенә күпмедер охшаш сез.
Алга ыргылган ниндидер тормышның

Агышын сыйдырасыз.
Ниндидер заманның
Басымын күтәреп торасыз...
Торасыз...
Аннан тузасыз...
...Тузганны онытырга,
җимереп ташларга,
яңаны салырга мөмкин.

Үзем дә
Бер күпер салырга уйлыйм мин,
Туздырып та,
Җимереп тә булмый торган бер күпер,
Матур, зур күпер.
Һәм, беләмен,
Ярны ярга түгел,
Утрауны утрауга түгел,
Бүгенгене киләчәккә
тоташтырыр ул күпер.
...Тик менә...
Нәрсәләр аша узар ул?
Нәрсәләр күтәрер?

## ЙӨЗ ЕЛДАН СОҢ ТУАР ТУГАННАРГА

Сез Ленинградны укыгыз,
Бездән хат көтмәгез,
Язмабыз без.
Гомумән,
күп нәрсәләрне
язып бетереп булмый хатка.
Ә бу шәһәр –
Ачык итеп язылган,
Җирнең күкрәгенә язылган,
Ленин хакында,
коммунизм хакында,
безнең хакта.

## ҖИҢҮЧЕ ЧӘЧӘК

Каян килә икән талау рухы,
Алдау рухы килә кайлардан?!
Буып, талап, суеп байый берәү,
Икенчесе талый аңардан...
Яңа сүздә, күздә – баю уты,
Тирә-юньгә янап, пешереп...
Җыелып, өелеп, сүгенеп сугыша да
Сибелеп җирне талый кешелек.
Бөек максат булып талау калды,
Маяк булды – баеп танылу:
Нинди Алла уйлап чыгардык та,
Бу соң әле нинди табыну? –
Мондый юлга ничек кердек икән,
чыгу юлын инде белмибез...
–Тиздән Җир дә бетә,
кешеләр дә...
Бергә бетә, – диеп йөрибез.
...Кешелекне кеше бетерер дә,
Җир җилләнеп калыр төслерәк:

һәм
жиңүче булып
чәчәк чыгар
безнең уртак кабер өстенә.

*1991*

## КЕШЕЛЕК БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Сугыш
Дан бирә.
Яхшы дан булырга мөмкин ул,
Мөмкин ул яман дан булырга.
Сугыш
Дан бирә...
Кешеләр!
Сугышны без аны
Үзебез тудырдык,
Үзебез үстердек,
Үзебез ашаттык –
Туймады...
Бабайларны без аңа ашаттык,
Әтиләрне без аңа ашаттык –
Туймады...
Әниләрне, сабыйларны
Ашаттык –
Туймады...
Мал биреп,
Дан алдык,
Җан биреп,
Дан алдык –
Туймады...
Бирсәк,
Безне дә алыр ул,
Ашар ул барын да.
Аннан...
Баласыз бишек төсле дан
Әйләнеп калыр Кояш янында.
Әйләнеп
таралыр, югалыр
Кояш янында.

*1969*

## БӘХЕТЕМ

Көндез кояш йөзә бәхетем булып,
Бәхетем булып төнлә ай чыга...
Язгы сулар ташый бәхетем булып,
Бәхетем булып гөлләр ачыла.
Болыт булып йөри минем бәхетем,
Яшен булып кисә һаваны...
Минем бәхет – хәтәр-хәвефләрдә
Юкка чыккан ирләр дәвамы.
Яшем арткан саен арта барып,
Зурайды шул бәхетем бик күпкә;
Бар кешенең бәхете, бәлкем, җирдә
Тиң түгелдер минем бәхеткә.
Һич бетәрлек түгел минем бәхетем,
Минем бәхетем җиргә килүемдә,
Минем бәхетем бөтен бәхетсезне,

Бөтен бәхетлене сөюемдә.

*1971*

## МИҢА АКЫЛ ГЕЛ СОҢЛАБРАК КИЛГӘН

Миңа акыл
Гел соңлабрак килгән.
Узганыма карасам,
Төен-төен тырпаешып
Хаталарым тезелгән.
«Ташкент – город хлебный!» дип кычкыру
Яңгырап модага кергән бер чорда
Мин ут-малай туган яктан ычкындым.
«Ташкент – город хлебный!»га
Барып чумдым.
Һәм адашып анда шактый йөрелде,
Шул арада ут-малайлык сүрелде.
И ашкындым кабат кайтып китәргә,
Көн дә әйтәм «иртәгә» дим, «иртәгә»,
Ах, «иртәгә», иртәгә дә «иртәгә»!
«Иртәгә» ул
Әллә бар да, әллә юк.
Тик без аңа ябышканбыз
Шактый нык.
Әйтмим лә бүген, иртәгә әйтәм,
Бүген түгел, иртәгә болай итәм.
Әй,
Бүген түгел, иртәгә китәм.
Иртәгә барам, иртәгә күрәм.
Җитте бүгенгә,
Бу эшне иртәгә бетерәм.
Күптән барам,
Барам шулай
Үз-үземне юатып.
Ә каршыма
Авыз ерып киләләр.
Соңлаган акылым да
Үләр вакыт
Соңгарып килгән акыл –
Гамәлдән чыккан акча сыман.
Ул бары узганыңда
Юкка актарыну
Һәм аптырау икән.
Ә яшәү фәкать «бүген!»
«Бүген» һәм «бүген» нәрдән генә
Тора икән.

*2004*

## БУ КӨН МИҢА ШУНДЫЙ ТЫНЫЧ КИЛДЕ

*(Миңа алтмыш җиде яшь тулган көн)*

Бу көн миңа шундый тыныч килде,
Артык тыныч – хәтта куркыныч.
Ярый хатын сукрангалап йөри,
Юкса хет өеңнән чыгып кач.
Бу көн миңа шундый тыныч килде,
Телефоным таңнан оран сала,
Никтер мин ишетмим шикелле.
Әйтерсең лә мин үлгәнмен инде

Моннан алтмыш җиде ел элек.
Үзе булмаганның күзе дә юк,
Дуслары да югы билгеле.
Тик күңелгә һаман нидер җитми,
Тик күңелгә бүген хет юри
Ишегемә кагылып узар кебек
Шагыйрь Гөргөри.
«Юри» сүзен ялгыш әйттем әле,
Гәрәй юри йөри ул рәҗе?
Кинәт телефоным телгә килде:
Азнакайдан Илдус Гыйләҗев.
«Шактый озын язды, төп фикере
Ни моның?» дип хафаланмагыз,
Анысын да әйтеп салабыз:
«Бер-беребезгә шундый охшаганбыз,
Барыбыз да әйбәт без, дуслар!
Начар булмас иде арабызда
Күбрәк булса әгәр Илдуслар».

*2004*

## КЕШЕЛЕК ӨЛГЕРГӘН ЧАКТА...

Бодай кыры – бодай иле,
Нинди иркен, нинди сары!
Үзгәртте шул, эре итте
Тормыш аның башакларын;
Кургаш кебек авыр итте –
Тотып кара син кулыңа?
Ярый әле башакларда
Бодай гына, бодай гына.
Әллә ни ясар бу тормыш,
Баксаң, әле малай гына.
Үзе таза, хыялы зур:
Кулы озын, аягы да...
Җитешмәгән урыны юк,
Йолдызларга барып менә.
Ялгыш кына нидер ватар,
Нидер кояр кебек менә.
Бәлки, шөбһәм гел юккадыр,
Бар да булыр уңай гына...
Кургаш түгел башакларда,
Бодай гына, бодай гына.
Мин үзем дә бодай чәчкән,
Бодай урган кеше булам.
Әйтерсең мин ялгыш кына
Кулга төшкән кыргый болан.
Ычкынам да шәһәрләрдән,
Урманнарга таба чабам.
Аланнарга,
Бодай үскән мәйданнарга
Чәчрәп чыгам.
Уңган бодай...
Уракка да
Төшәр вакыт җитә бугай.
Мин соң бүген бу басуда
Ник борчылам әле болай.
Кайлардадыр бомба яуган,
Кырлар янган чак булса да,
Газеталар, үзәк өзеп,

Хәтәр хәбәр кычкырса да,
Яшәү дигән бөек куәт
Югарыга үрли әле, –
Безнең гомер, исән җырлар,
Исән кырлар моңа дәлил.
Әле тормыш малай гына,
Ни эшләмәс, кая бармас?!
Үзе болай зирәк күренә –
Каш ясыйм дип күз чыгармас...
Кешелек өлгергән чакта,
Юк, үлем төшмәс уракка;
Хәвефләрне кичеп юллар
Китәр әле бик еракка.
Бодай кыры– бодай иле –
Җиргә һаман шулай сарыр.
...Эре булыр, сары булыр,
Авыр булыр башаклары.

*1973*

## БОЗЛАР КИТӘ...

Яз, Иделне эретерлек итеп,
Күккә учак яга.
«Бозлар китә, бозлар китә!»– диеп
Йөгерә бала-чага.
«Бозлар китә, бозлар китә!»– диеп
Йөгерер идем мин дә, –
Мәңге китми торган
Бозлар бар шул
Күңелем Иделендә.

*1971*

## ҖИРГӘ БЕР СҮЗ

Кадер-хөрмәт күрсаталам диеп,
Кызыктырма минем күңелне.
Каберлекләр күрсаталам диеп,
Бозып торма минем күңелне.
Каберлекләр белән кадер-хөрмәт
Арасында эшем бар әле.
Кадер өчен мин кечкенә булсам,
Кабер минем өчен тар әле.
Ике аралыкта торасың дип,
Син көләргә миннән кыйма, Җир;
Әнкәм мине шушы төштә тапкан,
Син шушыннан миңа мәйдан бир.
Фикеремдәге шатлык
Монда юк та...
Фикеремдәге кайгы да
Юк монда,
Шушы төштә яшәп,
Шушы төшкә охшаш
Җырлар язый әле шушында.
Еллар бите ачылмаска ябыла,
Дәфтәр бите алай ук түгел.
Җилгә очырыр эшләр булса монда,
Җырга кертерлекләр юк түгел...
Берәр ана, бәлки,

Минем өчен
Кыз үстереп йөргәндер монда.
Яшим әле, шушы төшкә охшаш
Җырлар языйм әле шушында...
Аннан... чамаларсың,
Мин бер таш түгел ич,
Лаек тапсаң әгәр кадергә...
Мин кояш түгел ич, тик Кояшны
Күмеп куеп булмый кабергә.

*1965*

## ЯНУЛАРЫМ, КӨЮЛӘРЕМ...

Ашкынуым гел яктыга,
шуңа күрәдер инде
бүгенемнән иртәгемне
якты күрәмдер инде,
матур күрәмдер инде.
Һәр кеше дә киләчәген
матур күрәдер инде.
Сабыр җаннар сабыр бара,
мин йөгерәмдер инде,
ник йөгерәмдер инде?
Януларым, көюләрем
шуңа күрәдер инде...
Гел яктыга ашкынганнар
утка керәдер инде.

...Утка керәдер инде.

*1985*

## КИНӘТ

Әйтер сүзем «Ирек» иде –
«Читлек» килде кинәт искә.
...Әйе, теле аркасында
Попугай читлеккә төшкән.
Һәм кеше күптән читлектә,
Белми хәлен кеше генә:
Читлегенең зурлыгы тел,
Биге дә тел,
Ишеге дә.

*1980*

## СИГЕЗЕНЧЕ МАРТ УҢАЕ БЕЛӘН

Булды,
булды,
кара төннәрне
кара бала итеп иркәләде
ап-ак хатын-кызлар.
Күкрәгенә кысып төннәрне,
төннәргә кушылып елады
ап-ак хатын-кызлар.
...Кара хатын-кызлар,
алар да юата алмады төннәрне.
Ак көннәрне

ап-ак бала итеп яратып,
кулларында тирбәтеп,
ак көннәргә кушылып елады
кара хатын-кызлар.
...Сары хатын-кызлар,
алар да елады,
заман шулай булды,
тик барысы да
булмагандай уза.
Озын-озак гомер –
ул бер генә сәгать,
хәзер-хәзер,
ун гына минут,
бер генә минут –
һәм уза.
Җир яңара. Яңа – яңага!
Заман яңаларныкы!
Яңа ирләр…
Яңа хатын-кызлар…
Кара кызлар, кара гүзәлләр!
Сары кызлар, сары гүзәлләр!
Ап-ак гүзәлләр!
Ханымнар!
Еракта-еракта
бездән соң яшәүче
олгайган аналар, очкалак сеңелләр!
Сезнең төннәр еламасын инде,
еламасын иде сезнең төннәр.

*1981*

## БАРЫ ВАКЫТ-ВАКЫТ...

Йөгерсәм дә, узып булмас
кебек иде көннәр.
Кинәт шулар кыскарды бит,
кыскардылар төннәр.
Эшләгәнем нихәтледер? –
Күренми анысы да.
Эссе табада май сыман
сәгатьләрем сыза.
Сыза җегәр, җаным сыза
һәм – йөз алсулыгы.
Көйләп булмый, сабый эшем
елый сулгып-сулгып.
Ниһаять, булды дигәндә,
җебеп калам сыман.
Кышлар китек, язлар ярты –
мин алданам сыман.
Җәйләрнең дә тулы чагы,
бары вакыт-вакыт
кәккүк булып кычкыра,
хәтеремә кайтып.

*1977*

## ШИГЫРЬЛӘРЕМ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ

Ни дисез,
бездә горурлык,

бездә көч бар, дисезме?
Без сине кеше иттек, дип
әйтергә телисезме?
Киендердек, туендырдык,
дияргәме уегыз?
Соң, үзегез сез ни киеп,
ни белән туендыгыз?
Йөрәгемне өлеш-өлеш
сезгә бирмәдемме мин?
Ярсу җаным җылысына
сезне төрмәдемме мин?
Кабатланмас җәйләремне,
кояшлы көннәремне,
айлы төнем, сөйгәнемне
мин сезгә бирмәдемме?
Ни калды минем үземә,
ни калды, беләсезме?
Алыштык, дәрәҗә бирдек
һәм гомер, диярсезме?
Беләм мин гавам алдында
дәрәҗәм күпмелеген.
Беләм ачы дөреслекне –
исем гомер түгелен.
Булса миндә биргәнегез,
күпсенсәгез
алыгыз.
Ә Җиргә мин сезсез тудым,
сез минсез тумадыгыз.

*1968*

## БАЗАРДА

Егерменче гасыр иде, берзаман
шулай мин дә уздым сезнең базардан.
...Бүкән тора, түшкә тора бүкәндә,
ә исерек ит чабучы ит чаба.
Ызгышлар ник,
талашлар ник дөньяда?
Сугышлар ник,
бүлешләр ник дөньяда?
Ә исерек ит чабучы ит чаба...
Һәм ит ята охшап канлы дөньяга,
исерек, шат ит чабучы ит чаба.
Ит чабучы! Әй, үтим мин, чапмый тор!
Юкса минем башны уем яндырыр.

...Егерменче гасыр иде, берзаман
шулай мин дә уздым сезнең базардан.

*1975*

## АЧЛЫК ҖЫРЫ

Булган икән шундый кеше –
икмәк тәмен белгән кеше;
ятып ачлык түшәгендә,
үлгәннән терелгән кеше.
Җыр язып ул көй чыгарган
һәм чал башын иеп куйган.

Язганының иң өстенә
«Ачлык җыры» диеп куйган.
Бу җыр кемгә, ник кирәкми?
Кемгә, нигә бу җыр кирәк?
«Югалт аны!»
«Юк, югалтма!»
«Нишләтергә?»
«Тизрәк, тизрәк!»
Нәрсә язган?!
Ярый әле
дөньяга тәкъдим итмәгән?!
...Тик колагыннан үз җыры
китмәгән шул, аһ, китмәгән.

*1972*

## КЕШЕ ГОМЕРЕ

### 1

Немецлар җиңелә, дип
Сөйләнәләр олылар,
Тиздән әти кайта, дип
Сөенәләр балалар...
Һәм мин елмаеп кына
Өйгә кайтып керсәм кич –
Көтелмәгән күренеш...
Шундый чакта,
Кирәк ич!
Ниндидер кәгазь тотып,
Бөгәрләнеп утырып
Әнкәй елый,
　　бөтен өйгә
Күңелсезлек тутырып.
Кырыенда күрше апа,
Ул кайгыда нигәдер.
«Кеше гомерен вакытсыз
Кистеләр шул!» – дигәнен
Ишетеп калдым аның...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аннан
　　мин дә еладым...

### 2

Ә төнлә әнкәй миңа
Куеп ятты аркасын...
Ә ул мине кочаклап
Ята иде һәрвакыт...
Еласа, кайнар күз яше
Тия иде битемә...
Бүген бары туктаусыз
Сулкылдавы ишетелә.
Бүген бары туктаусыз
Калтырана аркасы.
Һаман күрше апаның
«Кеше гомерен вакытсыз
Кистеләр шул!» дигәне
Колактан китми әле...
Ярый әнкәйнең күз яше

Тими бүген битемә.
Нишләр идең бу төндә?

Төн бик күңелсез килде,
Төн –
Мәңгегә йомылган
Күзләр шикелле иде...

Тиздән сугыш бетәр, дип,
Әткәң кайтып җитәр, дип,
Күпме сөйләде әнкәй!
Хәзер...
Шундый язу килгәч...
Гомере вакытсыз киселгәч,
Кайтмас шул инде әткәй...

3

Йокыдан уянсам иртән,
Әнкәй күптән эшкә киткән.
Өстәлгә чүпрәк каплаган.
Астында бәрәңгедер.
Ашап буламы хәзер?!
Һаман әнкәйнең елавы,
Һаман күрше апаның
«Кеше гомерен вакытсыз
Кистеләр шул!» дигәне
Колактан китми әле...

Тәүге йөри башлагандай,
Атлап ишектән чыктым.
Йортта бөркү һәм тып-тын.
Йортта әллә нәрсә бар.
Читәннәргә эленгән
Пәрәвез оялары
Селкенергә куркалар.

Әллә нинди көн килде.
Көн авыздан өнсез чыккан
Кычкыру кебек иде...

Тиздән сугыш бетәр, дип,
Әткәң кайтып җитәр, дип,
Күпме сөйләде әнкәй.

Хәзер...
Шундый язу килгәч...
Гомере вакытсыз киселгәч,
Кайтмас шул инде әткәй...

4

Утынлыкта – сынык пычкы,
Нигездә – сынык көянтә...
Алар вакытсыз киселгән
Гомерне хәтерләтә...
Әрәмәдә күл күренә,
Ярым түгәрәк өсте...
Ул да вакытсыз киселгән
Кеше гомере төсле...

Онытырга теләп барсын,
Йомдым шунда күземне –
Минем уйда төн инде,
Уйга ярты ай килде.
Ай да вакытсыз киселгән
Кеше гомере шикелле.
Һаман кеше гомере! –
Кармак кебек уй булды,
Ә мин, балык шикелле,
Ычкынырга тырпылдыйм.
Качып китмәкче булам
Бу күңелсез уйлардан –
Йөгереп чыгам урамга...
...Әмма
Күккә карасам,
Кояш – кыңгырау теле,
Ә күк – гигант кыңгырау.
Кайдадыр бер кеше гомерен
Вакытсыз киссәләр бүген,
Күк чайкалырга тотыныр,
Офыктан офыкка кояш
Бәрелер. Бөтен галәм
Шалтырар төсле тора.

## ГОМЕР ТҮБӘСЕНӘ МЕНҮ

Түбәнгә тезеп калдырам
Яшәгән елларымны.
Бик арсам да, үҗәтләнеп
Менәм әле югары.
Узганым калды түбәндә,
Бик түбәндә калды инде –
Мин артык ашыгып мендем.
Менеп җитмәслек шикелле
Шактый биек күренә әле дә
Миңа гомерем түбәсе.
Әмма шул биек түбәгә
Һаман менәсе килә,
Шуңа менеп, түбән карап,
Бер төкерәсе килә...
Сәер халәт. Шунда башым
Миңа киңәшен бирә:
– Җитәрлек мендектер, абзый,
Әллә тукталабызмы?
Егылып очып түбәнгә,
Әллә ватылабызмы?..
Бу башым бераз әйләнеп,
Уйнап кына алуы.
– И кадерле тиле башым!
Шундый уен буламы?
Күбен менгәч,
Калган азын
Менеп җитәбез аның!

*2004*

## УЗГАНЫМ БЕЛӘН ЯШИМ

«Элеккечә яратам!» – дип
Юатма әле мине;
Бүгенемне уйландырып
Елатма әле мине.
Бүгенем белән түгел,
Хәзер мин
Узганым белән яшим.
Ярый әле узганымда
Шундый көннәрем булган –
Алар елмаюлар белән
Һәм бәхет белән тулган.
Шундый узганым барына
Куанып яшим хәзер.
Киләчәгем ни күрсәтер –
Мин барысына да әзер.

*2004*

* * *

Кайчак шулай күзләремне йомам.
Барлык мәшәкатем онытыла,
Уйлап торам...
Дөнья тына...
Тыныч хисемдә,
Йомык күзләрем эчендә
Яналар җемелдәп
Мин күргән шәһәрләр,
Мин белгән, ишеткән шәһәрләр, –
Җемелди
      йолдызлар булып,
Җемелди
Уйларымның чиксез күген бизәп.
Йолдызлар арасында
Якты ай сыман
Казан йөзә...
Йөзә...
      минем шәһәр,
            минем бетмәс бәхет!
Күзләремне ныграк кысам,
Ә шәһәрләр кысылмый,
Ә Казан кысылмый –
Шуңа
      сабый күк елмаям.
            Миңа рәхәт!

*1970*

## ШУЛАЙ КИРӘК

Син яшәгән шәһәр ваза түгел,
Мин вазага куяр гөл түгел.
Сиңа яхшы булса монда калу,
Миңа яхшы булыр китүем.
Курыккансың икән минем белән
Мин теләгән якка китәргә.
Ташла инде, узганнарны сөйләп,
Сөю диеп вакыт үткәрмә.
Үзсүзлегең, катылыгың бар, дип,
Холкымны да миңа аңлатма.

Дөрес юнәлешне юллар бирә,
Каршылыклар дөресен аңлата...
Синдә булган китап миндә дә бар,
Яшә әйдә анда әйткәнчә.
Китап улы түгел, ир улы мин,
Мин юлдашны сайлыйм эткәмчә:
Юлдаш булса, ил таянган иргә
Таяныргга курыкмасын ул,
Кирәк чакта тотар көчем булып
Янәшәмә басып барсын ул.
Үзсүзләнеп, хәтта усалланып
Тормыш сөйгәнемне төшенсен.
Киңәш бирсен миңа йомшарырга,
Катылыгым өчен кичерсен.
Мин сөенәм икән, миннән артык
Сөенә торган булсын юлдашым.
Мин бәреләм икән, еламамын,
Минем өчен юлдаш еласын.
Аны юатырга, елмайтырга
Көч табылыр минем йөрәктә.
Агач өйдә мине үстергән семья
Миңа тимер гадәт өйрәтте.
Шуңа сөя беләм, курка белмим,
Телисеңме, юлдаш итәмен?
Теләмәсәң, мин сөйсәм дә сине,
Бик сөйсәм дә ташлап китәмен.
Шулай кирәк... Шулай сиңа яхшы,
Шулай яхшы булыр миңа да;
Кешеләргә шулай яхшы булыр,
Шулай яхшы булыр дөньяга.

*1964*

## БАГУЧЫ БУЛГАН ИКӘН

Бер ал таңда илтеп мине
Караттың зур көзгегә –
Күз алдымда дулкын-дулкын
Узганнарым йөзделәр.
Аңладым мин, дус, кемеңдер
Багучы булган икән.
Ул көзгесен Кама итеп
Сиңа калдырган икән.

Бер тын кичтә ул көзгегә
Икәү карап уйладык.
Күз алдымда дулкын-дулкын
Киләчәгем уйнады.
Аңладым мин, дус, кемеңдер
Багучы булган икән.
Ул көзгесен Кама итеп
Сиңа калдырган икән.

Шул көзгене мин төнозын
Син югында күзләдем.
Хәтта анда бер дулкын да,
Бер йолдыз да йөзмәде.
Аңладым мин, дус, кемеңдер
Багучы булган икән.
Ул көзгесен Кама итеп

Сиңа калдырган икән.

*1971*

## КӘБИСӘ ЕЛ МӘРХӘМӘТСЕЗ, ИМЕШ

Бу җәй миңа әллә ни зур
Шатлык китермәде:
Эреле-ваклы
Ун-егерме шигырь –
Бөтен китергәне.
Зур кайгы да китермәде,
Рәхмәт бу җәемә;
Эреле-ваклы борчуларын
Җиңдем җае белән.
Инде җәем китеп бара,
Китә кышлавына.
Мин исәнлек теләп калам
Урман-кырларыма,
Хайван-кошларыма.
Озатып җәйне,
Кул болгап,
Мин балконда калам.
Һәм җәй миңа
Кабат кайтыр,
Әгәр кушса Аллам.
Колач җәеп каршылармын
Йә каршылый алмам...
Бу җәй миңа әллә ни зур
Шатлык китермәде.
Шөкер әле,
Киләчәккә өметемне
Бетермәде.
Гаиләм дә бөтен,
Казаным да бөтен әле.
«Кәбисә ел мәрхәмәтсез!» –диләр.
Мәрхәмәтсез түгеллеген
Исбат итим әле,
Шушы елның аркасына сыенып кына
Мәрхәмәтле еллар ягына үтим әле.

*2004*

## ЮК, БУ ЭШЛӘП АРУ ТҮГЕЛ

Алмыйм бүген кулга кәгазь,
Каләм дә алмыйм әле.
Алдады мине шигърият,
Һаман да алдый әле.
Эшләсен Равил, Ренатлар –
Мин эшләп ардым бугай;
Юк, бу эшләп ару түгел,
Мин яшәп ардым бугай.
Тик зарлану миңа оят,
Хәтта оят ару да,
Каршымда Ходай бүләге –
Мәңгелек ял барында.

*2004*

## ГОМЕР АРТЫК ТИЗ УЗА

Гомер юллары һәммәсе
Бер-беренә охшаштыр:
Уйлап сүгенер урыны да,
Сагыныр җире дә булыр.

«Бу яшәү – яшәү түгел» дип
Сүгенүче ишәйде.
Алай ук сызып ташламам
Мин үземнең яшәүне.

Тычкан куган мәче кебек,
Бәхет аулап карадым.
Бәхет тычканнан да елгыр –
Акыл кергәч аңладым.

Әкрен керә икән акыл,
Гомер артык тиз уза.
Хәзер бәхет тә ауламыйм, –
Теш-тырнагым нык тузган.

«Яшьлек тиле» диләр инде...
Ярый, тиле тиз дә узсын,
Үпкәм юк анысына.
Бәйләнчек картлыгым гына,
Акылына абына-абына,
Озаграк узар сыман...

*2004*

## ТЕГЕ ЯККА УЗАМ ӘЛЕ

Әллә чынлап,
    әллә юри картаелды бит әле.
И гүзәл зат!
    Мин узасы юл яныннан кит әле!
Дәшми узып
    йә сөйләшеп сине үпкәләтермен.
Начарланып куйды әле бу арада хәтерем.
Начарланып куйды әле йөрүем, күрүем дә,
Әмма дуслар элеккедән ачыграк күренә.
Тузган гомерем дивары ишелә иңнәремә.
– Әй ишелде,
Нык ишелде, бетерде мине! – дисәм,
Ярый әле дусларыма бирәсе кулым исән.
Теге якка узам әле –
    ишеге ерак калмады.
Ни үкенеч, мәңгелеккә әзерлегем чамалы.
Үкенү дә һәм елау да
    файдасыз инде, беләм.
Шуңа бүген мин үземнән
Һәм миндәйләрдән көләм.

*2004*

## ЭЛЕК ҺӘМ ХӘЗЕР

Яшәгән идем элек
Аз-маз гына селкенеп.
Хәзер яшим мин биеп,
Аллага шөкер, диеп.

Очты дуслар, гел очтылар,
Очтылар мин бар якка.
Оча дуслар, кача хәзер
Миннән ерагракка.
– Алда ни? – дип бәргәләнмим,
Алла кушканы булыр.
Дус бетсә дә, ялгыз калмам,
Минем дошманым булыр...

*2004*

## ШАТ ЯШӘҮНЕҢ СЕРЕ БАРДЫР

Шат яшәүнең сере бардыр,
Озак шуны белми йөрдем.
Хәзер бераз чамалыйм:
Тәрәзәгә килгән һәр көнне
«Минем өчен туган көн!» дип,
Гел елмаеп каршылыйм.
Әйтерсең лә һәр көн миңа
Сөенечле яңалык.
Ә дөресе – һәр көн миңа
Бик кирәкле ямаулык.
Һәр бүгенем йөрәгемә
Кичә алган
Яраларны ямарлык.

*2004*

## КҮТӘРИК БЕР ГАЗЛЫ СУ

Озын булса да гомер ул,
Кыска булса да гомер.
Ул – тар фани дөнья белән
Киң мәңгелек арасы.
Вакыт дигән машинада
Тукталыш, еллар аша
Бер җилдереп каласың...
Һәм чатта –
Соңгы тукталыш.
Тукталышта һаман шулай –
Сату-алуда шау-шу...
Юлдашлар! Аерылышкан чакта
Сезгә әйтер сүзем бар:
– Тутырыйк та бокалларны,
Күтәрик бер газлы су!
Мәңгелектә
Җәһәннәмдә
Очрашырга язмасын!

*2004*

## ӘНКӘМ ҖЫРЛЫЙ БЕЛГӘН ОЗЫН КӨЙ

Тауларыма тагы чыгам әле,
алар минем бәрхет тауларым.
Бәрхет кенә түгел ул тауларым,
алар минем бәхет тауларым.

Тауларыма тагы чыгам әле,

тыңлыйм әле – алар ни сөйли?..
Күңел киңлекләрен иңләп ага
әнкәм җырлый белгән озын көй.

Кешеләргә чиксез мәхәббәтем
шушы көйдә генә бар сыман.
Тауларыма басып җырлар идем,
җырым өчен дөнья тар сыман.

## КҮРӘСЕБЕЗ БАР ИКӘН

*(Алар һәм болар, яки гөлләр турында)*

Алар башка буын иде,
ә болар – башка буын.
...и язлар кабатлануы –
гөлләрнең ачылуы!

Чын төс иде, чын ис иде
калын толымнарыңда.
Тезләнеп торыр идем лә
узасы юлларыңда...
Алар шул бик үз иделәр,
болар да бик чит түгел.
Шулай да һаман аларны
юксынып куя күңел.
Чын сүз иде телләрендә,
күз яшьләре чын иде.
– Гафу итә күрегез! – дип
әйтергә дә соң инде.
Алар калган бакчаларда
хәзер ниләр бар икән?
Анда микән әле алар,
анда да болар микән?
Исе башка, төсе шашкан,
дөньясы бүген бүтән.
Алар кыяк-кыяк иде,
болар бит түтәл-түтәл.

Озын-озын түтәлләрнең
аралары тар икән.
Биниһая матур гөлләр
күрәсебез бар икән.

## КИГӘН ИДЕҢ ЯШЕЛ КҮЛМӘГЕҢНЕ

*Биектау районының Бикнарат егете Нияз Зыятдин улы*
*Хөснетдинов истәлегенә*

Казаннардан гына киткән булсаң,
белеп торсам исән йөргәнеңне?!
Еш сагыныр идем зур гәүдәңне,
абзый, диеп, кулың биргәнеңне.
...Ишегемә тулып керә идең,
бүлмә тутырып гөрләп көлә идең.
Әллә кемнәр миңа килә һаман,
син килмисең – ә бик кирәк идең.
Үз итмисең хәзер дусларыңны,
туган ягың, тавын, үзәнен дә.

Яшисеңдер бары әнкәеңнең
чыклы чәчәк кебек күзләрендә.
Синсез Мәскәү Мәскәү түгел инде
Анда калган ятим кызыңа да...
Күңелең дөньялардан киң булганга,
сыймадыңмы, Нияз, бу дөньяга?
Казаннардан гына киткән булсаң,
шәт, ишетмәс идем үлгәнеңне!
...Соңгы кабат сине күргәнемдә
кигән идең яшел күлмәгеңне.

*1995*

## ӨЧ ЗАКИР ҺӘМ АЛАРНЫҢ ӨЧ МАЛАЕ ТУРЫНДА ХИКӘЯТ

1

Булса да була бит
шундый кешеләр!
Әйе була
шундый кешеләр:
«күкрәкләре
    калкан-калкан,
мускуллары
    шалкан-шалкан».
Безнең дә авылда,
нәкъ безнең урамда
бар шундый өч батыр:
«йодрыклары
    чүлмәк-чүлмәк,
чәчләре
    кырып алынган,
башлары тап-такыр».

2

Әлбәттә, аларны
сез инде белмисез.
Сез безнең авылга
нигәдер килмисез.
Бар бездә өч Закир!
Килегез!
Күрерсез!

Аларга әбиләр:
– Балакай! – дип тора.
Һәр малай аларга:
– Абыкай, – дип тора.
Елмаеп, кул биреп,
кунакка чакыра.

3

Бар бездә өч Закир,
өчәү тиң батырлар!
Һәркемгә билгеле
янгынчы Закирлар!

4

Өч Закирның берсенә
бик рәхмәтле Гөлсинә.

Ул инде үсеп килә,
Гөлсинә инде белә.
Янгынчы Закир абый
уттан коткарган аны.
Күреп янган зур өйне,
бәреп кергән ишекне.
Алып чыккан урамга
Гөлсинәле бишекне.

Өч Закирның икесе –
алары узган айны
коткарганнар янудан
әби белән бабайны.

Узган елда өч Закир
чак янмаган үзләре:
коткарганнар янгыннан
сыерлар, үгезләрне,
сарыклар, бозауларны,
«Каравыл» дигән өйне,
ялгыш йокыга киткән
каравылчы кешене,
каравылчы янында
елап торган песине.

5

...һәм,
озын сүзнең кыскасы,
озын сүзнең кыскасы шул:
Закирларның һәрберсе дә,
барлык авыл кешесе дә –
олысы да, кечесе дә –
авылыбызда башка янгын булмаганын телидер.
Җир шарында башка янгын чыкмаганын телидер.

*1996*

## СЕРЛЕ ЧЕМОДАН

1

Булган бер малай,
торган ул малай
бик биек йортта,
унынчы катта.

Бу кыска малай,
бәләкәй малай
тиз-тиз киемен
кия дә икән...
Йә әтисенә
иярә икән,
йә әнисенә
иярә икән.

Үзе ул малай
куркак булмаган,
өйдә берүзе
калган берзаман.

Әнисе эшкә –
заводка киткән.
Әтисе эшкә –
заводка киткән.
Өйдә тып-тыныч,
коридор тып-тын,
кешеләр эшкә
таралып беткән.
Бу батыр малай,
бәләкәй малай
ун катлы йортта
берүзе икән.
Ул үзе генә
уйнап караган.
Китабын алган,
укып караган.
Әйе, караган,
җырлап караган.
Ятып караган –
йоклап арыган.

Тәрәзгә барып
караса түбән –
малай ни күргән?!
Ул нәрсә күргән?!
Урамнан берәү
йөгереп килгән,
туры ун катлы
йортка сикергән.
Биек сикергән,
күр син, күр әле!
Ак стенадан
өскә үрмәли...
Үрмәкүч сыман
үрмәли генә...
Ялгыз малайны
ул күреп менә.

Унынчы катка
җитеп килә ул.
Нинди кеше ул?
Ничек менә ул?
Аның малайга
сүзе бар микән?
Алайса, нигә
керми ишектән?
Әллә лифтта
йөри белмиме?
Ул стенадан
юри йөриме?
Каяндыр килгән
карактыр ул йә?
Тәрәзгә җитә,
керә бит өйгә!
Озын куллары,
күзе кап-кара.
Мыегы кара,
бу – кара карак.
Үзе карт карак,
бу бабай карак.

2

Бәләкәй малай
курка аз гына.
Кача тиз генә
өстәл астына.
Ни урлар карак?
Малай нишләсен?
Малайның үзен
алып китмәсен.
Карак тәрәздән
төшә идәнгә.
Ул мышнап беткән
өйгә менгәндә.
Бусы ни тагын?
Карак артыннан
сикереп керә
соры чемодан!
Карак артыннан
куа чемодан:
соры чемодан,
серле чемодан.
Абына карак,
китә тәгәрәп.
Тора сикереп,
тагын йөгерә.
Өстәл астыннан
карап боларга,
әллә көләргә?
Әллә еларга?

Юк ла бу карак
карак түгелдер.
Әнә ишектән
чыгып йөгерде.
Шап-шап ишекләр,
сырлы баскычлар,
буш коридорлар
гөрли-дөберди.
Карак артыннан
чапты чемодан.

Малай да чыкты
өстәл астыннан.
Малай да чапты
алар артыннан.

3

Бәләкәй малай,
бу җитез малай,
бу батыр малай,
бу матур малай
бабайны куып
җитәргә уйлый.
Йә чемоданны
тотарга уйлый.
Белергә уйлый,
соры чемодан
бабай артыннан

ни өчен чаба?
Әйе, ник чаба?

Иң алда бабай,
аннан чемодан,
аннан соң малай, –
чабалар өчәү!
Ни булыр менә?
Юл күтәрелә –
юл үргә менә.
Үрдә – тау өсте,
анда юл бетә.
Анда таш кыя
түбәнгә китә.
Өч катлы йорттан
ул кыя текә.
Биш катлы йорттан
ул кыя текә.
Ун катлы йорттан
ул кыя текә.
Шуны белмидер,
бабай белмидер.
Әйе, белмидер –
белсә, ул якка
нигә йөгерер?
Чемодан куып
җитте дигәндә,
бабай кыядан
китте түбәнгә.
Очты түбәнгә –
ташлар өстенә.
Нишләр бабакай?
Нишләр, мескенем?
Нишләр чемодан,
ул да сикерде!
Алар артыннан
бәләкәй малай,
бу батыр малай,
сикерә хәзер,
сикерә инде.
Сикерми икән,
ул башын кашый:
шүрли шикелле,
шүрли шикелле.
Нык курыкмый ул,
курка аз гына.
Карый түбәнгә –
кыя астына!
Егылды бабай
ташлар өстенә,
торып тузанын
какты өстеннән.
Тагын йөгерде
кырларга табан.
Әнә ташларга
төште чемодан.
Әллә чемодан
каты бәрелде?
Әллә бабайдан
калганын белде?

Бик зур авызын
ачып чемодан,
елап җибәрде
ачык чемодан.
Елама алай,
соры чемодан!
Бу әйбәт малай,
сине ала ул...
Төшеп ала ул,
сукмак таба ул.
Акыллы малай,
батыр малай ул.

4

Өйдә малайны
әтисе көтә.
Әнисе көтә –
кайгырып беткән.
Урамга чыгып
бөтен күршеләр
малайны көтә,
кайгыра икән.

Әнә ул малай
кайту юлында.
Серле чемодан
малай кулында.
Бу чемоданмы?!
Буш чемодан бу,
бик җиңел, димә,
җип-җиңел, димә!
Шатлыгы да күп
аның эчендә.
Кайгысы да
зур аның эчендә.
Ул бер поездда
адашып калган.
Хуҗасы аны
чак табып алган.
Күргән-белгәне
аның күп әле.
Батыр малайга
үзе сөйләде:
чиратта торган,
вокзаллар күргән.
Ул таксиларда,
атларда йөргән.
Авыллар үткән,
шәһәрләр үткән.
Йокламаска да
өйрәнеп җиткән.
Өйрәнеп җиткән
авып йокларга
самолетларда,
пароходларда.
Өйрәнгән ул
тиз уяныргa да.
Серләр ишетеп
уйланырга да.
Кызык юлчылар

күргән юлларда.
Өйрәнеп җиткән
кызык тыңларга.
Тәмам күнеккән
юлда йөрергә,
тирбәлеп кенә
кулда йөрергә.
Хуҗасы гына
юллардан туйган.
Хуҗасы гына
картаеп куйган.
Ала пенсия,
эшен ташлаган.
Өендә генә
тора башлаган.
Төнлә – өендә,
көндез – өендә,
берүзе яши –
бу нәрсә инде?!
Ашыкмый гына
ашап утыра...
Йә кашыгына
карап утыра.
Йөреп уйлана
йә барып ята.
Аны чемодан
елап уята:
«Юлга чыгыйк», – ди.
Көндез уята,
төнлә уята...
Көн дә уята:
«Әйдә чыгыйк», – ди.
«Китик!» – ди икән.
Хуҗасы аннан
аптырап беткән.
Чемодан шуны
аңламый икән.
«Китик!» – ди һаман,
«Юлга!» – ди икән.
Инде нишләсен
картайган хуҗа?
Ул чемоданын
берәр юлчыга
бүләк итәргә
дип тә уйлаган.
Соры чемодан,
серле чемодан,
елак чемодан
риза булмаган.

5

Мыегы кара,
күзләре кара
ул бабай карак
булмаган икән.
Артык йөдәткән
чемоданын ул
адаштырырга
уйлаган икән.

Ә малай тапты,
малай сөенә...
Чемодан тотып
кайта өенә.
...Әтисе тирги,
әнисе белми,
чемодан серен
тик малай белә.
Әйе шул менә,
ул гына белә!

Аптырау тулган
ун катлы йортка:
– Кайткан бит малай!
– Чемодан тоткан!
– Чемодан тоткан!
– Чемодан тапкан!
Бераздан малай,
бәләкәй малай,
бу батыр малай
йокларга ята.
«Тор әле, балам!
Ник елыйсың?» – ди,
әнисе аны төнлә уята.
...Икенче төнне
килә әтисе:
«Ник елыйсың? – ди, –
Нигә әйтмисең?»
Килә әнисе,
карап торалар.
Тыңлап торалар,
сизәләр шунда:
малай түгел ич,
чемодан елый!
Чемодан елый
койка астында.
«Ташла чыгарып
син моны!» – диләр,
менә малайны
тагын тиргиләр.
«Тапкан җиреңә
илтеп куй!» – диләр.
«Йокы бирми ул,
елый ул», – диләр.
«Мондый чемодан
булмый ул!» – диләр.

6

Нишләп булмасын?!
Була шул, әнә
соры чемодан
ята идәндә.
...Ята идәндә
серле чемодан.
Туктады хәзер
төнлә елаудан.
Инде көндез дә
дәшми малайга.
Юллар турында

сөйләми аңа.
Ялына малай:
«Сөйлә!» – ди аңа.

Әйе, чемодан
бер сүз эндәшми.
Гади чемодан
шикелле яши.
...Үпкәләдеме?
Сере беттеме?
Ләкин беркөнне,
көннән бер көнне!
Шулай беркөнне,
эти-әнисе
эштә вакытта,
бәләкәй малай
мәктәптән кайта.
«Чемоданкаем,
эндәш әле», – ди.
«Сөйләшик инде,
сөйләш әле!» – ди.
«Әйдә, без дуслар
булыйк әле!» – ди.
«Хет икәү бергә
елыйк әле!» – ди.

7

Шул мәлдә телгә
килгән чемодан:
«Еламыйк әле!» –
дигән чемодан.
«Юкка еладым
мин теге чакта.
Ник, – дигән, – икәү
еларга юкка?
Мәктәптә бишле
аласың, – дигән. –
Син гел бәләкәй
калмассың, – дигән. –
Үсәрсең, – дигән, –
ерак китәрсең.
Мине дә алып,
җырлап китәрсең».

Үсә, әлбәттә!
Ала, әлбәттә!
«Алам!» дияргә
оныткан хәтта,
бәләкәй малай
биеп җибәргән.
Чемодан биеп
аңа ияргән.
Әти-әнисе
кайтып кергәннәр.
Бу хәлгә карап
озак көлгәннәр.
Карт та таныган
үз чемоданын:
никтер тәрәзгә

менгән ул тагын.
...Ул стенадан
менгән дә күргән.
Һәм стенадан
төшеп йөгергән.

## ӨМЕТ

Ал гөлем ак кар астында
Калды шул инде көлеп.
Юк, сулмас ул, коелмас ул,
Ул – минем өмет гөлем.

Йөрәгемнән ал гөлемә
Карлар аша көч бирәм.
Бик сизәм лә, кыш озын ла,
Кар салкын ла, кар тирән.

Яз җитүгә кар югалыр,
Ал гөлем чыгар көлеп.
Юк, сулмас ул, коелмас ул,
Ул – минем өмет гөлем.

*1973*

## БУ КИЧ СӘЕР КҮРЕНӘ

Кояш җиргә төшәр-төшмәс,
Бу кич сәер күренә.
...Яр буенда бер ал чәчәк
Күккә хәтле үрелә...
Кулымдагы кармак сабы
Җирне дә үтә сыман.
Кармагымда кыртыш чыга,
Җәен чыккандай судан.
Чәчрәп киткән һәрбер тамчы
Бер зур океан бугай.
Елга шавы – минем тавыш,
Дулкын минем җан бугай.
Әллә ниләр уйга килә,
Ярый берәү дә белми.
И рәхәт – озын уйларым,
Ярый берәү дә бүлми?!
Ут турында җырлый кояш,
Сүзләрен ишетәмен...
...Җемелди су өсте тулып
Акчарлак бишекләре.

*1975*

## ҖӘЙ УРТАСЫНДА

Бер сүзең миндә мең сүз тудыра ала,
Эндәшмәвең өшетте.
Җәй уртасында
Ярга ябышып туңган
Пристань кебек торам әле менә...
...Кич елыша җиргә әкрен генә.
Төзелеш объектларында, басуларда,

Гранит тауга батып кергән карьерларда,
Мин язып алмаган шигырь юллары
Чәчелеп кала.
Тарих тарафыннан мәңгегә күмелгән
Алтын тиенлекләр төсле
Кала...
...Ярты төндә чишмәгә ай төште,
Үбештеләр.
Кемдер комачаулады аларга.
Чишмә камышларга качты,
        ай – болытларга.
Тиздән урам утлары,
Йолдызлар –
Мин үлемгә хөкем иткән
Сүзләр шикелле.
Бу таң миңа шулай килде!
Карашыңны
тартып алып
        күккә чөя торган
Завод торбаларыннан
Кара төтен күтәрелә!
Анда
Станоклар тавышы яна,
Уйланулар, елмаюлар яна.
Мин язмаган хәлләр яна.
Җылый-җылый, көлә-көлә яна.
Янган елмаюлар
                    хакына
Бер сүз әйт әле, ярый, шушы.
Миңа да соңгы сүзең булсын:
Артык озак һәм тупас шаяруыңны
Үзең сизденме соң?

*1971*

## КҮЗЛӘРЕНӘ БӘХЕТ ТУЛГАН, ДИЛӘР

«Аны алга илтә һәр адымы,
Гел уңышлар көтә аны!» – диләр;
Юк, аңа да көзге яңгыр койды,
Күзләренә бәрде юеш җилләр.
Күлмәк кенә кигән хәлдә иде,
Башында да яулык кына иде;
Яр сөймәгән япь-яшь кызый иде,
Өрсәң юкка чыгар сыман иде.
Кеше алай җиңел юкка чыкмый,
Бер күмелеп, бер күренеп бара;
Ул очрады тау-тау кирпечләргә,
Актарылып яткан мәйданнарга.
Җирдә ята иде нәни бәхете,
Биләвендә үксеп беткән иде;
Ишетә белде шуның көчсез тавышын,
Ул иелеп аны ала белде.
Һәм үстерә алды үз бәхетен –
Тик югалтты япь-яшь кызый чагын;
Аңа хәзер ханым булу килешә,
Зур бәхете алдан йөри аның.
«Ул шәп яши!» – диләр, аңа карап,
«Күзләренә бәхет тулган!» – диләр;
Көнчеләрме әллә шулай әйтә?

Әйтә микән шулай бәхетсезләр?

*1973*

## ЯШИСЕ КИЛӘ

Искеләрне чөйгә элдем,
Соңгы яңамны кидем.
Мин өемне ташлап киттем,
Җитте, искерде, дидем.
Ә шул өйгә тагы кайттым,
Кире кайттым – шигырьгә.
Көткән мине искеләрем,
Мичтә – минем күмерләр.
...Кайда йөрдем?
Ник күрдемме?
Һич кирәкмәс ул сиңа.
Ул тавышлар, күп танышлар –
Күзләремдә чүп сыман.
Бар да зурлар, бар да яңа,
Вaклары да эреләр,
Үзләре шат, җырлары шат,
Кайгы барын белмиләр.
Исерек җилләр хәтердә –
Җилләр анда лаякыл.
Агачта яфрак шикелле,
Калтырый башта акыл.
...Иске өйдә – аек моңым,
Су, икмәк исе килә.
Һәм каләм аласы килә,
Тагын яшисе килә.

*1971*

## ЧЫН ЯЛГАН

Җир шундый зур икән!
Минем кечкенә баш
Әллә ниләр күрде монда.
И-и-и, сөйли килсәң!
...шулай бермәл
Булган идем
Ялганчылар авылында.

Ул авылда
Хатын-кызы, ир-аты,
Яше, карты – бөтен кеше,
Тавыгы, чебеше
Болай диләр:
«Бу зур җирне,
Бу түгәрәк җирне,
Кайчандыр ерактан
Тәгәрәтеп бирегә
Безнең бабайлар китергән», – диләр.

Чатнатып, күзеңә карап
Шулай сөйлиләр.
Әйе! Ул авылда һичкем
Ялгышып та бер дөрес сүз әйтмәс,
Вәт сөйлиләр анда!

Анда, ничек әйтим,
Чиста, чын,
Саф алтындай ялган!
Ялтырап торган ялган!
Үз күзләрем белән күрдем,
Беркөнне
Ул авылның ялганчылары
Авыл өстенә җиткән кояшны
Ялганлап кирегә бордылар.
Кояш кирегә,
Көнчыгышка таба
Барды, барды да
Берзаман
Аңына килде;
Кабат көнбатышка йөзә башлады.
Соң инде,
Кояш саташып йөргәнне
Үзегез дә
Күргәнсездер инде?

Ә, юк!
Күрмәгәнсеңдер,
Ул көнне
Сезнең авыл өстендә
Кара болыт иде.

*1974*

КАСА МАРИ

Уйларда тирбәлә Кишәнәү һәм Казан,
Йөрәкләр сөенеп өр-яңа җыр яза.
Танышу мәҗлесен күңелле үткәрик,
Калалар саулыгы өчен бер күтәрик.

Кушымта:
Каса Мари          2 тапкыр
Шаулый көн дә,
Тау битендә,
Юл читендә.

Кызлары учактай, җырлары ялкындай,
Ярый ла пиносы, пиносы салкын, һай.
Егетләр, мәҗлесне күңелле үткәрик,
Шат кызлар саулыгы өчен бер күтәрик.

Кушымта:
Олы йортта          2 тапкыр
Бай табын бар.
Бусы бетсә,
Сый тагын бар.

Дөньялар сау булса күрешербез тагын да
Кишәнәү янында һәм Казан ягында.
Бүгенге мәҗлесне күңелле үткәрик,
Дөньяның саулыгы өчен бер күтәрик.

Кушымта:
Каса Мари          2 тапкыр
Шаулый көн дә,

Тау битендә,
Юл читендә.
Олы йортта
Бай табын бар.
Бусы бетсә,
Сый тагын бар.

Хуҗаларның
Татлы сүзе –
Әйтерсең лә
Пешкән йөзем.

* * *

Берәүгә кояш син,
Берәүгә син айдыр.
Берәүгә син җәйдер,
Берәүгә тургайдыр.
Берәүгә син чәчәк,
Чишмәдер берәүгә.
Ә миңа син язмыш –
Санамыйм берәмләп.
Гүзәллек күп синдә,
Татыдым барсын да.
Һәм минем өчен үк
Агу да бар синдә.

## ЭСФИРГА

Бәйрәмнәр күп, әй бу кесә такырлык!
Давыдовның рухын түргә чакырдык.
Ак башлы һәм ак уйлы Марс килде,
шунсы әйбәт: хәзер ул эчми инде.
Наис Гамбәр дә пәйгамбәр – ташлаган,
рөхсәт ит, Эсфир, мәҗлесне башларга.
Күтәрик бер,
бәйрәмең котлы булсын!
...Вәт, хәл иттек бер яртының яртысын,
илленнән соң хәл итәрбез калганын.
– Калганы да хәмер түгел, ялган ул! –
дип, Яһудин кабымлыкка ашыкты...
...сагыш каптык шатлык дигән кашыктан.

## ДАНИЯ

Син, Дания, серле-сихерледер,
бу нисбәттән юктыр ишләрең.
Күзгә чалынасың да Мөштәридә,
тузгытасың бөтен хисләрне.

Безне узганнарга күчерәсең,
их, менә ул – Бауман, 19.
Мәҗлесләрнең бу тулырак чагы,
бүлмәләрдә бәйрәм утыбыз...

Кызык сөйли әнә Гариф Ахун,
гөрләп көлә Фәрваз Миңнуллин.
Сибгат Хәким артык җитди бүген,

Хәсән Туфан әллә ни уйлый.

Ал гармунны, әйдә, Илдар Юзи,
картлачларның уен бүл әле.
...Илдар уйный!
Чү, ишектән керә
Зәки Нури дигән «Шүрәле».

Үзең сихерләдең, Даниякәй,
узганнарга шуңа кагылдым.
Максатым тик сине котлау иде,
менә әйтер сүз дә табылды:
– Яңа меңьеллыкның
        май аенда
очрашырбыз диеп кем белгән?
Туган көнең, туган аең белән
котлыйм сине ихлас күңелдән!
Узган еллар, юллар, елмаюың –
һәммәсенә зурлап баш иям.
...Ешрак тузгыт
безнең уй-хисләрне
      Мөштәригә килеп, Дания!

## МЕНӘ ПУШКИН ҺӘЙКӘЛЕ...

Тудырганнар.
Үстергәннәр.
Үтергәннәр.
Һәйкәл куйганнар...
Менә Пушкин һәйкәле...
Кайда да һәйкәл һәйкәлдер –
Шушыдыр инде...
Ул мине аңламый –
Мин аны аңлыймын.
Мин аңа җан булып
        кушылыр идем.

## «БАКЫР ҖАЙДАК», ЯКИ ПЕТР I ҺӘЙКӘЛЕ ЯНЫНДА УЙЛАНУ

Тыяр иде атын, узмас иде,
Туктар иде минем янымда:
Белер өчен бүген ниләр барын
Россиядә, Казан ягында.
Тыңлар иде, аңлар иде мине,
Аңлый алгач балыкчыларны;
Мин дә бер балыкчы, сүзләр сөзеп,
Коры җирдә беттем чыланып.
Шуңа ышанамын: Татарстанны
Сөйләп бирер көчем барына.
Аны сүзләр белән һәйкәл итеп
Бастыралам Нева ярына.

## ЯХШЫЛЫК ҺӘМ ЯМАНЛЫК

Боргаланып,
Боргаланып,
Яшь үләннәр
Арасыннан

Болганчык су
Аккан сыман,
Алга шуа
Кара елан.
Баш калкыта,
Телен суза.
Куян куркып
Чабып уза.
Тал төбенә
Бака поскан.
Калтырана
Сукыр тычкан.
Һәрнәрсәнең
Коты очкан.
Күрә елан,
Көлә елан:
«Өркетәм, – ди, –
Барысын да».
Менә гаҗәп,
Курыкмыйча
Нидер ята
Каршысында.
Килеп җитсә –
Сандык икән!
Кем соң аны
Ташлап киткән?
Капкачы да
Ачык калган.
Кояш аңа
Нурын салган.
«Яхшы урын
Тыныч ялга», –
Ди дә елан,
Бу сандыкка
Кереп ята...
Китә йоклап.
Гырлавыннан
Җир селкенә,
Үлән куркып
Дер-дер килә,
Һәм гөлләрдән
Җиргә таба
Чәчкә-чәчкә
Яшьләр тама.
Ерак түгел
Өч чикерткә
Бер-берсенә
Каш сикертә.
Өченчесе,
Батыраеп,
Елан яткан
Җиргә китә.
Сизсә елан –
Эше харап!
Сыңар күзе
Белән карап,
Кача-поса
Килеп җитә.
Ачык торган
Зур капкачны

Бар көченә
Кинәт этә.
Шап итеп
Ябыла капкач
Һәм бикләнә...
Йә, елан, ач.
Юк шул инде,
Ача алмый.
Юкка дулый,
Юкка шаша.
Чикерткәгә
Юкка яный
Тактадагы
Ярык аша.
Белмиләр дә
Чикерткәләр,
Шаян көйгә
Кыл чиртәләр,
Тыпырдыйлар
Һәм җырлыйлар:
«Агулы угы белән,
Бар явызлыгы белән,
Күпләргә янап йөргән,
Күпләргә кайгы биргән
Елан ята сандыкта,
Су буенда, таллыкта.
Чыр-р-р,
Чыр-р-р,
Чыр-р-р,
Чыр-р-р,
Шушы булыр безнең җыр.
Кешеләр сөенсеннәр,
Хайваннар биесеннәр,
Кан эчеп йөргән елан
Үлә бүген ачлыктан
Су буенда, таллыкта,
Чыга алмый сандыктан.
Чыр-р-р,
Чыр-р-р,
Чыр-р-р,
Шушы булыр безнең җыр.

Сандыкны кар
Каплап китә.
Елан һаман
Үлми бит, әй!
Тик көннән-көн
Хәле бетә.
Көчкә-көчкә
Язны көтә.
...Беркөн,
Кояш кыздырганда,
Әрәмәдән кайта Ханнан.
Сандык күрә каршысында,
Шундый тавыш килә аннан:
«Әй, дускаем, кил бирегә,
Кил, иреккә мине җибәр».
Сандыкның авыр капкачын
Шыгырдатып Ханнан ача –
Куркуыннан төсе кача.

Чигенә башлый артка таба.
Ә сандыктан
Аңа таба
Елан шуа,
Елан ага,
Елан көлә:
«Кара, ничек кача белә,
Тик белми бит, мин еланнан
Кем соң качып котыла алган?
Тукта, малай,
Барыбер тотам!
Карыным ач,
Сине йотам».
Сизеп каты ялгышканын,
Елый-елый әйтә Ханнан:
«Сиңа ирек биргән өчен
Шулмы, елан, миңа файдаң?
Ичмасам, син зурла мине,
Ярты сәгать гомер биреп.
Мине ашарга бармы хакың,
Өч шаһиттан сора күреп?»
Елан әйтә:
«Алай дисең?
Андый файдам
Сиңа тисен».
...Ул арада
Төлке килә,
Монда булган
Хәлне белә
Һәм Ханнанга
Карап көлә:
«Тәмле азык
Шикелле бу.
Әйдә, елан,
Эшеңдә бул.
Карап торма,
Йотып җибәр.
Яхшылыкка явызлыкны
Күп төлкеләр, шәп эш, диләр».
...Бүредән дә
Шул ук җавап:
«Әйдә, елан,
Йотып җибәр.
Яхшылыкка явызлыкны
Бүреләр, бик шәп эш, диләр».
Өченчегә – килүче юк...
Елан:
«Инде йотам», – диде.
Авызын гына ачкан иде...
Атка менеп,
Шат җыр көйләп,
Ак сакаллы
Бер карт килә:
«Сәлам сиңа,
Елан чибәр,
Ничек хәлләр,
Сөйләп җибәр?»
Әйтә елан:
«Менә, картлач,
Бу сандыкта озак яткач,

Шушы малай ярдәмендә
Бүген чыктым якты җиргә.
Бик карыным ачканлыктан,
Бу малайны инде йотам».
«Һи-һи-и, – ди карт, –
Карап торма,
Йотып җибәр,
Йотып җибәр.
Яхшылыкка явызлыкны
Кайберәүләр, шәп эш, диләр.
Тик
Гафу ит, елан туган,
Син мине алдыйсың бугай.
Шушы хәтле олы гәүдәң
Бу сандыкка сыймас кебек.
Кеше кечерәя белер,
Ә елан халкында гомер
Андый талант булмас кебек.
Белгәнемчә, күп кешеләр,
Елан тупас, ахмак, диләр».
Кыза елан:
«Кит, карт юләр,
Сөйләп торма
Кеше сүзен.
Күзең белән
Күр син үзең.
Менә ничек безнең халык».
Камчыдай оста уралып,
Елан сандыкка яңадан
Эһ дигәнче сыеп бетә.
Бабай һаман якын килә,
Үзе һаман баш селкетә.
«Гаҗәп!
Талант!» – дип шаккатып,
Сандыкның авыр капкачын
Ул ябып куя шартлатып.

*1963*

## АНЫ ШАТЛЫК ҖЫРЫ ОЗАТА КИТӘР

Бер хикәя сөйлим хәзер сезгә,
Игътибарсыз булмасагыз иде!
Ак йолдызлар төнге ай әкиятен
Тыңлагандай тыңласагыз иде!

Беләсезме, чем-кара Карлыгач
Кичә җилкәмә үк килеп кунды.
И сөендем, тын да алмый торам,
Кая инде кыймылдату кулны.
Колагыма сөйли сәнәк койрык:
– Гыйбрәтле хәл күрдем еракта, – ди. –
Бер егетне анда чыпчыклар да
Күңелсез җыр җырлап озата, – ди.
Ул нинди җыр, аны кем чыгарган –
Бу ни гаҗәп, бу ни хикмәт икән?
– Белим әле, – димен, – тыңлыйм әле.
Сәнәк койрык болай дәвам итә:
– Мин дөресен сөйлим, кечкенә мин,
Миндә ялган сүзгә урын да юк.

...Егет Гата атлы, ул зур хата
Эшләгән, ди, малай чагында ук.
Яшел җәйдә иптәшләре белән
Киткән Гата качышлы уйнарга.
Үзе белән, кесәсенә яшереп,
Әрәмәгә пәке алып барган.

Качып утырганда тал астында,
Каршысында япь-яшь
Тирәк күргән.
Яшь тирәккә шунда Гата кулы –
Үткен пәке тоткан кул үрелгән.
Тирәк бу тирәнең бердәнбере,
Куанычы, мактанычы икән...
Шушы хакта уйламаган Гата,
Кызык итеп бу Тирәкне кискән.
Яфракларын юнып, аткан аны –
Тик кадалган Тирәк юеш ярга.
Әрәмәдән китмәс шатлык булып,
Яңа тамыр җәйгән, яфрак ярган.
Тирәге дә гади Тирәк түгел,
Моңлы Тирәк, җырчы Тирәк булган.
Кыштыр-кыштыр килеп, әкрен генә
Тирәк күңелендә бер җыр туган.
Торган саен җыр өлгерә барган,
Җәйләр үткән саен, Тирәк үскән.
Барлык шомыртлардан, баланнардан,
Каеннардан Тирәк тизрәк үскән.
Һәм ул күреп алган бер иртәдә,
Әрәмәлек аша таш юл үтә;
Таш юл буйлап, эре-эре атлап,
Чемоданын тотып Гата китә.
Тирәк яфраклары, күзләр кебек,
Барсы да Гатага төбәлгән.
Моңлы-зарлы көйгә менә нинди
Җыр башлаган Тирәк шушы мәлдә:
«Үскән агачларга киңәшем бар,
Яшел кием матур икән бигрәк.
Озак яшим дисәң яшел киеп, –
Бу кешедән сакланырга кирәк.

Нәфис гөлкәйләргә киңәшем бар,
Чәчәк ату матур икән бигрәк.
Озак торыйм дисәң шау чәчәктә, –
Бу кешедән сакланырга кирәк.

Очкан кошкайларга киңәшем бар,
Күктә очу матур икән бигрәк.
Озак очыйм дисәң шулай уйнап,
Бу кешедән сакланырга кирәк.

Һәрнәрсәгә минем киңәшем бар,
Гомер итү матур икән бигрәк.
Матур гомереңнән мәхрүм итәр, –
Бу кешедән сакланырга кирәк».

Әнә шундый җырны җырлаган да
Тирәк басып калган, Гата киткән.
Җырны таллар откан, Гата бара,
Таллар аңа карап җырлый икән:

«Нәфис гөлкәйләргә киңәшем бар,
Чәчәк ату матур икән бигрәк.
Озак торыйм дисәң шау чәчәктә, –
Бу кешедән сакланырга кирәк».

Җырны үлән откан, аннан – имән.
Гата киткән һаман, Гата киткән.
Юл читендә инде каен җырлый, –
Җыр Гатаны шулай озата киткән.

Өч көн барган Гата, өч төн барган,
Нарат урманына кергән барып.
Ләкин җыр да килгән күчә-күчә,
Наратлар да җырлый аны танып:

«Үскән агачларга киңәшем бар,
Яшел кием матур инде бигрәк.
Озак яшим дисәң яшел киеп, –
Бу кешедән сакланырга кирәк».

Җәйне үтеп, Гата кышка кергән,
И кар ява икән бурап-бурап.
Гата бара, кыекларга поскан
Чыпчык малайлары җырлап тора:

«Очкан кошкайларга киңәшем бар,
Күктә очу матур икән бигрәк.
Озак очыйм дисәң шулай уйнап, –
Бу кешедән сакланырга кирәк».

Ерак китә Гата, һаман китә,
Тагын җәйгә чыга, кышны үтеп.
Тау астында гына чишмә ага,
Улак буйлап, чылтыр-чылтыр итеп.

«Нәрсә сөйли икән бу чишмә?» – дип
Туктап тора Гата, тыңлап тора.
Кызганычка каршы, бу чишмә дә
Безгә таныш җырны җырлап тора:

«Һәрнәрсәгә минем киңәшем бар,
Гомер итү матур икән бигрәк.
Матур гомереңнән мәхрүм итәр –
Бу кешедән сакланырга кирәк!..»

Башын иеп, авыр сулап куя,
Күңеленә шатлык тапмый Гата.
Ял итәргә уйлап, тау битенә,
Яшел чирәмлеккә сузылып ята.

Тау чишмәдән ишеткәнме әллә?–
Ул да тора икән гүләп-көйләп:
«Бу кешедән сакланырга кирәк...
Бу кешедән сакланырга кирәк...»

Һаман күңеленә шатлык тапмас,
Һаман шулай йөрермени Гата?

Малай вакытында уйнаганда
Эшләгән икән шул хәтәр хата.

Тик ул кискән Тирәк инде хәзер
Иңгә-буйга җиткән, басып тора.
Зәңгәр күк астында яшел Тирәк
Яшел болыт кебек ташып тора.

Хикәямне шунда тәмам итәм,
Карлыгач бит шунда тәмам итте.
Кая ашыккандыр сәнәк койрык,
Сау бул, диде дә ул очып китте.

Мин борчылып калдым Гата өчен,
Ләкин юкка бугай борчылуым.
Ул әйләнеп кайтыр бит карарга
Бала чакта уйнап үткән юлын.

Күрешерләр, аңлашырлар алар, –
Тирәк аны, бәлки, гафу итәр.
Юкка чыгар шунда күңелсез җыр,
Аны шатлык җыры озата китәр.

*1970*

## КҮЗ КАРАСЫ

Милләтләрдән монда кем генә юк,
Хезмәт көе тора яңгырап.
Яңа Чаллы!
Синең нигезеңә
Татар җыры салып калдырам.

Җыр башы

Җирдә бомба, бомба, бомбалар бар,
Янгын, янгын, янгын, янгыннар...
Ятим, ятим, ятим, ятимнәр бар,
Кайгы, кайгы, кайгы, кайгы бар.

Хәбәр, хәбәр, хәтәр хәбәрләр бар,
Гел яралый шулар бәгырьне...
Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.

Ерак күккә уза безнең юллар,
Юл башлары Җиргә таяна...
Сөйгән ярлар көтә юл башында,
Юл башында тора чал ана.

Җир эчендә безнең тузган йортлар,
Җирдә әткәйләрнең кабере...
Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.
Якты чишмә чыга елтыр-елтыр,
Нурга коенып үсә ак гөлләр.

Ташлар тезеп кеше йортлар сала,
Матур үтсен өчен гомерләр...
Кеше йортын кайчак кеше вата,
Шунысы күңелләрне җәберле.
Күз карасы кебек түгәрәк Җир
Күз карасы кебек кадерле.

Көлдә соңгы чаткы булыр күзләр,
Әгәр Җирне саклый алмасак!..
Ник йөрәкне кыса шушы тойгы,
Хыял канатларын ник баса?!
Хәбәр, хәбәр, хәтәр хәбәр нигә?
Нигә кайгы, кайгы, кайгы бар?
Нигә чыга янгын, янгын, янгын?
Нигә бомба, бомба, бомбалар?!

Җыр дәвамы – җимерелмәскә!

Сүзен
    Чаллыдан башлаган иде бит,
Бомба турында
    күбрәк сөйли, дип
        әйтүче булыр булуын.

Ләкин
    миңа
        моны әйтмәс
            минем буын!

Минем буын –
Бомба ярылганда,
Әтиләр, әниләр янганда,
Йортлар ауганда аунап
    елаган малайлар.
Безнең –
    җимерүчегә
        үз караш,
            үзебезнең
                үзгә
                    ачуыбыз бар.
Шул ачудыр, ахры,
Безне
    кырысрак итә,
Ләкин тырышрак итә,
    төзелешләргә
        ныграк
            рухландыра.

Шул ачудыр
Кырык бер-кырык бишенче еллардан
    бирле,
Әзер бул, аң бул, сак бул
    дигәндәй,
        канымызда
            сулкылдап тора...

...Дуслык,
    азатлык,
        бәхет өчен
            илара килешүләрдә,
                халыкара сөйләшүләрдә

Көрәшеп,
    минем буын
        таңнар тыныч тусын өчен яши...
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Кичер, кешелек,
Синдә җимерүче барын күреп,

Минем буын
    яңа солдатлар әзерли
        Яңа Чаллы сагына.

– Бер, ике, өч!
Бер, ике, өч! –
Ил чикләрен,
    ил байлыгын
        барлап
            яшь кенә кешеләр бара.

– Бер, ике, өч! –
Яшь кенә кешеләр баса
    ракеталар янына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр керә
    таза танкларына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр чума
    диңгезләр кочагына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Яшь кенә кешеләр:
    «Тиздән кайтам» диеп
        хат яза
            әнкәсенә,
                сөйгән ярына.

## Җыр дәвамы – шатланыр өчен

Өр-яңа урамда йөрим...
Тормышта шунсы кызык:
Урамнардан мең узсаң да,
Булмый бит тыныч узып.
Шагыйрь башы – уйлар өчен,
Уйлары – халкы өчен:
Шул уйларга басып халкы
Өскәрәк калкыр өчен...
Якты яшен уйнагандай
Балкып ала уйларым;
Күзе аша күрәм шулчак
Кемдә нинди хис барын.
Чагыштырып карыйм аннан
Хисләрен кешеләрнең;
Шәһәрләр киләчәгенә
Мин шулай төшенәмен.
Шулай итү хәвефләрдән
Саклану өчен кирәк.
Шулай итү алга карап
Шатлану өчен кирәк.
Яңа үсеп чыккан Чаллы –
Ул сабый кебек әле:
Кайдадыр күке кычкыра,
Ул саный кебек әле.
Тик аның яшәр еллары, ярсулары, язлары –
Бүгенге безнең максатка
Таянып тора бары!
Ә максат корал була ул,
Хискә әйләнү белән.
Ул коралдан куәтлерәк
Коралның югын беләм.

Жыр дәвамы – эш көне

Яшьләр!
Көчлеләр!
Эшлиләр!
Дөнья күргән
Картлар нишлиләр?..
Берсе гаҗәпләнеп карап тора:
Торсын гына, ирек!
Берсе киңәш бирә:
Бирсен генә, ирек!
Берсе эшкә керә:
Керсен генә, ирек!
...«Туктале, нинди эш?
Нинди цех турында син?» – диеп
Сүземне бүлдерсәң, ирек!
Ләкин беләсеңме, туганкай,
Миңа хәзер
Шигырьне
    кирпеч, балчык, ком итәргә түгел,
Комны, балчыкны, кирпечне
    шигырь итәргә кирәк,
Кешеләрне шигырь итәргә кирәк.
Эш көне!
Бар да эшли...
...Күрәсеңме,
Күбәләк кенә кыз
Кранда
Авыр панельләрне
    югары этажга күтәрә.
Буем җитмәс аңа
    үрелсәм дә,
        гөлләр бүләк итәргә.
«Әй, сеңлем, исемең ничек?» – дип кычкырсам,
    тавышым ишетелмәс үзенә.
...Каршымда, үкереп,
Төяүле
    таза машиналар
Төзелеш мәйданына керәләр,
Бал кортлары кергәндәй
    умарта күзенә.
Керәләр...
Монда юл кая?
Ничек барырга?
Ничек чыгарга биредән?
Карашың адашыр беренче күрүдә!
...Тегендә
Нинди тау иде, ә?!
Иске тау,
Гасырлар кичкән тау:
Эшчеләр
Тотындылар аңа,
    хисләрен,
        мускулларын киереп...
...Инде
    горур тау
        каршыңда
            балавыздай эри:
Салдырып

Кара балчыгын,
Ташыйлар бер якка –
Анда яңа тау, кара тау
    калка тора,
Бу – ашлы кара җир,
Игенчегә
    комлы кырларына таратырга.
Яңа тау калка тора...
Иске тау чүгә,
    чүгә, урын бирә, –
Кешеләр,
Тракторлар,
Экскаваторлар,
Тимер тешле машиналар
    тауның сары балчыгын
        гасырлар кичкән чокырга
            төшерә...

Җир гөрселдәп китә –
Зыңлап куя
Шагыйрь күңеле...
Ләкин...
Төшенәм,
Шулай кирәк...
Монда тигезлек кирәк,
    бу – яңа цех утырасы мәйдан!
...Ишетелә колакка
Бер кош моңы –
    әкрен генә,
    әллә кайдан...
Кошчыгым, якыным, җүләрем!
    Юкка үпкәләп йөрмә,
        кайт әйдә.
Яшәр урын күп
    безнең якларда,
        безнең җәйләрдә.

Илермә,
Моңланма,
    их, син, аңла!
        Кечкенәм,
            шулай кирәк.

...Зур тау, иске тау –
Гасырлар кичкән тау
    югала,
        яңалыкка урын бирә.

Тигезләнә
Иске чокыр –
Гасырлар кичкән чокыр,
Зур чокыр тигезләнә;
Өстендә кызлар йөгерә,
    егетләр йөгерә,
Тракторлар йөгерә.
Тормыш бара...
Читтәрәк өч шофер...
Озын рус
    папирос өләшә.
Һәм, бутап колгадай кулларын,

нәрсәдер сөйләнә;
Чандыры,
Казахка охшашлы,
үпкәли нигәдер;
Төп кебек татары
и көлеп кинәнә...
Аннан
өчесе өч машинага утыра,
һәм бик тиз
күренеш алышына:
Үзеннән зур портфелен
тотып кулына, сакаллы
яшь кенә инженер
килә каршыга.

...Шулай,
Эш көне, туганкай!
Бередә кеше,
вакыт,
хәрәкәт –
барысы да ашыга.

Җыр дәвамы – сүзләр

Ял кичеңне синең бүлдем инде,
Сиздермәдең үзең арганың...
Бүген менә хатыныңны алып
«Чулпан»га да керә алмадың.
Син шулай да кичерерсең мине,
Кичерерсең яшьтәш булганга...
Язмышларда безнең охшашлык зур –
Әтиләр бит бергә югалган...
Иргә чыкмаганнар әнкәйләр дә,
Кайтырлар дип һаман көткәннәр.
Көтә торгач, синең белән мин дә –
Уллары да чыгып киткәннәр.
Без «Чулпан»га бүген кермәгәннән
Югалтмадык, ахры, берни дә.
Үзебездән бүген, сүзебездән
Кино чыгар иде бер дигән!
Без үлгәчтен чыгарырлар әле,
Ярый, бусы аның – шаярып...
Теге фикереңә килсәк әгәр,
Мин кушылам аңа шар ярып:
Безнең буын хәзер – җыр башында,
Җир башында, дөнья башында.
Күз тимәсен, кешелекне шулай
Матурлыкка илтә барсыннар.
Матур юлдаш итеп кешелеккә
Без Чаллыны биек күтәрик,
Мәшәкатьле, кыен минутларны
Бергә-бергә җиңел үткәреп...
...Сизелә ич иңгә мондагы йөк,
Чынлап-чынлап баса, нык баса;
Кыен булыр иде янәшәңдә
Алмаз кебек дуслар булмаса.
ГЭСлар төзеп үскән Рудаковлар,
Абдуллалар янда тору – шәп!
Алар белән эш башкарып була,
Бәхәсләшеп була, килешеп.

Ә Рәисләр, Умат Нурбиевлар,
Карпенколар – шундый егетләр!
Партиянең бөек чакыру булып
Яңгыраган сүзе кебекләр...
Синең хезмәтнең дә бар зурлыгын,
Мөһимлеген аның төшенәм...
Син генә дә... сөйлисең генә дә,
Кешеләр бит янда, кешеләр!
Берәүләргә эшең җиңел төсле –
Нидер оештыру торакта...
Чәчрәп чыгып башлаучы да табыла,
Күрсәтүче табыла җырлап та.
Яшь шагыйрьләр ярсып шигырь укый,
Очып-очып бии биюче, –
Барысы да алар күп укыган,
Күп уйлаучы, күпне белүче...
Алардан ким түгел тыңлаучы да.
Сынап карый, аңлап утыра.
Бию дә бит сыгылып уйнау түгел,
Аның мәгънәсендә сүз тора.
Һәр эш аслы җирдә нидер сөйли,
Синең сәхнә эше – синең сүз!
Ничә кеше залда, кемнәр алар –
Залдан сиңа карый синең күз!
Зал йөрәге – хәзер синең йөрәк,
Канәгатьме йөрәк, сөенәме?
Син җаваплы, син уйлыйсың хәзер –
Йөрәгеңә нәрсә сөйләдең?!
Бу зур йөрәк, шундый сәер йөрәк,
Анда күпме милләт тамыры!
Һәр тамырга сүзең көч бирдеме?
Син уйлыйсың җуеп сабырың.
Тоясың син: бу зал гына түгел,
Чаллы мәйданы бу, ил кыры!
Мондагы сүз ул, газорез кебек,
Металларны кисә сызгырып...
Ташны ташка сүз беркетә алыр,
Сүз нур була алыр бүлмәгә.
Кош оясы кебек гаиләне
Туздырадыр сөйли белмәгән.
Сүз куәтен белгән кеше әйтмәс:
Булмас, диеп, сүздән өй корып.
Тарих шаһит:
Сүзләр чыгардылар
Дәүләтләрнең нигезен суырып.
Яңа дәүләтләргә мәйдан булып,
Нигез булып сүзләр яттылар...
Сүзләр көрәшәләр, сүзләр җиңә,
Сүзләр тавыш биреп
Атлыйлар...
Синең хезмәтне мин яхшы аңлыйм,
Сынатмаска безгә ничек тә!
Без елмайсак – дөнья күреп тора,
Ютәлләсәк – дөнья ишетә.

Җыр дәвамы – ныклык

Бу дөньяда
Ныклык кирәк,
Тагы ныклык,

Кабат ныклык!

Безгә – утыз,
Безгә – кырык,
Бар да яңа...
Һай, дөньяда!

Бу дөньяда
Кеше яңа,
Учак яңа,
Утын яңа.

Утын яна,
Учак яна,
Кеше яна,
Һай, дөньяда!

Бу дөньяда
Эшең яңа,
Көнең яңа,
Вакыт яңа.

Вакыт яна,
Көнең яна,
Эшең яна,
Һай, дөньяда!

Бу дөньяда
Буын яңа,
Тизлек яңа,
Юллар яңа.

Ныклык кирәк
Эшеңә,
Үзеңә...
Сүзеңә – ныклык!
Һай, дөньяда!

Җыр дәвамы – туйлар

Машиналар, машиналар, машиналар
Илнең барлык почмагыннан бире җыела.
Яңа завод эшен күреп сокланырга
Кама җыена, Идел җыена, Ил җыена.
...Бер вакыйга
 әйтерсең мең тау артында,
Һәм биредә сөйләргә дә аны бик соң:
Беренче кат каерып туфрак алган иде
КамАЗ калкыр җирдән Носков машинасы.
...Юк, соң түгел...
Батырлыкны сөйләү кирәк,
Тик сүземне зур хәрәкәт бүлә тора:
Кырыс йөзләр, елмаюлар, шаян сүзләр;
Бертуктаусыз машиналар гүләп тора!
Машиналар, машиналар, машиналар
Балчык этә, балчык ала... бетон ясый.
Ә бер өйдә ял сәгате – туй сәгате:
Яңа парны биетеп, яңа гармун ярсый.
Эх, Никола!
Ничек баса!
Оста баса!

Маринасы
Идәннәрне өзәр бугай!
Өстәлләрдә стаканнар һәм чәчәкләр
Биемичә көчкә-көчкә түзә бугай...
Бораулыйлар, бораулыйлар машиналар,
Машиналар субай суга, субай куя...
Калын нигез, авыр цехлар күтәрелә:
Кемдер – авыр, кемдер җиңел сулап куя.
Ә бер өйдә ял сәгате – туй сәгате:
Насыйх белән Мәдинәгә текәлгәннәр.
Аккош кебек Мәдинәкәй каушаган да
«Ачы» тәмен аералмый баллы тәмнән.
Тракторлар, тракторлар...
Бульдозерлар...
Ярдәм килә... Чиләбедән... йә Ташкенттан.
Волгоградтан, Куйбышевтан...
Сахалиннан...
Эшкә алу бүлмәсеннән чират чыккан.

Ярдәм килә –
Дулкын-дулкын самосваллар...
Грейдерлар...
Бетон изү машинасы...

Ә бер өйдә ял вакыты – туй вакыты:
Кияү кеше – дагстанлы сөйли басып.
Сүздә ялгыш җибәрсә дә, уе төпле;
Басымнарны ялгыш куя, ләкин сөйли.
Ялгышларга елмая да Валя, эчтән,
Тик туебыз ялгыш була күрмәсен, ди.
Машиналар, машиналар, машиналар
Илнең барлык почмагыннан бире җыела.
Җыелуның кайтавазын тиз күрергә
Кама җыена, Идел җыена, Ил җыена.
...Һәм кайтаваз
Гигант КамАЗ
Капкасыннан
Күрелмәгән тимер ташкын булып китәр.
Шул ташкында кырлар аша, таулар аша
«Чаллы» сүзе, «Татарстан» сүзе үтәр.

Җыр ахыры
Минем буын
Таңнар тыныч тусын өчен яши...
Чаллы – җимерелмәскә салына!
Кичер, кешелек,
Синдә җимерүче барын күреп,
минем буын
яңа солдатлар әзерли
Яңа Чаллы сагына.

– Бер, ике, өч!
Бер, ике, өч!
Ил чикләрен,
ил байлыгын
барлап
Яшь кенә якташларым
бара...

Якташларым баса

        ракеталар янына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Якташларым керә
        көчле танкларына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Якташларым чума
        диңгезләр кочагына.
...Чаллы – җимерелмәскә салына!
Якташларым...
...Әнә
Кара мишень
Сыңар күзе белән
        ерактан
                чекерәеп карый,
Ике кара күз
Мишеньгә төбәлгән;
Чакма тавышы
        һәм пуля
                эләгә «10» санына.
Афәрин, егетләр!
Димәк, Чаллы –
Җимерелмәскә салына!
Яшәгез, егетләр!
Өйрәнегез!
Беркөнне без
Шәһәрләребезне
        бөтен матурлыклары,
                бөтен мәшәкатьләре белән
                        калдырырбыз сезгә генә.
Шуны сизеп
Җимерүче килсә,
        беренче пулягыз
                эләгерлек булсын йөрәгенә!
Өйрәнегез,
Кадерлеләрем!
Киләчәкнең күп өлеше
        өйрәнүдә хәл ителә,
                бүген хәл ителә –
                        шушында, хәзер!
...Ә мин –
Гел матурлык эзләп
        дөньяга караучы –
                яшел күзләремне
                        мишень итеп
                                куярга әзер.
Бары сез
Дошманнан тиз һәм төз
            була белегез,
Сезнең йөрәкләрне
            пуля тишмәсен,
Ил табынына бомба төшмәсен,
Өзелмәсен матур эшләр;
Сау булсын
Калалар,
КамАЗлар,
Шат җырлар,
Түгәрәк Җир,
    чәчәкләр һәм кешеләр!

*1971–1972*

## ИКЕ АВЫЛ АРАСЫ

### I

Күк астында авыл тора –
бер урамлы, төзек кенә:
үзәнлеккә ялга кунган
кош төркеме кебек кенә.
Бер урамы– бер кыл гына,
бөтен көйне уйный үзе...
Чиртә, суга еллар кылга,
юк, өзелми– әле түзә,
әле уйный... Кызыл колын
кешнәп куйды кыл өстендә:
яңа чыккан кояш булды –
тавышы таулар җилкәсендә.
Үзгәрешләр күп булса да,
шул ук тормыш күк астында.
Яшисе бар, күрәсе бар,
бирәсе бар, аласы бар...
Төрле холык, төрле халык,
һәммәбезгә шатлык кирәк.
Шаян шатлык чакыра, көлә,
посып тора, юлдан йөгерә.
Авыл карты атын җиккән,
кай арада өлгергәндер.
Җилкән булсын, бабай, дугаң!
Карт чөңгереп җибәрә бер!
...Таныш пәрдәләр артында
Кызлар чәчен үреп кала...
Хәтта чикләр, дәүләтләрне
акыл күзе күреп бара:
якалашкан илләр күрә,
якынлашкан илләр күренә.
Менеп бара авыл карты
гомеренең соңгы үренә.
Үрне менгәч югалыр ул,
борынгыдан шулай инде.
Борынгыдан мирас Җиргә
һаман яңа кеше килде.
Җирдә үскән җиләк сыман
туды кеше, туды кеше.
...Үсте кеше.
Кыйтгаларга
төркем-төркем тулды кеше.
Җирне бүлде,
суны бүлде,
күкне кисә телем-телем.
Тимер куәт алды кеше,
эшли кулы, эшли теле.
Эшли кеше.
Авыл карты
кагып куйды дилбегәсен.
Һәм чайкалды хәтерендә
бер арбалык гаиләсе:
олы улы, уртанчысы,
кече малай, төпчек кызы.
...Хатынының чардуганы
миләшлектә калды посып.
...Ике улы яуда үлде,

үзе исән, һай, бу гомер!
Төпчегенең кызы үсә,
йөгереп бүген каршы килер.
Тамак кырып алды бабай,
соңгы үрен күтәрелә.
Үрнең өсте якын да бит,
кимеп бара җегәр менә.
Югарыда җегәрлеләр
күкне кисә телем-телем.
Тимер куәт алды кеше,
эшли кулы, эшли теле.

II

Батыр эшли, куркак эшли...
Дөрес эшме, ялгыш эшме? –
Күрә кеше, уйлый кеше,
яза кеше, уйлый кеше...
...Суктылар –
егылды кеше –
әллә барга, әллә юкка?
...Аттылар –
коелды кошлар,
җилфердәшеп
кулъяулыктай.
...Кистеләр –
егылды урман,
өнсез калып, тузып ята.
...Тимер куәт кырлар аша
кара чокыр сузып ята,
ак көннәргә каберме бу?
Хәтта кояш кысылып куя.
Ә чокырдан тарих чыга,
җилкәсеннән балчык коела,
таш коела,
ватык-сынык
сөяк коела,
ком коела.
Еллар коела,
елтыр-елтыр
чорлар коела,
алтын коела.
Коела бирсен –
миңа нәрсә?!
Һәм бабайга нигә алтын?
Алтын – аның дилбегәсе,
алтын – аның җиккән аты.
Менеп барган үре – алтын,
юлы алтын арасында...
Сары алтын – сагышлары,
борчулары – сары сыман,
һәм кызара бара сыман,
кыза, монарлана сыман,
күгең каплап янар сыман.
...Иран нишләр?
Кытай даулы...
Кайчан тынар бу дөньялар?
...Кызы якын булу яхшы,
бик ерак шул кече малай.

Карт күрмәгән бәхет булып
малайның да улы үсә.
Җегәр житсә, барыр иде,
китәр иде– арба түзсә.
Җилкән булсын, бабай, дугаң!
Кызыңача арбаң түзәр.
Аннан ары... таныш хәлләр:
сулар ага...
яфрак йөзә...
Кер чайкыйлар.
...Иске эзне
яңа юллар ямап бара.
Сикерә куян. Болан уза.
Ватыла заман арбалары.
...Муллык өчен дога булып
эленә салават күпере.
...Басып тора буш чиркәүләр,
җирдә ята шәүләләре.
...Михрабында җил йөргәнне
буш мәчетләр сизеп тора...
Борынгылар ял итәләр,
бүгенгеләр тормыш кора:
фикер йөртә, исбат итә.
Талантлылар, даһилар бар.
...Колбага кайгысын салып,
бәхет ясый акыллылар.
...Тиленәр
йөри шаулашып
бер якында, бер еракта.
Сүгәләр алар вакытны
йодрык селкеп,
туктап-туктап.
Вакыт – мәшгуль,
аңлый алмый,
сүгенүләрне тыңлый алмый.
Көчле вакыт гомерләрне
Дахауларга кертеп ялгый.
Карт аларны күреп кайтты,
яныл кайтты – исән калды.
Илтә вакыт – түзәр булсаң,
йолдызларга
гомереңилтә.
...Тимер куәт су йөрәген
Җиңел генә ярып үтә.
...Яр буенда авыл карты
чәчәк карый тып-тын гына.
Үрелергә кыймый тора
ак шомыртлар толымына.
Бер тармагы ялгыз сыман,
алсын мәллә шуны гына?
Шуны гына алсын микән
кызына һәм оныгына?
Бер-бер киңәш көткән сыман,
күтәрелеп карый күккә...
Әй, бабакай! Киңәшчеләр
Күк астында яши күптән.

III

Күк астында

шомырт үсә,
яхшы теләк
бөреләнә.
Күк астында шыбыр-шыбыр
яңгыр ява
бөреләргә.
...Күк астында
кош оясы,
оясында –
йомыркасы:
Җиргә охшаш,
түгәрәк тә...
Бер карасаң,
үзгәрәк тә,
биш карасаң,
ун карасаң,
мең карасаң –
ни диярсең?
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күк астында семафорлар:
әле кызыл,
әле яшел.
...Такси чаба,
атлы чаба.
Поезд чаба
максатына.
Киштәләргә
ипи тула.
Банкларга
акча тула.
...Ит сатыла,
сөт сатыла.
Ир сатыла,
ил сатыла.
Төяп-төяп
кеше ялга,
төрмәгә дә
озатыла...
Тимер куәт күрше илнең
күзен ала, йөзен ерта:
бакчаларын, балаларын,
шәһәрләрен
кабып йота.
Туфрак кала.
Яңа язда
чирәм чыга,
йортлар арта.
Яңа йортта яңа тормыш
кабынып китә –
утлар арта.
...Чаллы балкый,
яңгырый БАМ.
...БМО эше гүләп тора.
Төтен чыга сигареттан,
һәр кыйтгага исе тоела.
Төтен чыга сигареттан,
йөзә кушылып сүз һәм төтен.
Милләт хәлен күтәрәләр
хәл кылырдан зуррак итеп.
...Яр буенда авыл карты

чәчәк карый тып-тын гына.
Үрелергә кыймый тора
ак шомыртлар толымына.
Бер тармагы ялгыз сыман,
өзсен мәллә шуны гына?
Шуны гына алсын әйдә
кызына һәм оныгына...
...Төтен чыга сигареттан,
йөзә кушылып сүз һәм төтен.
Илләр хәлен сөйләшәләр.
Мәгълүматлы хәзер һәркем.

IV

Ил башлары сөйләшәләр.
Зур эшләрен дөнья күрә.
Дөнья – картта,
карт – дөньяда,
ул да эшли, ул да күрә,
мин дә күрәм...
...Батыр эшли, куркак эшли.
Кычкыралар
эшкә өндәп:
«Коткарырга!»,
«Үтерергә!»,
«Катырак бу!»
Тагы өндәү...
...Үбешәләр.
Җир әйләнә.
Сулгып-сулгып
елый кемдер.
Йөзен каплап гасырларга,
ничә гасыр
елый кемдер:
бәлки, ул – үлемсез карчык,
кешелекнең әнкәседер?!
Карт шуларны уйлый әле,
онытып атын, дилбегәсен.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Исәнләшеп аның белән
калды казлар гаиләсе.
Чишмә тавышын тыңлап калды
сабын кебек сары бура.
Коймак тәме йөзеп чыкты
яңа авыл урамына.
Көтәләрдер, өйдәләрдер –
карт киләсен сизгәннәрдер.
Кыз якын да...
Кече малай
никтер сирәк яза хәзер.
...Гәзитләрдә төрле хәлләр,
телдә йөри төрле хәбәр.
Җилкән икән, бабай, дугаң,
атың – дугаңа бәрабәр!
Төшә бабай арбасыннан,
кызы суга чыгып килә.
Койрык болгап көчек килә,
аваз салып онык килә:
«Бабай килгән!»
...Әйе, килгән

ун чакрым ара юлдан.
Оныгына бирер өчен
чәчәге дә юк кулында.
Бу хәл аңа бик кыен да,
бик кыен да түгел бугай.
Кызы – исән, авыл– яшел,
бакчаларга чәчәк тулган.
Чү, арбада байлык бар ич,
төенчеге хәтта җылы:
җылы, эре бәрәңгеләр –
куян күчтәнәче булыр.
Һәм күтәрә карт оныгын,
оныгы ла үскән ничек!
Йортка, Җиргә хуҗа сыман
өрә алтын-сары көчек.

*1979*

## ИРТӘГӘ...

### I

Нидер кала дөнья тизлегеннән,
Кырга яфрак кебек ягылып,
Канатсыз кош булып
Утырып кала,
Ятып кала
Башсыз яу булып...
Кала соңгы тапкыр үрә баскан,
Ак күбеккә баткан ат булып...
Дусың булып кала кулын болгап,
Кала арттан аткан ят булып.
...Ниләр кала шулай, кемнәр кала?
Көйләр кала микән, илләрме?
Мөмкин түгел җиңел генә бару
Дөнья тизлегенә ияреп.
Бүген алган тизлек бүген ярый, –
Яңа тизлек кирәк иртәгә.
Гел үзгәреп очкан дөнья белән
Әй китәргә ерак! Китәргә!
Бүләгем бар ерак ул көннәргә,
Илтә барам Тукай якларын.
Бәрхет түшле яшел тауларымның
Язмышлары бездә чакларын.
Борынгыдан килгән кырлар монда,
Шәһәрләре исән килмәгән.
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән...
Читекләре килгән Идел белән,
Кешеләре тузып килгәннәр.
Җайдагы юк атлар йөзеп килгән,
Агып килгән атсыз иярләр.
Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер, димәк, белмәгән.
...Борынгыдан килгән кырларында
Шәплекләре исән килмәгән.
Җир астында килгән
Җиз комганнар,
Алкаларның алтын – затлысы;
Хәрабәләр арасына посып
Поэмасы килгән, эпосы...

Күпне белгән безнең борынгылар
Нәрсәнедер барыбер белмәгән.
Борынгыдан килгән кырларында
Шөһрәтләре исән килмәгән.
Алар янган борынгы йорт белән, –
Тукай ягы бетеп янмаган...
Борынгыдан килгән кырларында
Без яшәргә булдык яңадан!
Юкса безгә Рәсәй патшалары
Урын бүлгән музей түреннән...
Унҗиденче елда
Китеп бардык
Музееның ишеге төбеннән;
Көлдек шунда карап бер-беребезгә:
– Үзебез дә кызык икәнбез...
– Килеш-килбәтебез музей өчен, –
Тәмам әзерләнеп җиткәнбез...
– Киемебез, хәтта биюебез,
Җырларыбыз – музейныкылар...
– Юк, музейга безгә иртә булыр!
– Йә, сезнеңчә ничек, сынчылар?
– Ә рәссамнар безнең нәрсә диләр?
– Музейларга рәсем, сын кирәк!
– Музейларга үле корал кирәк!
– Без бит әле тере төслерәк!
– Юк, музейга безгә иртә булыр!
Без яшәргә булдык яңадан...
Гел үзгәреп алга дөнья оча,
Без калмаска булдык аңардан.
Оча дөнья алга гел үзгәреп,
Илтә барам Тукай якларын:
Аэропортлар, юллар,
Байракларның
Язмышлары бездә чакларын.
Иксез-чиксез әрәмәләр илтәм,
Эче тулы шомырт, бал исе.
Шомырт чәчәкләре ап-ак дәрья,
Ак дәрьяда хыял көймәсе.
Йөзә һаман, йөзә сары көймә,
Малай-шалай карый кызыгып.
Аннан йөгерә алар егетлеккә,
Акбай чаба арттан сузылып...
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кызлар җитә монда, җыйнаклана,
Күз алдында бераз суырылып.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Монда җылы сөю җиле исә,
Көннәр исә рәхәт җил булып.
Үсә монда каен һәм бозаулар,
Үсә фикер, үлән һәм тайлар...
Башын чайкап, бөгелеп, биеп кенә
Үсә кырда безнең бодайлар.
Ялган юллар, яулар авызына
Без бирмәскә тиеш аларны.
...Явызлык та алдым үзем белән,
Җиңәр өчен явыз җаннарны, –
Күңеле гаҗәп яхшы кешеләр дә
Көтмәгәндә каза күргәннәр.
Серләрем бар әле,
Киңәшем бар

Кабынасы яңа көннәргә...
Ни икәнен беләм юлларның да,
Озын юлда буш кул кем йөрсен?!
...Уенчыклар алдым оныкларга,
Уенчыклар алдым,
Төрлесен...
Сыбызгылар...
Битлек...
Курчак алдым...
Бәлки, күп тә китә алмамын:
Янәшәмдә яхшы дусларым бар,
Юлда калмас кебек алганым.

II

Юл өстендә, кыр өстендә
Сайрый тургай биектә.
Ничек болай сайрый тургай,
Борчак кына кебек лә?!
Сайрый тургай, өзә тургай,
Каян алган шундый көй?
Эче тулы шатлык кына,
Шатлык кына микәнни?!
Җирдә тургай бәхет кенә,
Бәхет кенә күргәнме?
Бәхетле кыяфәтенә
Әллә юри кергәнме?!
Әллә болай кирәкмиме,
Әллә шулай кирәкме?
Күтәрә бит, күтәрә бит,
Күтәрә бит йөрәкне!
. . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Көе белән коендыра,
Яңарта бит, юа бит...
Якынайта өметләрне,
Борчуларны буа бит!
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кыр өстендә, чор өстендә –
Кыл өстендә бугай ла.
Җыр ягына көн тартыла,
Гөл тартыла тургайга.
Көй артыннан тал сузыла,
Үлән күккә үрелә.
Таш, үрелеп көйгә таба,
Йортларга әверелә...
Кынысында кылычы бар
Ир тартыла тургайга.
Тартылмаска уйлап торган
Ил тартыла тургайга.
Уйламагыз тартылмый дип,
Җир тартыла тургайга.
Чор өстендә, кыл өстендә
Ни хикмәте бар аның?
Уйный тургай,
Сайрый тургай –
Безнең белән барадыр.
Әллә соң ул бер-бер серле,
Җанлы рәсем икәнме?
Киң кырларны ул үзенә
Сихри канат иткәнме?

Әллә үзе киң кырларга
Сихри канат булганмы?
Чор өстендә, кыл өстендә –
Хикмәте бар тургайның.
Әллә тургай түгелме ул,
Ул очар шигырь микән?
Ник булмасын?
Тургай– шигырь,
Канаты булган икән.
...Килә-килә,
Тургай көнне
Тутырып ала бугай.
Сайрый-сайрый китә тургай,
Ядрәгә кала бугай...
Кабат сайрап килә тургай,
Ядрә түгел,
Бу тургай!..
...Дөньяга
Эндәшә шулай,
Яшәргә
Чакыра шулай,
Биеккә
Дәшә шулай.
Кыл өстендә, чор өстендә
Үз урыны тургайның.
Бу чорны канатсыз кичеп
Булмыйдыр ул, мөгаен.
Чор юлында –
Татарстан,
Чор юлында –
Чал Идел...
Канат булса безнең хезмәт,
Безнең сәнгать, безнең тел,
Канатлыдыр Татарстан,
Һәм канатлыдыр Идел.

III

Бу дөньяда үз ягымның
Чын кыйммәтен беләм мин.
Шагыйранә сөйләп аны
Арттырырга теләмим.
Шаярмыйм мин чынлык белән,
Ялган белән уйнамыйм.
Татарстан, Идел, диеп
Мактанырга уйламыйм.
Идел икән Идел инде! –
Җанга якын, туган бит.
Бабайларның канлы йөзен
Юган чагы булган бит.
Идел икән Идел инде! –
Яратыйк та кадерлик.
Әмма моннан зур суларның
Җирдә барын кем белми?!
Тормышка Татарстанмы
Иң кирәкле, иң матур?
Кай шәһәрдән Казан артык,
Кешеләре кемнән зур?
Зур булсалар,
Андый зурлар

Бездә генәме алар?
Бездә генәме яшь алмаш –
Үсеп килгән алыплар?
Үсеп киләдер алыплар!
Безнең бит Сәйдәш тә бар!
Үсеп киләдер алыплар!
Безнең бит Мулланур бар!
Аксакаллар булган икән,
Алмаш булырга тиеш!
Без ничек язмыйк ди икән,
Кол Гали язган килеш.
«Безнең халыкның үткәне,
Зур юлы булган», имеш.
Халкы булгач,
Аның инде
Юлы булырга тиеш!
«Тарихи истәлекләре,
Сөембикә манарасы,
Мәрҗани мәчете...» имеш.
...Истәлек океан булыр,
Истәлек булыр инеш...
Истәлекләр булыр алар,
Күргән дә бар аларны.
Хөрмәтлик истәлекләрне,
Хөрмәтлик бабайларны.
Һәм узганга салават та,
Шуны да уйлау кирәк:
Чыгышы бөркет икәннең
Очышы ничегерәк?
Ачышларда-очышларда
Бүген хәбәр өр-яңа!
Суны кысып, металл итә
Сәхнәсендә замана.
Тезләнеп сәҗдә кылсаң да
Болгарларың ягына.
Ир дигәннең – бүгене ир,
Узганы малай гына.

IV

Без очышта, без очышта,
Мин моны тоеп барам;
Мин тумыштан дорфарактыр,
Сөйләшәмдер дорфарак.
Тик очышта, без очышта,
Гел шуңа сөенеп барам.
Җәлилләр алган алкышның
Җилләрен сизеп барам...
«Китмибез»не «Төшмибез» дип
Әйтәсеңмени аны?!
Шаяртып, әнә «Шүрәле»
Кытыклады дөньяны...
Сабалардан, Арчалардан
Чәчрәп чыккан егетләр –
Кирәк җиргә барып явар
Җылы яңгыр кебекләр.
Кара күзле кызларыбыз
Ак шәһәрләр өстендә –
«Кама»ларны, КамАЗларны
Тартып-тартып үстерә.
Әлмәтләрдә, Төмәннәрдә,

Томаннарда торбалар –
Татарстан куәтенең
Киңәйгәнен тоялар.
Без очышта, без очышта,
Әй Җәлил егетләре!
Тизлекне үзгәртәбезме?
Егәрлек бармы әле?
Ярсудыр сезнең күңел дә,
Минем дә ярсу күңел.
Елмаеп сорау бирсәм дә,
Шаярып сорау түгел.
Шаярыр заман түгел бу,
Очмасаң, туктау кирәк –
Инде күккә күтәрелмәс
Самолетлар төслерәк.
Озак уйлар заман түгел,
Очсаң очарга кирәк –
Шәүләсе дә җирдән купкан
Ракеталар төслерәк.
Күзендә күкнең очарга,
Дөньядан гыйбрәт алып.
Очарга янып-янып та,
Очарга – исән калып!
Хәерле юл тели Ватан,
Алда нинди зәңгәрлек!
Халкыңны, оча алмаса,
Ник туган, дип җәлләрлек.
Ярсудыр синең күңел дә,
Минем дә ярсу күңел.
Елмаеп сорау бирсәм дә,
Шаярып сорау түгел.
Тизлекне үзгәртәбезме,
Татарстан, бергенәм?
Улың булып, хуҗаң булып
Киңәшәм синең белән...
Аңлар мине синең киңлек,
Анда бар да минеке:
Төлкеләр дә, куяннар да,
Боланнар да минеке.
Суыңда балык чиртүе,
Камышы да минеке.
Торналарың, бүреләрең
Тавышы да минеке.
Яккан учак, пешкән шулпа,
Аксыл пары – минеке.
...Малайлары, әнкәләре
Һәм кызлары минеке.
Шаулы Казан минеке ул,
Юкәләр дә минеке.
Синеке түгел, дисәләр?
Дисәләр дә, минеке!
Урам саен мәрмәр такта,
Алары да минеке.
Кичләре дә, төннәре дә,
Таңнары да минеке.
Зур тәрәзләр, киң мәйданнар
Һәм гөлләр дә минеке...
Гөл куяр кешесе беткән
Каберләр дә минеке!
Мин аларга шигырь куям,

Куярлык шигырь микән?
Безнең шәплек, яшәү табышы
Шуннан ишетелер микән?
Мин аларга шигырь куям,
Җыр куегыз, җырчылар!
Кайсыгызда сан бирерлек,
Сан алырлык тавыш бар?
Кайсыгызның дөнья тавышы
Саналырлык табышы бар?

V

Син башласаң,
Без дә кушыласы –
Әйдә килешеп алыйк, булмаса!
Чыдарбызмы, әгәр синең җырың
Ил өстенә җәелеп еласа?
Чыдарбызмы? Никтер безнең халык
Әллә нинди җырлар чыгарган;
Зур Җир шары төшеп тирбәлерлек,
Кайгы диңгезедәй җырлар бар.
Чыдарбызмы? Болай чыдам да без,
Ә барыбер күпме еланган?!
Син җырлама инде авыр көйләр,
Мин теләмим хәзер еларга.
Син җырлама бүген авыр көйләр,
Күңелләрне генә йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Юлда һәркем күңеле йомшак түгел,
Алга бара ләкин барысы да.
Күренәләр генә тыныч сыман,
Бөтен кеше җирдә ярсыган.
Алышалар күпләр, бүлешәләр,
Көчлерәге тарта күбрәген –
Бармакларын гына карасаң да,
Тишкәләнә йомшак йөрәгең.
Юлда әле бәхет эзләүчеләр,
Бәхетеннән шашкан кешеләр бар.
...Чишеләсе бәхәсләр бар юлда,
Үтерешкә җиткән эшләр бар.
Без барабыз тыныч тормыш яклап,
Дошман бара җыелып-серләшеп.
Йөкле ана уза киләчәккә,
Һәм танклар уза гөрләшеп...
Юк, җырлама моңлы озын көйләр,
Күңелләрне артык йомшата.
Алда әле йомшак күңел белән
Узып булмый торган юл ята.
Син шуларны җырла, борылышларны,
Дәүләтләрнең убылып беткәнен.
Упкыннардан кеше калыкканын,
Яшәү һаман җиңеп үткәнен.
Үзебезне җырла, гыйшкыбызны,
Чоры өчен без дә Таһирлар.
Эш күбрәктер бугай, вакыты шулай,
Ләкин азмы бездә шатлык бар?!
Мәңге яңа дигән шәп җырлар да
Искерәдер бераз, мөгаен, –
Җырладык ла инде андыйларны

Юл читендә оеп, моңаеп...
Ә бүгенгә безгә инде күбрәк
Лазер җыры кирәк, ут җыры!
Кыенлыклар моны сорый бездән,
Тизлек моны сорый, юл сорый.
Исән илтик юлда Кеше йортын,
Шатлык белән тулы йорт ясап.
Тукай ягын илтик, шәһәрләрен
Һәм шөһрәтен илтик исән-сау.
Ерак китик әле дөнья белән,
Чын бәйрәмнәр булыр шуннан соң.
Ул чакларда гөнаһ булмас йомшау,
Һәм җырларсың безгә...
Җырларсың...

VI

Нидер кала дөнья тизлегеннән,
Кабат килер сыман яз булып;
Төркем-төркем кошлар сыман кала,
Канатлары кала язылып:
Кала тыныч кына, кайчан да бер
Адресатка җитәр хат сыман;
Калмас өчен кузгалырга кала,
Кешнәп үрә баскан ат сыман.
Гел үзгәреп дөнья алга оча,
Ярты керә канлы таңнарга...
Оча дөнья алга гел үзгәреп,
Без калмаска булдык аңардан.

*1975*

ЭЧТӘЛЕК

Шигырьләр
Җиргә бер сүз
Яна-яна киткән торналар... ..........................
Бакчасарай .................................
Карадык ла килеп дөньяга ..........................
Кай тарафтан, кем нәселе бу җаннар? ...................
Русия киңлегендә ...............................
Татар түбәтәе ник кара төстә, яки Ходай язса... .............
Идарә чылбыры ................................
Алдагы сайлаулардан соң ..........................
Гариза ....................................
Ураза елы ..................................
Күпләр соравына бер җавап ........................
Чиксезлек һәм көзге чебен турында .....................
Табут хәтле алтын! ..............................
Әй, шаян тормыш... ..............................
Гаярь татар .................................
Узар юлың... .................................
Кылыч йөзе буйлап .............................
Нишлибез? ..................................
Кичер, Аллам! ................................
Бәлки, алгы ярга җитәрбез... .........................
Ак капкада кара шәүлә ...........................
Кем кулларына калдырыйм? .........................
Ул еллар... ..................................
Көн килде ..................................
Карап тора... ................................
Кара ат кебек бу төнне... ...........................
Еракта́гы зәңгәр офыгым бул ........................
Өч урын ...................................
Ялгыш яраттым ................................
Уйнабрак уйлану ...............................
Төшеп югалма икән .............................
Кичке бакчада ................................
Ходай сиңа күп биргән ............................
Тентү, яки бердәнбер җәй ..........................
Яратуга хәтле ................................
Яратам әллә ничек... .............................
Елмай әле бер генә ..............................
Күбәләк аланнары ..............................
Ялгызлар моңы ................................
Кызыл чәчәк .................................
Тыныч төн ..................................
Чәчәк тулы бал икән .............................
Шәт... ....................................
Онытылып бара идең .............................
Болай түгел идем дә бит... ..........................
Гомер язында ................................
Бану әби, туганай ..............................
Үтәли җил ..................................
Өнnәрем һәм төшләрем ...........................
Син акыллы .................................
Сары көз ...................................
Китәселәр... .................................
Нәрсә гаҗәп? ................................
Язгы Тукай янында ..............................
Коегыздан су алдык .............................
Сеңелләр ...................................
Ә хәзер без акыллылар ...........................
Гел ......................................
Быелгы кыш .................................
Нарасый ...................................
Кояшлы язда .................................
Алмалык ...................................
Сабырлык алам хәзер ............................
Әгәр берәү әйтсә ..............................

Үпкәләрмен кебек ................................
Сөйләргә дә хурланам .............................
Гел кабатлыйм шулай ..............................
Әллә шулай була микән? ...........................
Әйләнеп кайтуың бар .............................
Чакыр аны... ..................................
Гадәтемдә – кышкы давылың .........................
«Күр яшисе елларымны...» ...........................
Без игезләр түгел ...............................
Бер танышлык турында .............................
Кыш түренә ут ягып... .............................
Урманымда йөрим ...............................
Барган чакта .................................
Җитәрләр... ..................................
Бу кич сәер күренә ...............................
Авыл малаеның монологы ...........................
Өмет ......................................
Кайтырмын ...................................
Яздым .....................................
Хат яз, дускай, Теләчегә ...........................
Урманнарга йомшак сукмак кирә .......................
«Ишеттем...» .................................
Җиде бабай .................................
Үлән бүтән, яфрак бүтән ...........................
Мин Идел кешесе ..............................
Мәктәпкә кайткач ..............................
Дөнья каршысында ..............................
Кавказда ...................................
Иделдә ....................................
Кышкы рейс ..................................
Бульдозер ...................................
«Ак кар ява...» .................................
Кимсенмәм, һич боекмам ...........................
Булмый торган хәл ..............................
Юатма инде мине ...............................
Безне ватып ага вакыт ............................
Җәйне көттем .................................
Йөгереп китсәм... ...............................
Елаучылар ...................................
Без җырлаган көйләр .............................
Хәзер ......................................
Атланабыз атларга ..............................
Туган-үскән якларда .............................
Уздылар ....................................
Бәхет кирәк бездән соң да ..........................
Шигырь генә... .................................
Җизле йөгән, җирән атың... .........................
Чарасыз ....................................
Горур бәхетем ................................
Сорыйлар ...................................
Үзебезне чыгарганбыз истән дә .......................
Түгәрәк күл генә... ..............................
Шигъри сагыш .................................
Әйтерсең лә... .................................
Иртә ......................................
Мин күрмәгән ике якташ ...........................
Эш башы ....................................
Якташлар янынннан... .............................
Еракларда... .................................
Минем яшьлек .................................
Нәкъ унбиш ел үткәч... ............................
Кулым ныгысын әле, ныгысын .........................
Күтәрелде Чүрәкәй ..............................
Нурсибә әби өйдәдер ............................
Яңа ел төне Казанда ............................
Әнкәй, әнкәй... ................................
Каеннарны үтеп өскә мендек ........................
Кышкы суыкларга кердек исә... .......................

Сәбәп .....................................
Табыш .....................................
Җаным чаңы ..................................
Әнкәйне хәтерләү ..............................
Сагыну .....................................
Күктә сары ай йөзә ..............................
Шунда сине күрмим бит һаман... ......................
Серле дустыма ................................
Асия апага ...................................
Сорама, Камышлы ..............................
Хәсән Сарьянга ................................
Йөреп чыгыйк әле Казанны .........................
Каләмдәшем Рәдиф Гаташны озаграк күрми торганда туган уй ......
Илдар Юзеевка ................................
Равил Фәйзуллинга ..............................
Илһам Шакировка ..............................
Гәрәй Рәхимгә .................................
Клара Булатовага ..............................
Диләрә Тумашевага .............................
Вафирә Гыйззәтуллинага ...........................
Лена Шагыйрьҗанга .............................
Син сагышлы, шуңа каләмдәш .......................
Безнең күрешүләр күп булмады .......................
Мәгъсүм Хуҗин – мәгълүм Хуҗин ......................
Ризван Хәмидкә ................................
Батуллага ...................................
Әхмәт Рәшиткә ................................
Фарсель Зыятдиновка ............................
Альберт Хәсәновка ..............................
Шәрә чәркә .................................
Язучы Гәрәй Рәхимгә .............................
Палатадашларга ...............................
Танышыма ...................................
Энем Исламнурга ..............................
Зәңгәр ишек .................................
Соңгы мәсьәлә ................................
Аяк киемнәре төзәтүче дустыма .......................
Туган як кырларына ..............................
Читтә яшәп калган якташларыма ......................
Авылдашка хат ................................
Гөл күзләре мөлдерәмә ...........................
Тумый калган балага .............................
Гел шулай гына тоелды ............................
Бала эзе ...................................
Туган як елгасын хәтерләү ..........................
Тау астында гади су ..............................
Синең базар .................................
Шат бала... .................................
Ике такта – бер басма ...........................
Безнең Герой ................................
Иллә мәгәр... ................................
Булма ....................................
Бу елларда... ................................
Сүзләрең гел истә торды ...........................
Тормыш чаба .................................
Ут кебек дуслар ................................
Томаннарга таба илтteләр ..........................
Ак болытлар үтте ..............................
Военкоматта .................................
Бардыр ....................................
Сабыйлар көлә ................................
Күпме илләр... ................................
Күңелемдә менә шундый шатлык бар ....................
Кайвакытта .................................
Шигырь дәфтәремне актарсагыз ......................
Җинаять ...................................
Очрашу ...................................
Ленинградка .................................

Төн дисездер .................................
Күперләр ....................................
Йөз елдан соң туар туганнарга ........................
Җиңүче чәчәк .................................
Кешелек белән сөйләшү ............................
Бәхетем ....................................
Миңа акыл гел соңлабрак килгән .......................
Бу көн миңа шундый тыныч килде .......................
Кешелек өлгергән чакта... ...........................
Бозлар китә... .................................
Җиргә бер сүз .................................
Януларым, көюләрем... .............................
Кинәт . .....................................
Сигезенче март уңае белән ..........................
Бары вакыт-вакыт... ..............................
Шигырьләрем белән сөйләшү .........................
Базарда ....................................
Ачлык җыры ..................................
Кеше гомере ..................................
Гомер түбәсенә менү .............................
Узганым белән яшим .............................
«Кайчак шулай күзләремне йомам» .....................
Шулай кирәк ..................................
Багучы булган икән ..............................
Кәбисә ел мәрхәмәтсез, имеш .........................
Юк, бу эшләп ару түгел ............................
Гомер артык тиз уза .............................
Тege якка узам әле ..............................
Элек һәм хәзер ................................
Шат яшәүнең сере бардыр ..........................
Күтәрик бер газлы су .............................
Әнкәм җырлый белгән озын көй .......................
Күрәсебез бар икән .............................
Кигән идең яшел күлмәгеңне .........................
Өч Закир һәм аларның өч малае турында хикәят .............
Серле чемодан ................................
Өмет ......................................
Бу кич сәер күренә ..............................
Җәй уртасында ................................
Күзләренә бәхет тулган, диләр ........................
Яшисе килә ...................................
Чын ялган ...................................
Каса Мари ...................................
«Берәүгә кояш син...» .............................
Эсфирга ....................................
Дания .....................................
Менә Пушкин һәйкәле... ............................
«Бакыр җайдак», яки Петр I һәйкәле янында уйлану .............
Яхшылык һәм яманлык ............................
Аны шатлык җыры озата китәр ........................

Поэмалар

Күз карасы ...................................
Ике авыл арасы ................................
Иртәгә... ....................................

Литературно-художественное издание

***Мингалим*** *Рустам*
*(**Мингалимов** Рустам Галиевич)*

В ЧЬИ РУКИ ОСТАВИТЬ?

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Мингалим*** *Рөстәм*
*(**Мингалимов** Рөстәм Гали улы)*

КЕМ КУЛЛАРЫНА КАЛДЫРЫЙМ?

Мөхәррире *И.Г.Ногманов*
Рәссамы *Д.В.Голубцова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректорлары *Г.Г.Гарифуллина, Р.Н.Шакирова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 10.09.2007.
Форматы 70x108 $^1/_{32}$. Офсет кәгазе.
Офсет басма. Шартлы басма табагы 16,80. Шартлы буяу-оттиск 17,15.
Нәшер-хисап табагы 13,13. Тиражы 2000 д. Заказ С-1137.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.